Процесс этот сопровождался установлением булгарской этнокультурной доминанты в лесостепной зоне региона, тогда как степи Приуралья и Заволжья в конце IX–X вв. становятся частью собственно тюркской, огузо-печенежской ойкумены. Составлявшие ее кочевнические племена буквально с самого начала своего расселения в регионе активно включаются в процессы

[1] http://www.gks.ru/free_doc/new_site/perepis2010/croc/Documents/Vol4/pub-04-07.pdf

[2] *Кузеев Р.Г.* Народы Среднего Поволжья и Южного Урала. Этногенетический взгляд на историю. М., 1992. С. 46.

формирования Волго-Уральской историко-этнографической общности через взаимодействие с этнокультурным миром волго-уральской лесостепи.

К началу монгольского нашествия в регионе складывается достаточно сложная этнокультурная ситуация, в которой наряду с булгарами заметное положение продолжали сохранять приуральские угры (носители чияликской культуры), хотя и находившиеся под мощным воздействием булгарской (тюрко-мусульманской) культуры[1].

Со второй половины XIII в. этнокультурная пестрота в регионе нивелируется под воздействием кыпчакского этнического пласта, в эпоху Золотой Орды покрывшего степные и отчасти лесостепные районы Урало-Поволжья. Если быть точнее, кыпчакская волна, точнее кимакская, достигла этого региона еще в XI в. Тогда же была исламизирована это восточная часть будущих кипчаков. Важное уточнение – в кимакском каганате правящая элита была татарского происхождения. История этих кимаков, с которыми связан знаменитый Бачман Султан, чья история попала и в татарский дастан «Туляк и Сусылу», имеет прямое отношение к Оренбуржью, так как столица этой группы находилась на месте современного г. Оренбурга[2]. Кыпчакские племена составляли конфедерацию с единой материальной культурой и одним уровнем общественного развития. Во главе конфедерации стояли ханы, занимавшего местность Юйлиболи, которую исследователи локализуют в степях северо-западного Казахстана и Южного Урала[3].

Таким образом, по данным средневековых письменных источников и археологии, степи Южного Приуралья и Заволжья с середины XI в. выступают как территория расселения кыпчакских племен. Доминирующая роль кыпчаков в степи подтверждается

---

[1] *Кузеев Р.Г.* Народы Среднего Поволжья и Южного Урала. Этногенетический взгляд на историю. С. 78–79.

[2] См. подр.: *Кумеков Б.* Кимакский каганат // История татар Западного Приуралья. Том I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 39–51.

[3] *Ахинжанов С.М.* Из истории взаимоотношений кипчаков и Хорезма в XII – начале XIII в. // Археологические исследования в Казахстане. Алма-Ата, 1973. С. 61.

также присутствием кыпчакских родоплеменных объединений в составе других этнических массивов Великого пояса степей и его окраин (узбеков, каракалпаков, татар). Письменные и историко-этнографические источники вполне определенно изображают кыпчаков как ведущий субстрат, определявший этнокультурную ситуацию на Южном Урале и в Приуралье в XI–XVI вв.

При распаде Улуса Джучи (Золотой Орды) территория современной Оренбургской области оказалась в составе Ногайской Орды. В период наивысшего могущества, в первой половине XVI в., ее граница на востоке и юге подходила к верховьям рек Тобола и Нуры, шла по реке Сарысу и затем по Сырдарье к Аральскому морю. Западным рубежом долго служила Волга. Но со временем жители Ногайской Орды стали осваивать и правобережные волжские пастбища. В XVII в. ногаи расселялись по Причерноморью и Северному Кавказу, покидая родные заволжские степи. Северные пределы Орды можно определить очень условно. До середины XVI в. в ее состав входила бо́льшая часть нынешней Башкирии[1].

Основой Ногайской Орды стал Мангытский юрт, образовавшийся в конце XIV в. в междуречье Яика и Эмбы – районе кочевания тюркского племени мангытов, во главе которого стоял могущественный беклербек Идегей (Эдиге). Он управлял в то время всеми делами Золотой Орды от имени безвластных, во всем покорных ему ханов. Традиция влияния Идегея была столь сильна, что после его гибели в 1419 г. должность беклербека закрепилась за его семьей. В восточно-кипчакских наречиях эта должность передавалась как улу бий (чаще просто бий).

Понятия «ногаи» (как народ) и «Ногаи» (как территория) появляются на страницах хроник с конца XV в. Некогда, после нашествий Тимура на Улус Джучи в 1391 и 1395 гг., Идегей воспользовался кризисом ханской власти и сумел собрать у себя за Волгой огромные массы золотоордынского населения. Стабильная и безопасная жизнь в заволжских степях привлекала

[1] *Трепавлов В.В.* Южное Приуралье в составе Ногайской Орды // История татар Западного Приуралья. Т. I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 263–278.

кочевников и позже, в первых десятилетиях XV в. Постепенно в кочевьях, подвластных мангытским биям, собрались семьи и целые общины из множества племен. Крупные войны и стихийные бедствия почти не задевали Мангытский юрт. К концу XV в. в степях между Волгой и Эмбой обитало уже третье или четвертое поколение его жителей. Общие историческая судьба и политические интересы породили у них осознание единой общности.

Показателем этого стало слово *ногай*, происхождение которого достоверно не выяснено. Так стали называть всех подчинявшихся мангытскому бию кочевников, независимо от их племенной принадлежности. Ногаями отныне были и сами мангыты, и найманы, и кереи, и десятки прочих племен. А Мангытский юрт получает в источниках второе название – Ногайская Орда[1]. К началу XVI в. ногайские бии стали уже полностью самостоятельными правителями, хотя и номинально низшими по сравнению с окрестными ханами. Постепенно увеличивался престиж управляемых ими владений. Если в документах третьей четверти XV в. «Ногаи» еще предстают как некое абстрактное пространство за Волгой, то в начале следующего столетия Орда ногаев становится в один ряд с прочими тюрко-татарскими владениями. Элита этого государства признавала свое татарское происхождения и в ряде случаев называла себя татарами (многие племена, входившие в Ногайскую Орду, такие как найманы, кереиты и др. в реальности были татарского происхождения)[2].

Налаженная система управления начала рушиться с 1550-х гг. Сказания связывают это с политической смутой, экономической катастрофой, голодом и мором, которые охватили тогда Ногайскую Орду. Еще одна причина крушения заключалась в продвижении на восток России. Огромное впечатление на соседние народы оказало завоевание Иваном IV Казанского ханства в 1552 г. Бывшие казанские данники отправили своих представителей к царскому воеводе в Казань и приблизительно в 1554–1555 гг.

---

[1] *Трепавлов В.В.* Южное Приуралье в составе Ногайской Орды. С. 263–278.

[2] См. подр.: *Исхаков Д.М.* От средневековых татар к татарам Нового времени. (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Казань: Мастер-Лайн, 1998. С. 16–31, 140–174.

были приняты в число российских подданных. Эти новые россияне оставались под управлением своих традиционных биев, а их подчинение царю в то время ограничивалось выплатой небольшого ясака. Узнав о столь необременительных условиях пребывания в составе Московского царства, примеру земляков последовали и некоторые племена южного Приуралья. Даже те из них, что были увлечены ногаями на юг, вернулись на родину и отправили делегации к казанским воеводам.

Русская администрация не возражала, чтобы ногаи продолжали кочевать на Южном Урале, но выступала резко против их попыток собирать ясак. Здесь она действовала быстро и жестко: сборщиков дани, снаряженных мирзами, хватали, вязали и бросали в тюрьмы. В конце концов ногаи перестали требовать ясак и стали организовывать грабительские набеги на свои утраченные владения.

Основание русской крепости отрядами стрельцов и размещение гарнизона воеводы Ивана Нагого в центре бывшего ногайского наместничества в 1594 г., а тем более учреждение там воеводства знаменовало собой окончание владычества здесь Ногайской Орды. Россия прочно утверждалась в Заволжье и на Урале и неуклонно двигалась в Сибирь. Ослабленные раздорами и экономическими неурядицами правители Ногайской Орды не могли воспрепятствовать формированию нового гегемона Евразии. Тем не менее Ногайская Орда присутствовала в Южном Приуралье вплоть до 1630-х гг., тем самым образуя тут золотоордынско-татарский слой[1].

С 30-х годов XVIII столетия территория современного Оренбуржья стала активно осваиваться переселенцами из центральных губерний России, в том числе из Казанской. В 1743 г. была основана пограничная крепость Оренбург, ставшая административным центром Оренбургской губернии, учрежденной именным указом императрицы Анны Иоанновны в 1744 г. У истоков основания губернии стояли известные государственные деятели и исследователи той эпохи – В.Н. Татищев, И.К. Кирилов, П.И. Рычков и И.И. Неплюев, ставший первым оренбургским губернатором.

[1] Подр.: *Исхаков Д.М.* От средневековых татар к татарам Нового времени. (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). С. 16–31, 140–174.

Казанские татары в рассматриваемые районы начали переселяться не ранее 30–40-х гг. XVIII в., причем значительная часть мигрантов была так или иначе связана с правительственной колонизацией. К моменту заселения татарами далеко не на всей этой территории (например, в западных частях Бугурусланского и Бузулукского уездов) имелось более раннее тюркское население. К тому же в юго-восточных районах, локализованных частично на стыке двух зон смешанной подобласти и недалеко от совершенно иной историко-этнографической области (Казахстан и Средняя Азия), встретились миграционные потоки выходцев из среды различных субэтносов волго-уральских татар, испытав и некоторое воздействие населения Казахстана[1]. Все эти факторы отразились и на этнокультурном облике, и на особенностях расселения татар.

1. У представителей оренбургской группы слабее выражено влияние башкир. В то же время в нескольких районах имелись «некоторые черты полукочевого хозяйства и быта»[2], что связано не только с влиянием соседних тюркских народов (башкир, казахов), но и, возможно, с определенными этническими особенностями тех компонентов, которые вошли тут в состав татарского населения.

2. Смешение казанских татар с мишарями, а также их чересполосное расселение могло привести на юго-востоке к выработке новых этнокультурных параметров. Диалектологи такие факты отмечают. Так, камышлинский говор, распространенный на территории Бугурусланского и Бузулукского уездов Самарской губ., выделявшийся как особый говор в составе среднего диалекта татарского языка, имел и определенные особенности, присущие западному диалекту. Взаимовлияние западного и среднего диалектов татарского языка в Оренбуржье отмечает З.Р. Садыкова[3].

---

[1] *Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. Казань, 1993. С. 51.

[2] *Халиков Н.А., Мухаметшин Ю.Г.* К истории формирования оренбургских татар // Всесоюзная сессия по итогам полевых этнографических и антропологических исследований 1984–1985 гг.: тезисы докладов. Йошкар-Ола, 1986. С. 103.

[3] *Садыкова З.Р.* Говоры Оренбургских татар. Казань, 1985. С. 17–18.

3. В связи с тем, что при освоении татарами Оренбуржья и примыкавших к нему территорий, кроме вольной колонизации, была значительной и роль правительственной колонизации, татарскому населению рассматриваемого ареала было присуще деление на множество сословных групп. Кроме традиционного для татар в Среднем Поволжье подразделения на «ясашных» и «служилых», татарское население юго-восточных районов делилось еще на «чемоданных» (ямских)» татар, «мещан», «купцов», «казаков», «тептярей», «тархан», «башкир», «мещеряков», «нагайбаков»[1].

4. Управление потоком татар-мигрантов со стороны правительственных органов привело к тому, что расселение татарского населения в юго-восточных районах оказалось довольно дисперсным, хотя и имевшим в некоторых ареалах и определенные «сгущения».

По мнению Д.М. Исхакова, татарское население ареала распространения юго-западного и оренбургского этнокультурного районов следует считать не консолидированной этнографической группой субэтноса казанских татар. Против консолидационных процессов действовали следующие факторы: относительно позднее заселение юго-восточного ареала; дисперсность расселения; сословная пестрота. В то же время имелись и факторы, действовавшие в направлении усиления внутригруппового сплочения: наличие ареалов компактного расселения татарского населения; активная межпоселенная миграция в пределах сословных групп (например, казаков): регулярные связи между целым рядом селений по характеру деятельности (между «ямскими» татарами); наличие крупных поселений торгового характера (Сеитова Слобода), являвшихся центрами «притяжения» татарского населения значительных территорий. В результате действия указанных противоречивых тенденций, к концу XIX – началу XX в. все же в культуре татар Оренбуржья ряд общих элементов были выработаны, но в целом сохранились как «родство и преемственность... с основными группами татарского этноса», так и внутренняя неоднородность их

[1] См.: *Садыкова З.Р.* Говоры Оренбургских татар. С. 15.

культуры[1]. Об этом же говорит и выделение в ареале юго-западного и оренбургского этнокультурного районов нескольких подрайонов (западного, юго-западного, южного). Причем часть территории тептярско-башкирского района сомкнулась с частью территории юго-западного смешанного района (центрально-приуральский подрайон). При языковой характеристике татарского населения Оренбуржья видим такую же картину. З.Р. Садыкова пишет, что здесь «довольно устойчиво» сохраняются «основные черты «материнских» диалектов и говоров... не образовался единый говор, не завершилась нивелировка говоров даже соседних населенных пунктов»[2].

Тут были распространены бугурусланский (Бугурусланский и Бузулукский уезды Самарской губ.), каргалинский (Оренбургский и Орский уезды Оренбургской губ.) говоры среднего диалекта татарского языка.

Юго-восточную группу в целом описывать довольно трудно. Поэтому мы пойдем по пути характеристики наиболее крупных составных частей этой группы. К ним можно отнести *татар-казаков, сеитовских татар и «ямских» татар*[3].

Формирование *оренбургских казаков* было связано с основанием в 30–40-х гг. XVIII в. Оренбургской военной линии (главным образом по реке Уралу, реке Самаре и реке Сакмаре). Оренбургское казачье войско было организовано из казаков и служилых людей разного рода, отчасти и ясачного населения, приписанных к городам Уфе, Самаре и прилегающих к ним крепостей. С самого начала формирования группы оренбургских казаков в их состав вошло и татарское население.

Рассмотрим формирование татар-казаков Оренбургского казачьего войска подробнее. П.И. Рычков сообщает, что недалеко от пригорода Алексеевска «имеется Татарская слобода, называемая Мочинская...Татара... все служат казачью службу

---

[1] *Халиков Н.А., Мухаметшин Ю.Г.* К истории формирования оренбургских татар. С. 103.

[2] *Садыкова З.Р.* Говоры Оренбургских татар. С. 16.

[3] *Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. С. 54.

обще с нынешними Самарскими и Алексеевскими казаками»[1]. Эти казаки относились к ставропольской дистанции и находились довольно далеко от основной группы оренбургских казаков. Кроме того, по Самарской дистанции (тоже в некотором отдалении от оренбургских казаков) татары-казаки числились еще при крепостях Борской и, возможно, Бузулукской (основаны в 1737 г.). В глубине Уфимского уезда жили крещеные казаки-нагайбаки.

Довольно много татар-казаков обосновалось и вдоль р. Урал. Наряду с русскими они отмечаются в крепостях Озерной (основана в 1736 г.) и Красногорской (основана в 1741 г.). По данным И. Фалька (сведения за 1760-е гг.), татары-казаки жили еще в крепостях Пречистинской (основана в 1743 г.) и Орской (основана в 1742 г.). Основанный в 1742 г. редут Никольский также имел татарское население. В 1770-х гг. – начале 1780-х гг. к Оренбургскому казачьему войску была причислена и часть татарского населения Сеитовой слободы. По V ревизии (1795 г.) в окрестностях г. Оренбурга числилось много селений, жители которых – татары, являлись казаками (полностью или частично). Это следующие населенные пункты: Сеитова слобода; д. Зубочистенская (при креп. Татищенской); Нижеозерная крепость, слобода Чеснокова (при этой крепости); деревни Верхние и Нижние Чебеньки; крепость Орская; крепость Ильинская; редут Никольский; станция Гирьяльская при крепости Красногорская; сельцо Чанышево; д. Ново-Умерово; д. Аблязово (жители – служилые «мещеряки») (135). Татары деревень Верхние и Нижние Чебеньки были из сеитовских татар и татар Вятской губернии; деревни основаны в конце XVIII в. Чесноковская слобода была основана в 1800 г. сеитовскими татарами. В 1819 г. из этой же слободы татары были переселены в редуты Гирьяльский и Никольский. Туда же (в 1819 г.) переселились жители д. Ново-Умерово. В 1800 г. к казакам была причислена часть татар д. Абдуллово, в 1799 г. – татары д. Нижнее Ибраево Оренбургского уезда. Очевидно, они были из сеитовских татар. В 1824 г. в Алабайтальский отряд

[1] Цит. по: *Исхаков Д.М.* Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. С. 54.

переселились татары-казаки из Гирьяльской и Никольской станиц. Вообще, в конце XVIII – первой трети XIX в. внутри всех населенных пунктов татар-казаков из Оренбургского казачьего войска происходила интенсивная межпоселенная миграция, в результате которой произошла внутренняя консолидация татар-казаков.

Еще одной составной частью оренбургских казаков являлись «кундровские» и «солтанаульские» татары (ногайцы), которые были переведены из Казанской губернии на территорию Оренбургской около 1745 г. Переселенцы были поселены около редута Желтого отдельной Кундравинской слободой (1745 г.), а в 1768 г. в Воздвиженской крепости и в Никольском редуте. Эти ногайцы сильно перемешались с средневолжско-приуральскими татарами и уже в XIX в. не отличались от остальных татар-казаков. Говор их в целом не отличается от говора остальных татар-казаков.

В конце XVIII – первой трети XIX в. группа оренбургских татар-казаков в основном сформировалась. Однако в 40-х гг. XIX в. начался следующий этап истории этой группы, связанный с проведением Оренбургской пограничной линии по новым границам и получением Оренбургским казачьим войском сплошной территории. При этом в состав оренбургских казаков были включены крестьяне прилинейных уездов (Оренбургского, Челябинского и Троицкого). В итоге в составе оренбургских казаков оказалось татарское население еще ряда селений. В 1843 г. в Зауралье, частично и на территорию Оренбургского уезда, были переселены и нагайбаки. В Оренбургском уезде они были расселены в станицах Ильинской, Неженской, Гирьяльской и Алабайтальской. Последние отпали в мусульманство и оказались в общем составе казаков-мусульман.

Таким образом, основное ядро оренбургских казаков-татар сформировалось в 30–90-х гг. XVIII в. преимущественно за счет казанских татар. Одним из этнических компонентов татар-казаков стали ногайцы. В 40-х гг. XIX в. в состав оренбургских татар-казаков влились новые группы (из мишарей, ичкинских татар и тептярей), которые, однако, с остальными татарами-казаками полностью так и не слились.

Второй крупной составной частью татар юго-восточной группы являются *сеитовские татары* – население основанной в 1745 г. Сеитовской (Каргалинской) слободы. Безусловно, население Сеитовской слободы должно быть отнесено к казанским татарам: при основании Сеитовой слободы там поселились выходцы из центральной (82%) и чепецкой (18%) этнографических групп (в основном из района Заказанья). В конце XVIII в. в слободе отмечена незначительная группа касимовских татар. Кроме того, с середины XVIII в. в Сеитовой слободе поселялись «бухарцы», «хивинцы», «персы», «кашгарцы», «турки», правда, крайне малочисленные, но частично навсегда оставшиеся среди татар (в конце XVIII в. их насчитывалось 61 чел. мужского пола, но жены у многих были татарками). Отдельные случаи поселения в конце XVIII в. мишарей среди сеитовских татар также имели место, однако абсолютное большинство сеитовских татар были выходцами из среды субэтноса казанских татар.

Жители Сеитовой слободы в первое время после основания относились к сословиям «купцов» и «мещан» (так называемые «торговые татары»). Однако в дальнейшем часть населения слободы (менее состоятельные жители) попали в сословие «крестьян». В 1788 г. татары Сеитовой слободы «из крестьян, мещан и купцов» были причислены (всего 2674 чел.) к «иррегулярным войскам» (указ сената об этом последовал в 1792 г.).

Сеитовские татары принимали активное участие в освоении юго-восточных районов. Кроме того, сеитовские татары расселялись и севернее – на территории Уфимской губернии. Так, по материалам конца XVIII в. сеитовские татары отмечены в 4-х самых южных селениях Стерлитамакского уезда Уфимской губернии: Сухом Изяке, Арсланово, Зириклях и Зяк-Ишметеве (160). Во второй половине XIX в. последнее селение относилось к Бурзянской волости Оренбургского уезда, а остальные – к Покровской волости Стерлитамакского уезда. Тогда же в ревизских материалах указывается на проживание сеитовских татар в деревнях Балыклы, Денискино, Атачево и Стерлибаш того же уезда. Еще две деревни – Яшерган и Айдарали (Белебеевский уезд, Артюховская волость) были также основаны сеитовскими татарами. Все эти населенные пункты близко примыкали к

другим татарским селениям Оренбургского уезда Оренбургской губернии. Поэтому район проживания сеитовских татар в южной окраине Уфимской губернии в этнокультурном отношении сближается с татарским населением Оренбургского уезда.

Роль сеитовских татар в формировании юго-восточной группы была весьма значительной. Именно эта роль была констатирована диалектологами, назвавшими один из основных татарских говоров Оренбуржья каргалинским. Фактически сеитовские татары и стали своеобразным ядром, вокруг которого сформировалась основная часть юго-восточной группы – оренбургские татары.

Третьим элементом татар юго-восточной группы были *«чемоданные (ямские)» татары*. Еще в 1743 г. правительством было предложено населить «иноверцами» из Уфимского уезда дорогу от Оренбурга до Казани (до Кичуевского фельшанца) с тем, чтобы они содержали «почтовой дороги почтовых лошадей». В 1749 г. этим «иноверцам» были уже обмежеваны земли по Ново-Московской дороге. Селения их находились на расстоянии от 20 до 40 верст (т.е. на расстоянии дневного перегона). Почтовую «гоньбу» это население исправляло «безденежно», за что было освобождено от «рекрутских поборов». Татары-ямщики, по данным на начало XIX в., населяли 5 селений в Оренбургском, 5 – в Бугурусланском и 4 – в Бугульминском уездах. Это следующие селения: Биккулово, Дюсметево, Мустафино, Сарманаево, Юзеево – в Оренбургском уезде; Наурузово, Кутлумбетево, Якупово, Тирес-Усманово, Шалты – в Бугульминском уезде; Альметево, Карабаш, Дымская и Кандыз Татарский – в Бугульминском уезде. Перечисленные деревни были «чисто» ямщицкими. На самом деле «ямские татары» были расселены гораздо шире. Так, в Бугульминском уезде в конце XVIII в. они, кроме отмеченных, имелись еще в 12 селениях, а в Бугурусланском уезде – в 4-х. Необходимо специально подчеркнуть, что именно «ямские татары», населявшие главным образом западную половину Бугульминского уезда, обеспечили этнокультурную связь части татарского населения этого уезда с татарами Оренбуржья. Фактически бугурусланский говор тянется полосой вдоль Ново-Московской дороги (мы уже указывали на близость к нему и камышлинского говора).

«Ямские» татары в своей основе состояли из казанских татар. Об этом говорят многочисленные исторические материалы XVIII–XIX вв. Так, З.Р. Садыкова приводит ряд данных, показывающих, что населенные пункты Ст. Якупово, Ст. Аширово, Ст. Кутлумбетево, Наурузово были заселены казанскими татарами с некоторым включением мишарей; деревни Оренбургского уезда – Дюсметево, Юзеево, Биккулово, Мустафино, Сарманаево – были заселены казанскими татарами. Следует только заметить, что ко времени переселения на Ново-Московскую дорогу многие татары уже жили в Уфимском уезде – очевидно, на территории будущего Бугульминского уезда – в качестве «тептярей», «ясачных» и «служилых» татар. Вдоль этой дороги и были поселены те «иноверцы», которые были «найдены... подлежащими к высылке на прежние жилища..., которые сами просили, чтобы на той дороге поселить». Связь их с территорией Бугульминского уезда доказывается тем, что в 1757 г. они состояли «под ведомством бывшей Бугульминской земской конторы в Надыровской волости...». Кроме того, «ямские» татары весьма часто жили рядом или в смешанных селениях с тептярями. В документе начала XIX в. про последних сказано: «...а протчие на той же дороге поселенные и в подушном окладе положенные русские и из иноверцев в тептярском окладе от содержания той почты были уволены». Видимо, часть «ямских» татар с течением времени опять перешла в сословие тептярей.

Таким образом, группа татар юго-восточных районов сформировалась главным образом в XVIII в. Основную роль при этом сыграли казанские татары, но также нельзя отрицать определенные включения мишарей и касимовских татар. Еще одним компонентом оренбургских татар (главным образом, среди казаков) стали ногайцы. Незначительные включения имелись из среды тюркского населения Средней Азии и Казахстана.

В начале XX в. Оренбургская губерния – это один из центров развития татарской культуры и духовного (мусульманского) и светского образования. В 1912–1913 гг. в Оренбургской губернии насчитывалось 367 мектебов и медресе. Из зданий общественного назначения выделялись мечети. В 1851 г. на запрос Казанской врачебной управы «о доставлении сведений, сколько

имеется мечетей...» из Оренбургского Духовного Магометанского Собрания были высланы следующие данные: «...в означенной губернии Оренбургской – 1576...»[1].

В 1907 г. в Оренбурге была создана профессиональная татарская театральная труппа под руководством И.Б. Кудашева-Ашказарского. С Оренбуржьем тесно связаны многие замечательные имена. Ахмет Хусаинов – выходец из Татарской Каргалы, купец I гильдии, меценат; на его средства было построено и открыто в 1889 г. одно из крупнейших учебных заведений в Оренбуржье и на Южном Урале – медресе «Хусаиния». Риза Фахретдинов – директор медресе «Хусаиния», богослов, ученый-историк, опубликовавший более сотни книг. Поэты, писатели Сагит Рамиев, Шариф Камал и многие, многие др. Всему миру известен Муса Джалиль – поэт, Герой Советского Союза.

В начале XX в. Оренбург стал также одним из крупнейших центров формирования национальной журналистики, публицистической мысли, книгоиздательской деятельности. В 1906–1917 гг. здесь работали 3 из 13 татарских типографий в стране («Вакыт», «Дин ва магишат», «Каримова, Хусаинова и Ко»), издавались газеты «Вакыт» и «Урал», журналы «Дин ва магишат», «Кармак», «Карчыга», «Магариф», «Мугаллим», «Чикертке», «Чукеч», «Шура», «Яз».

Развернувшийся в постсоветский период процесс возрождения национальных культур и языков затронул и татар Оренбургской области. Здесь действуют шесть татарских национально-культурных автономий и объединений области; работает более 140 татарских народных театров, вокальных и фольклорных ансамблей. Функционирует татарский драматический театр им. Мирхайдара Файзи и библиотека им. Хусаина Ямашева. Администрация области является соучредителем областной татарской газеты «Яна Вакыт». Открыт общественный институт народов Оренбуржья им. Мусы Джалиля.

---

[1] Цит. по: *Муртазина Р.* Татары Оренбуржья: история и современность // Татарские новости. 2004. № 6–7 (119–120). http://tatarica.narod.ru/archive/ 2004/08/106_04.08.11-1.htm

# СӨЙЛИ ИКӘН ТАШЛАР ДА

*Марсель Әхмәтҗанов*

Эпитафик язмалар, ягъни кабер ташларына язылган хәбәрләр татар халкы тарихы өчен зур кыйммәткә ия. Алар бу җирдә безнең физик һәм рухи яшәвебезнең документлары. Аларга карап татар кешесенең мәдәниятен, динен, дөньяга карашын, нәселен, кем варисы булуын һәм аннан калган варисларны белә алабыз.

Оренбург төбәге тарихи ташбилгеләргә аеруча бай. Кабер ташлары өчен иң яхшы сыйфатлы материал Оренбург шәһәре янындагы Татар Каргалысы авылыннан ерак булмаган Йыланчык (Грибини) тавыннан алынганга күрәдер дә, бирედә (бигрәк тә, Каргалыда) ташбилгеләр эшләүче осталар аз булмаган. Болардан без Ибраһим Мөхәммәд-Түләк углы Орынбурҗының XVIII йөз урталарыннан калган эшләрен күрсәтә алабыз. Шулай ук Каргалыда Исхак бине Габделкәрим, Хәйрулла Каргалый, Гыймадулла, Сакмар шәһәреннән Гали Габдрахман улы кебек осталар яшәгәнлеге билгеле. Каргалыда XIX гасырда моннан тыш та таш кисеп язучы осталар күп булгандыр, киләчәктә алар да ачыкланыр әле. XX гасырда да кабер ташлары язучы осталарның күп булуы шик тудырмый, чөнки Каргалыда гасыр башында сыйфатлы эшләнгән һәм язылган йөзләгән ташбилгеләр хәзергәчә сакланганнар.

Оренбург төбәген, нигездә, XVIII йөзнең икенче яртысында гына колониаль үзләштерү башлана. Ул дәвердә бу яктагы татар мәдәниятенә Казан, Касыйм якларындагы кебек көчле йогынты, басым булмаган. Шунлыктан бу төбәктә татар кабер

ташлары сәнгате иркен үсеп китә алган. Ул ташбилгеләр Оренбург төбәгендә XX йөзнең беренче яртысында да әле матур, затлы күренәләр иде. Ул затлылыкның үзәге дип, әлбәттә, үзенең таш кисеп ясау сәнгате осталары булган Каргалыны әйтә алабыз. Башка бер халыкта да таш билгеләрне сәнгать дәрәҗәсенә күтәрүчеләр юк.

Оренбург шәһәре һәм татарның XVIII–XIX гасырларда зур мәдәни үзәге булган Каргалы бистәсе галимнәребезне күптән тарихи яктан кызыксындырып килгән урын. Белүебезчә, бирегә XIX гасыр ахырында Оренбургка нигез салучыларның каберләрен табу нияте белән беренчеләрдән булып күренекле татар галиме Ризаэддин бине Фәхретдин килеп киткән. Ул анда Каргалыда күмелгән Габделкәрим Балтай улы каберен дә өйрәнгән[1]. Ләкин галимнең Габделкәрим турындагы язмаларында ялгышлыклар күренә. Ул ташбилгедәге текстны хата белән укыган. Моны без укыган текст белән чагыштырып карарга мөмкин[2].

Соңыннан Каргалы зираты ташбилгеләре белән Оренбургтан Мәдинә Рәхимкулова, Рәшит Искәндәров, Миркасыйм Госманов, Лерон Хәмидуллин һ.б. килеп танышып киткәннәр, алар, нигездә, Каргалыда Сәгыйдь Хәялин кабер ташын эзләгәннәр. Берән-сәрән ташларны карап, алар турында галимнәрнең материаллары чыккалады, ләкин аларны масштаблы итеп өйрәнүче булмады. Дөрес, минем андагы укыган текстларны күчереп алып, үз китапларына шыпырт кына бастырып чыгаручыларны дә бераз искә алып китү мөмкин. Тик гарәп язуының аеруча катлаулыларына фән кешесенең керүе лязем.

Без 2004–2006 елларның җәйләрендә Оренбург якларына барып, җирле химаячеләр Рәшит һәм Әнвәр Искәндәровлар ярдәме белән, каланың һәм Каргалы, Сакмар, Чебенле авылларының зиратларын өйрәнеп йөрдек, бик күп материал һәм фоторәсемнәр алып кайттык. Шулар арасыннан, Каргалыдагы иң катлаулы

---

[1] *Ризаэддин бине Фәхреддин.* Асар. Беренче том. Казан: Рухият, 2006. Б. 43.

[2] *Әхмәтҗанов М.* Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре. Казан, 2011. Б. 50–51.

текст булган Хәдиҗә бикә дөрбәсендәге эпитафик текстны матбугатка чыгардык[1]. Күпчелек ташбилгеләрнең текстлары гарәп графикасында язылган. Без аларны укып шул ук графикада күчереп тә алдык. Әмма, ата-бабалары турындагы мәгълүматны күбрәк кеше укый алсын иде дигән өмет белән, киң катлам укучыларга гарәп графикасыннан күчереп, татарчалаштырып, аңлатмалар һәм искәрмәләр белән бирергә булдык.

## Оренбург өлкәсе Сакмар төбәге
## Татар Каргалысы авылы зиратлары

### *1. Беренче зират*

Каргалыдагы иң зур иске зират Оренбургтан килгәндә юлның уң ягында кала. Аның бер очыннан икенче очына кадәр чыгу өчен генә 40 минутлап вакыт кирәк. Аркылысын үтү өчен 20 минутлап вакыт уза. Зират Каргалы ягыннан биек, ташлардан салынган стена белән әйләндереп алынган, Оренбург ягыннан һәм кыр ягыннан стенаның биеклеге 70 – 80 см чамасы. Ике зиратта безнең тарафтан 27 ташбилге укылды.



1. *«Мәрхүмә*
*Гайшә Сираҗетдин*
*хәлиләсе Мөхәммәдшәриф*
*кызы вафат 1919*
*60 йәшендә»*

Искәрмә: Прак известь таштан эшләнгән. Язмалар калкытып язылган. Түбәсендә «җан кошы» өчен су җыела торган кечкенә чокыр эшләнгән. Язмалар гарәп язуының татар тәгъликъ ысулында төшерелгәннәр.

[1] *Әхмәтҗанов М.* Татар Каргалысы (Сәгыйдь Бистәсе) дөрбәләре // Татарская археология. 2006. № 3–4. Б. 213–227.

2. *«Әл-мәрхүмә-и әл-мәгъфурә-и*
*Биби-Газизә бинте мелла*
*Габдерәшид Хан Кирмани*
*Нур Аллаһу тәгаля-и мәркадә*
*1850 сәнә майда»*



Искәрмә: ак известь таштан эшләнгән. Ташбилгенең түбәсендә «җан кошы» өчен эшләнгән су чокыры бар. Үлчәмнәре: 3×7×12 см (тирәнлеге 3 см). Язмалар гарәп язуының татар тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×31×105 см. Мәрхүмнең чыгышы Касыйм шәһәреннән икәнлеге күрсәтелә.

3. *«Мәрхүмә*
*Мәрьям*
*Бану*
*Ахмито-*
*ва 1892 –*
*1923.IV»*



Искәрмә: ак известь таш, кирилл әлифендә, уеп язылган, су чокыры юк. Ташбилгенең үлчәмнәре: 12×31×85 см.

4. *«Мәрхүмә*
*Маһи Йахъйа*
*кызы Галийева*
*вафат 1920 нче сәнә*
*9 нчы ийүлдә*
*55 яшендә*
*Гыймадулла сәнгате»*



Искәрмә: ак известь таштан эшләнгән. Язмалар уеп, тәгъликъ ысулында язылган. «Җан кошы» өчен су чокыры юк. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×35×85 см.



5. *«Әр-раҗи гафур
әл-бари Мөхәммәдсадыйк
Мөхәммәдрәхим углы вафат 43 йәшендә
1852 [йылда] мартның
12 нче йәүмендә»*

Искәрмә: ташбилге известь таштан эшләнгән, язмалары калкытып, тәгъликъ ысулында язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 13×27,5×137 см. Аның түбәсендә «җан кошы» өчен су җыелу чокыры ясалган, тирәнлеге 2 см, диаметры (чөнки чокыр түгәрәк рәвешендә) 10 см.



6. *«Әл-мәрхүм әл-мәгъфур
Нигъмәтулла Габид
улла углы 50
йәшендә вафат
яздырды углы
1814
4 нче сәнә»*

Искәрмә: ташбилге ак известьтән кисеп эшләнгән. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 14×27×85 см.

7. *«Нур Аллай әл-маркаде
мәрхүм
Хисаметдин
Шәрәфетдин
углы
Корманайыф.*



Ташбилгенең уң янында:

*Рижәм улдур сиңа и бер дога кыйл*

Ташбилгенең сул янында:

*Килүрсең кабримә зинһар дога кыйл!»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры бар, аның диаметры (түгәрәк) 8,5 см, тирәнлеге – 3 см. Ташбилгенең үлчәмнәре: 17,5×37×120 см.

8. *«Әл-мәрхүм әл-мәгъфур
Рәхмәтулла Госман углы
вафат итди 68 йәшендә
1857 сәнә нуйәбердә
рухына Фатиха»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Язмалар тәгъликъ ысулында, кабартып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен ясалган су чокыры бар. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×34×120 см.

9. *«Мулла Әлмөхәммәд бине
Габдулла әл-Кирмани
1855
дәлүнең 9»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Тексты тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры юк. Ташбилге 16×33,5×100 см зурлыкта. Мәрхүмнең ватаны Касыйм шәһәре булган.

10. *«Әл-мәрхүм әл-мәгъфур*
*дамелла Йосыфшаһ*
*бине Гарәбшаһ*
*1802 сәнә»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Эпитафик текст тәгъликъ ысулында уеп язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалмаган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 17×35×70 см.

11. *«... фи ...*
*Мәхмүд бине Тимерхан*
*Кирмани 1215 сәнә»*

Искәрмә: Текст ташбилгегә уеп язылган. Язмалар уеп тәгъликъ ысулында теркәлгәннәр. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалмаган. Мәрхүмнең үлгән вакыты һиҗри ел белән күрсәтелгән. Милади белән караганда бу дата 1800/1801 елларга туры килә. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×32×115 см. Мәрхүмнең ватаны Касыйм шәһәре булган.

12. *«Көлли нәфсин даикатен әл-мәвет*
*Биби-Һәдийә*
*Биби-Гаишә*
*кызы*
*Һибәтулла*
*Дәүләтйаров*
*хәлали вафат*
*1921 сәнә*
*ийүл 15-е*
*55 йәшендә»*

Ташбилгенең ике янында түбәндәге шигъри юллар кителгән:

1. *Күб гомер бирмәк иде тол әмәл*
*Көтмәгәндә килде җитди бу әҗәл.*
2. *Үтди дәүрән, кичди сәйран бәни күр.*
*Бәни күр дә, гүр йарагын син дә күр!*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Очы зур гөмбәз рәвешендә ясалган, гөмбәз өстендә «җан кошы» өчен су чокыры бар. Ташбилгенең үлчәмнәре 35×35×165 см зурлыкта. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып ясалганнар.



13. *«Көлли нөфсин даикател әлмәвет*
*Сөм*[1] *әлинә торҗигун*
*имам-мөдәррис дамелла*
*Әбелмәһҗан мелла Гыйсмәтулла*
*әл-Котлымәти тәвәлләде*
*вә әл-Кышкар тәгълимә-и*
*вә әл-Нөгәри сөм әл-Каргалый*
*тусна вә тәдрисә*
*68 йәшендә*

(ташбилгенең икенче ягында)

*Кятиб Хәйрулла*
*сәнә-и һиҗрийә*
*мөбарәкә 1330*
*рамазан 18*
*синтәбер 8»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән, алгы ягындагы төп текст тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Арткы стенасына текст уеп язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 21,5×34×144 см. Һиҗри 1330 ел, милади 1911 елга туры килә.

14. *«Көлли нәфсин даикател әл-мәвәт*
*әл-мәтүфийә*
*Биби-Мөкәррәмә*
*Хәким бай карый кызы,*
*Имам Харис әл-Хәйдәри*

---

[1] Сөм – үлеме.

*әһлийәсе 33*
*йәшендә 1911 сәнә*
*23 нче гыйнварда.*
(арткы стенасында)
*әл-мәрхүмин»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Арткы стенасына уеп язылган. Ташбилгенең түбәсендә «җан кошы» өчен су җыела торган чокыр ясалган, һәйкәлнең үлчәмнәре: 19×32×132 см. Стиленә караганда, аны Хәйрулла Каргалый останың эше дип бәяләргә мөмкин.

15. *«Һәза әл-мәзар кол, әлмогыйзар*
*Мәркадә әл-фазыйл*
*әл-хәзир агъныбә*
*дамелла Әхмәди*
*әш-шәһир балгыйлем*
*вә әл хөкем рухыйн*
*Әл-тәдбир лә мисле*
*вәляде әл-мәрхүм*
*лә фәна була назыйр*

(арткы стенасындагы язма)

*дамелла Нигъмәтулла*
*вә әлкаһ әл-назыйр*
*Нурулла Тәгалә-и*
*мәркаде һимә*
*вә җәгаль әл-җәннәт*

(Ташбилгенең бер янындагы язма)

*Илле алты йыл гомер сөрди, гүзәл*
*Гыйш әйләди.*
*Җан, мал, тән дин йулына әсмарләди»*

Искәрмә: ташбилге ак известь таштан кисеп эшләнгән. Язмалары кабартып, тәгъликъ ысулында башкарылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су җыелу чокыры ясалган. Һәйкәлнең үлчәмнәре: 29×32×180 см. Ташбилге Хәйрулла Каргалый эшләгән стильгә нык охшый.

16. *«1187*
*Хәмәл борожҗында Бикчәнтәй*
*Мөхәммәдкол углы кәнд фәрзәндләре*
*Искәндәр вә Әбүбәкер бер көн*
*вә бер сәгат эчендә фәнадин*
*бакайа рихләт кыйлдыйлар.*
*Өмид улдыр догада...»*

Искәрмә: вакыйгада 1773 елның март аенда Татар Каргалысында яшәп яткан Казан артындагы Түбән Оры авылыннан булган ике сәүдәгәр баласының Пугачевчылар тарафыннан җәзалап үтерелү вакыйгасы чагыла. Ташбилгедә «җан кошы» өчен су чокыры бар. Тирәнлеге – 2 см, диаметры – 10 см. Ташбилгенең үлчәмнәре: 19×43,7×140 см. Ташбилгене Каргалының атаклы ташкисү сәнгате остасы Габделкәрим бине Исхак язган.

### *2. Икенче зират*

17. *«Әл-мәрхүм, әл-мәгъфур*
*хәзрәте ишан*
*Һибәтулла бине*
*Сәйедбаттал дарел*
*бакайа рихләт*
*әйләде 1867 йылында*
*маһи шәүвәл 4ндә.*
*1283 тә*

(ташның икенче ягында)

*әл-мәгъфур әл-мәрхүм»*



Искәрмә: ташбилге яхшы известь плитәдән эшләнгән. Язмалар калкытып тәгъликъ ысулында башкарылган. Бу кабер ташы атаклы суфый шагыйрь Һибәтулла Салихов кабере өстенә куелган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×30×135 см.

18. *«Әл-мәрхүмә, әл-мәгъфүрә*
*..........*
*Биби Мәхтүмә*
*вафат җөмади әл-әвәл*
*әвәлендә 1283 дә*
*53 йәшендә*
*сәнә 1866 нчы*
*ишан хәлаләсе»*

Искәрмә: Һибәтулла Салихов ташбилгесенең артында аның хатынының вафат тарихы да язылган. Язмалар калкытып тәгъликъ ысулында башкарылган. Ташбилгенең сакланышы бик яхшы. Үлчәме: 15×30×135 см.

Ташбилгенең түбәсендә «җан кошы» килү очрагына тәгаенләнгән су чокыры да эшләнгән. Аның тирәнлеге – 3 см, диаметры – 9 см зурлыкта.

19. «*Таҗетдин бине мулла Габделнәфигъ*
*Нур Аллаһ Тәгалә-и*
*Мәркад һа...*
*1801»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында кабартып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалмаган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 14,5×32,5×100 см.

20. «*Әл мәгъфүрәт әл мәрхүмәтә*
*Мәгълифә Илек кызы вафат улды»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалмаган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15×33×60 см.

21. *«Әл-әхлак әл-бакый*
*мәрхүм Хәлил бине Җәммәт*
*Нур Аллаһ тәгалә-и*
*йөз йәшендә 1845 сәнәдә*
*кавәснең 15 ндә»*

И с к ә р м ә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Язмалар тәгъликъ ысулында кабартып язылганнар. Ташбилгенең үлчәмнәре: 12×34×100 см.

22. *«Габдессәлам бине Йосыф»*

И с к ә р м ә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Язмалар тәгъликъ ысулында уеп язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалмаган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 17×39×70 см.

23. *«Һазә мәркадел шәйех мулла*
*Габделнәфигъ бине*
*мулла Габдулла әл-Каргалый*
*Нур Аллаһ тәгалә-и*
..........
*Тарих минг дә йөздә иксән ту-*
*кызынчы йылда шәүвәл айының*
*1 нче көнендә дар фанадин дар бакайа*
*нәкылъ итди, илли йитинчи йәшендә*
*рәхим Аллаһ галәйһә рәхмәтә*
*вә сәгатә»*

И с к ә р м ә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында кабартып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 17×52×154 см.

24. *«Әбүләйес Әбүлфәйез*
*углының хәлале*
*Шәмсекамал*
*1912 нче сәнә нуйәбер 20 сендә*
*85 йәшендә*
*Айа ихвандин кардәш*
*Айа вәляде фәрзандән*
*гарибнең рухына*
*Аллаһ укуб багышлаң*
*Коръән!»*

И с к ә р м ә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында калкытып һәм уеп язылган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 23×33×97 см.

Бу ташбилге XVIII гасырда яшәгән шагыйрь Габдессәламнең улы Әбүлфәйезнең килене булып торган затныкы икәне аңлашыла.

25. *«Мөхәммәдсадыйк Габделҗәлил*
*углы вафат 75 яшендә 3 нче апрель*
*1902 нче сәнә*
*И карендашлар килүбән*
*бәни күр*
*бәни күрүб гүр йарагын*
сез дә күр»

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 24×36,5×145 см.

26. *«Гатаулла Таҗетдин углы*
*Сәйеджәгъфәроф 50 йәшендә*
*1899 йыл*
*И кардәшләр кәлиб бәни күр*
*бәни күрүб гүр йарагын син дә күр»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 13×39×105 см.

27. *«Мәркаде мәрхүм Әхмәд ибне Габ-*
*дерәшид әл-мәрхүм 38 йәшендә*
*вафат улды, дәлү борожҗында, миладийә...*
*Килеб кабремә зийарәт идән ихван*
*Кыйла рухыма бер Фатиха, Ихсан»*

Искәрмә: ташбилге Татар Каргалысы авылы янында, Сакмар елгасының сул як ярыннан бераз күтәрелгәч Моратавыз ярларыннан өстәрәк егылып ята. Ак известь таштан ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 12×30×80 см зурлыкта, сынган. Язманың бер өлеше ватылып югалган.

### *3. Татар Каргалысындагы өченче зират Дүнә зираты*

(*Материаллар 2005 елның 16 июль көннәрендә өйрәнелде*)

Каргалыдагы татарларның казаклы төркемнәре 1870 еллардагы урыс-төрек сугышында катнашып кайткач Каргалы елгасының икенче ягында аерым бер бистә булып яши башлыйлар. Алар шул Дунай буйларында дан алып кайткач, торган бистәләрен дә истәлеккә Дунай (Дүнә) ягы дип атап йөргәннәр. Дүнә ягы зураеп, аның үзенең зираты да үсеп киткән. Әлеге зиратны 2005 елда беркадәр өйрәнеп аның материалларын да бу китапка кертүне кирәк дип саныйбыз. Дүнә зираты да бик зур мәйдан биләп тора, анда тарихыбыз өчен кирәкле сәхифәләр саклана. Биредә без 13 ташбилгене укып тасвирладык.

1. *«Мәрхүмә Аюпова Рашида Гибадулла кызы, туган 1935 ел, вафат 21 апрель 2004 ел. Алланы(ң) рәхмәтен дә булсын»*

Искәрмә: коеп ясалган ак таш. Үлчәмнәре: 13×29,5×140 см. «Җан кошы» өчен ясалган чокыр бар.

2. «*Мәрхүм Аюпов Марат Фавис улы, туган 4 декабрь 1962 ел, вафат 15 июнь 2001 ел. Алланы[ң] рәхмәтендә булсын»*

Искәрмә: койган ак таш, үлчәмнәре: 13,5×30×140 см, «җан кошы» хәтирәсе булган чокыры бар.

3. Ташбилгеләр куймыйча баш казыклары утыртылган каберләр дә күп бу зиратта. Металл, арматурадан ясалып буялган чардуганнар да күп күренә. Беренче зиратта чардуганнар күрмәгән идем. Чардуганнарның монда эченә керү өчен капкалары да бар. Биеклекләре – 135–140 см, иңе – 210 см, буе – 260 см. Чардуганнарның почмак багана башларына шарлар утыртылган. Чардуганнар, нигездә, көмеш, кара, зәңгәр, яшел төсләргә буялганнар. Инде ташландык хәлдәге, күгәреп беткән чардуганнарны да күрергә туры килде. Мәсәлән:

*«Рафиков Мухаммади Магдиевич. 1906–1979»* – шундыйларның берсе.

4. Агач рәшәткәдән эшләнгән, зәңгәр төскә буялган бер чардуган. (Зиратта башка агач чардуганнар күренми, бары калын тактадан эшләнгән баш казыклары шактый күзгә ташлана). Чардуганның үлчәме: 70×155×263 см.

Зиратта ташлары тузган булса, алар янына яңаны эшләтеп кую кебек уңай күренешләр дә бар.

Ташбилгенең башында – тимпанда ярымай силуэты да бу Дүнә зиратында таралган икән. Анда язылган текст:

*«Мәрхүм Мухамедъяров Абдурашит Юсуп улы*
*Туган 1918 ел 30 март*
*вафат 1993 ел 28 май*
*Алла рәхмәтендә булсын»*

Искәрмә: ташбилгенең үлчәмнәре: 13,5×30×140 см. Ташбилгедә «җан кошы» хөрмәтенә кечкенә су чокыры да ясалган.

5. Агач тактадан куелган баш казыгы.

Өске очында ярымай силуэты ясалган. Текст: *«Мухамедьяров Наил Семен углы туган 19... 22/VII; вафат 2005 03/V»*

Искәрмә: үлчәмнәре: 4,5×29×117 см. Тактада чәчәк сурәте мотивы бар.

6. *«Мәрхүм Исәнҗан Кинҗебай углы*
*Биреш, вафат 1910+6 йылда мизанда 26 йәшендә»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Үлчәме: 13×33×100 см.

Баш казыгы куелган кабер. Казыкның очы гөмбәз силуэтына ошатып эшләнгән. Баш казыклары күплеге күзгә ташлана, Әстерхан зиратларына охшашлык арта. Каберләр өстенә, баш һәм аяк очларына да баш казыклары утырту бу зиратта күп чагыла. Каргалының беренче зиратында мондый күренешләр юк.

7. *«Мәрхүм Шәрәфетдин бине Шәмседдин*
*Туктамышев, вафат 51 йәшендә*
*2 июльдә 1917 елдан»*

Искәрмә: язмалар йөзлектә калкытып, тәгъликъ ысулында, ян якларында уеп язылганнар. «Җан кошы»на су чокыры эшләнгән. Ташның үлчәме: 14×30×90 см.

8. «*Мәрхүм Мөхәммәдзариф Мөхәммәдәмин углы Фәйзуллин*
*вафат 44 йәшендә 25 ийүндә 1917 нче йылда»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Йөзлектә калкытып тәгъликъ ысулында язылган, ян якларында уеп язылган. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 15,5×27×90 см.

9. «*Мәрхүм Тимергали Әхмәди углы*
*22 йәшендә 1915 йылда 9 нчы майда»*

Искәрмә: тәгъликъ ысулында уеп язылган.

10. «*Нурулла мәркадә Бохарлык*
*Мирзашәриф Мирза Мокыймҗан углы*
*Мөхәммәдъйаров вафат 87 яшендә»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Текст тәгъликъ ысулында калкытып язылган, дүрт якка да орнаментлар төшерелгән. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 16,5×25×122 см.

11. «*Нур Аллаһ мәркаде һәза Бохарлык*
*Мирза Ширин җәмәгате Биби Сахибә*
*Габдулла кызы 68 йәшендә 1905 йылда*
*майда*
*Йаздырды углы Мирза Мөхәммәд*
*1907 нче йылда рамазан шәриф*
*10 нында.*
*Әл кабер баб көлли нас да...*
*Әлмәвет кас көлли нас шарба»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган дүрт кырлы. Текст тәгъликъ ысулында калкытып язылган. Ташбилгегә төрле харак-

тердагы орнаментлар да төшерелгән. Ташбилгенең башы гөмбәзсыман итеп эшләнгән. Аның очына җан кошына дип тәгаенләнгән су чокыры ясалган.

12. «*Нур Аллаһ мәркадә әл-мәрхүм имам*
*җамигъ Әйүб Ибраһим углы Ибраһимов*
*вафат 76 йәшдә 1917 йылда 25 ийун*
*числасы рухына дога. 9 нчы мәхәлләдә*
*35 йыл имам.*
*Дәвалау эшләре, тәрбийә, кулындан килгән гайрәтен ахыр гомренә кадәр милләт өчен хезмәт иткән»*

Искәрмә: ташбилге кабырчык токымнан ясалган. Язмалар тәгъликъ ысулында калкытып язылганнар. Ташбилгенең очында «җан кошы» өчен су чокыры ясалган. Ташбилгенең үлчәмнәре: 19×36×145 см.

13. «*Баширова Ризәләт Фуат кызы*
*1962.12.XI1 – 2000.28.VI.*
*Басып торам тып-тын*
*Каберлектәмен мин*
*Уйлар кичәм*
*Алар үлемсезләр»*

Искәрмә: догалар да, ай да юк, «җан кошы» өчен су чокыры да юк.

Кызганыч, XX гасыр безнең халкыбызның борынгы сәнгатен таптый, юкка чыгара башлады. Оренбургның үзендәге тарихи (XVIII йөзнең икенче яртысыннан башланган) булган зират өстенә дә (аны юк итеп, әлбәттә) тугыз катлы йортлар салганнар. Оренбург шәһәре кырыендагы XX йөз ахырында ачылган татар зиратын бетерергә җыеналар дигән хәбәрләр дә ишетергә туры килде. Булыр, төтене күренгәч, кайдадыр уты януы да гаҗәп түгел. Кешеләр рәхимсез булганда, ташлар да мәңгелек түгел икән шул... Шунлыктан, һәрбер татар зиратының тарихын сөйли торган ташбилгеләрне өйрәнеп калырга өлгерә алсак иде.

# РӘДҮТ АВЫЛЫНЫҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

*Венер Усманов*

Рәдүт 1742 елда барлыкка килә һәм аңа, анда хезмәт итүче командир офицерга нисбәтле, «Никитинский редут» дигән исем-атама беркетелә[1]. Ары таба, бу торак-ныгытма ишәеп, ике мәхәлләле авылга әверелә.

Аңлашыла ки, Рәдүт каберстанындагы сакланып калган борынгы ташъязмалар узган гасырлардагы мәдәни тормышны чагылдыручы кыйммәтле тарихи чыганаклар[2]. Биредә, барлыгы 28 кабер ташы исәпкә алынды. Теркәлгән иң әүвәлге таш 1822 елда язылган. Безнең тарафтан өйрәнелгән ташъязмаларның күпчелеге XIX гасырның икенче яртысына һәм XX гасыр башына карый. Эш барышында танылган шәхесләрнең киң җәмәгатьчелеккә моңа кадәр билгесез булган кабер ташлары ачыкланды, мәсәлән: ахунд Габделҗәлил бине Мөкәй бине Капкын бине Чапкын (1731–1841)[3], хаҗел-хәрәмәен Шаһмәхмәд бине Йосыф морза Тәфкилев (1767–1845)[4], Шаһгали хәзрәт бине дамулла Шаһ-Әхмәд хаҗи (1812–1875), Шаһ-Гыйльман бине мулла Шаһ-Мөхәммәд бине Шаһиәхмәд хаҗи (?–1892), мөгаллим вә шагыйрь, Гобәйдулла бине Габдулла

---

[1] *Искандаров Р.Ш.* Оренбургские татары: историко-энциклопедический очерк. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. С. 226.

[2] Бу мәкаләне әзерләгәндә «Һадиев И.Г., Мәрданов Р.Ф. Кукмара төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Милли китап, 2014. 204 б. («Татар эпиграфикасы» сериясе; 2 нче китап)» үрнәк рәвешендә файдаланылды.

[3] *Фәхретдин Ризаэддин*. Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 177.

[4] Шунда ук. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 23–24.

әл-Рәдүди (1885–1912)[1], хәлфә Габдрахман Габдессаттар углы Бикчәнтаев (1885–1914), мөәззин Кәлямулла имам Газыйшаһ углы Мөкәев (1834–1923), имам Габделгафур мулла Һуд углы (1856–1924), имам вә мөдәррис Габделхак бине шәех Һибәтулла әл-Каргалый (?–1924)[2], хаҗи Шаһ-Сәлим бине Шаһ-Гали Тәфкилев (79 яшендә вафат).

Югарыда әйтеп үтелгән кайбер шәхесләр Ризаэддин Фәхретдинов хезмәтләрендә дә телгә алына.

Рәдүт авылы каберстанындагы ташлар төрле шәкелдә һәм бизәлештә ясалган, алар арасында сәнгать дәрәҗәсендә башкарылганнары да бар. Мондагы эпиграфик һәйкәлләрне барлыкка китерүдә катнашкан авторларның саны уннан артык дип исәпләнә һәм алар турында мәгълүмат безгә (әлеге көнгә кадәр) төгәл билгеле түгел, шуңа күрә, хәзерге вакытта, без бу мәсьәләдә фәкать фаразлар белән генә эш итә алабыз. Бу төбәктә таш карьерлары булмау сәбәпле эпитафияләрнең күбесе Каргалы һәм Оренбург хаттатлары тарафыннан язылган (әмма ләкин бу Рәдүт авылында кятибләр булмаган дигән сүз түгел) дип кистереп әйтә алабыз (мәсәлән: кятиб Гобәйдулла бине Әхмәт бине Мәхмүд Исмәгыйлев (1862–1910), кятиб Сәйфеддин бине Хафизеддин әл-Каргалы һ.б.). «Таш язгучы» билгесез осталарның исемшәрифләрен, Каргалы һәм Оренбургта шул дәвердә яшәгән руханилар исемлегеннән эзләргә кирәктер.

Рәдүт авылында тикшеренү эшләребезне башкаруда зур ярдәм күрсәткән Маннур һәм Хаҗирә Абдулмәновлар гаиләсенә ихлас рәхмәтләребезне җиткерәбез.

## № 1. Ахунд Габделҗәлил хатыны Зөһрәгә куелган таш (1822 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мәрхүмәт әл-мәгъфурәт*
2) *ахунд Габделҗәлил Мөкәй у-*

---

[1] *Рахимкулова М.Ф.* Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург: Яңа Вакыт, 1997. С. 70–72, 93–95.

[2] *Фәхреддин Ризаэддин.* Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 23–24.

3) *глының хатыны Зөһрә Моса-*
4) *л морза кызы вафат алтмыш*
5) *өч яшендә 1822*
6) *үктәбер йолдызында*

Ташъязманың авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасы, әлегә аның исем-шәрифләре ачыкланмаган, без аны бу мәкаләдә шартлы рәвештә «хаттат № 1» дип билгеләдек.

Якынча үлчәмнәре: 13×31×160 см.

### № 2. Бикҗан Меңләш бай кызына куелган таш (1829 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *һу әл-Хәййе әл-ләзи лә йәмүт*
2) *мәрхүмә мәгъфүрә*
3) *Бикҗан Меңләш бай кызы*
4) *зәүҗә морза Шаһ-Әхмәд Тәфкилүф 55*
5) *яшендә маһ шәрифнең икенче көне хут-*
6) *ның 25 нче көне 1829 сәнә бәне яздырды*
7) *кияве Габдеррәүф.*

Ташъязманың авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасы, әлегә аның исем-шәрифләре безнең тарафтан ачыкланмаган, без аны бу мәкаләдә (шартлы рәвештә) «хаттат № 2» дип билгеләдек.

Якынча үлчәмнәре: 12×33×160 см.

### № 3. Хәлим-Җәүһәр Кылай кызына куелган таш (1832 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мәрхүмәт әл-мәгъфурәт*
2) *Хәлим-Җәүһәр*
3) *бинте Кылай*
4) *хәлиләи*
5) *Ишмөхәммәд ва-*
6) *фат 62 яшендә*
7) *каръяи Рәдүтдә*
8) *1832 сәнәдә*
9) *гакрабда, рухына фатиха.*

Аңлашыла ки, ташъязманың авторы – Каргалы яисә Оренбург остасы, әлегә аның исеме ачыкланмаган, без аны шартлы рәвештә «хаттат № 3» дип билгеләдек.

Якынча үлчәмнәре: 13×30×150 см.

### № 4. Бәлхия Нәзер кызына куелган таш (1833 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *мәрхүмә...* * *...***
2) *морза кызы вафат*
3) *1833 сәнәдә * Бәлхия (?) ** Нәзер*

Ташъязманың авторы мәгълүм түгел, шул ук Каргалы (яисә Оренбург) остасы язган дип уйланыла.

Якынча үлчәмнәре: 12×30×60 см.

### № 5. Ахунд Габделҗәлил[1] Мөкәй углына куелган таш (1841 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *мәркадь мәрхүм*
2) *ахунд Габделҗәлил*
3) *бине Мөкәй вафат*
4) *110 яшендә*
5) *1841 сәнә май.*

Язу үзенчәлегенә карап: эпиграфик ядкярнең авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасы булгандыр дип әйтергә була, әлегә аның исем-шәрифләре ачыкланмаган, ул (шартлы рәвештә) бу мәкаләдә «хаттат № 4» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 8×33×65 см.

### № 6. Ишан, хаҗи Шаһиәхмәд Йосыф морза углына куелган таш (1845 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-Хәллякъ*
2) *әл-Бакый оста-*

[1] Ахунд Габделҗәлил турында тулырак мәгълүматны карагыз: *Фәхретдин Ризаэддин.* Асар. 1 том. Казан: Рухият, 2006. Б. 177.

3) *з әл-көлл хаҗи*
4) *әл-хәрәмәен*
5) *ишан әл-мәрхү-*
6) *м хаҗи Шаһиәхмәд ибне*
7) *Йосыф морза*
8) *1261 нче сәнәдә*
9) *маһ сәфәрнең*
10) *18 нче йәүмендә*
11) *88 яшендә*

арткы һәм уң ягында (күпертмә язулы): ... (догалар язылган)

Сул ягында (күпертмә язулы):

1) *хәер*
2) *дога*
3) *өмет*
4) *итеп*
5) *яз-*
6) *дыр-*
7) *гу-*
8) *чы*
9) ...
10) *еддин*
11) *бине Нур-*
12) *Мөхәммәд*

Эпиграфик һәйкәлнең авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасыдыр, исем-шәрифләре әлегә ачыкланмаган, шартлы рәвештә «хаттат № 5» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 16×32×165 см.

## № 7. Ишхуҗа Ишмөхәммәд углына куелган таш (1867 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мәрхүм әл-мәгъфүр*
2) *Ишхуҗа*
3) *бине Ишмөхәммәд*

4) *72 яшендә*
5) *рухына фатиха*
6) *амин 1867 елда.*

Ташъязманың авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасы, исем-шәрифләре ачыкланмаган, «хаттат № 6» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 8×30×75 см.

### № 8. Шаһгали хәзрәт Тәфкилевкә куелган таш (1875 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мөтәвәффи*
2) *дамулла Шаһ(и)-*
3) *Әхмәд ха-*
4) *җи бала-*
5) *сы Шаһгали*
6) *хәзрәт в-*
7) *афат 63*
8) *яшендә*
9) *1875*

Арткы ягында (күпертмә язулы) авыр укылышлы текст. Каберташ «чалмалы» дүрткел сөтүн-багана рәвешендә ясалган. Калган ике як кабыргасында калкытып бизәк төшерелгән.

Якынча үлчәмнәре: 25×25×125 см.

### № 9. Шаһимәрдан Шаһиәхмәд хаҗи углына куелган таш (1879 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *нәүвәрә Аллаһы мәркадь*
2) *әл-мәрхүм*
3) *Шаһимәрдан*
4) *Шаһиәхмәд*
5) *хаҗи углы*
6) *78 яшендә*
7) ...

Сул ягында (уйма язулы): *1879 сәнә*

Шаһимәрдан Тәфкилевкә нисбәтле каберташ «хаттат № 4» тарафыннан язылган дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 9×27×100 см.

**№ 10. Габделбакый Җангол углына куелган таш (1882 ел)**

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мәрхүм әл-мәгъфүр*
2) *Габделбакый*
3) *Җангол углы Тәналин*
4) *1882 нче ел хут 7 ндә*

Ташъязманың авторы – Каргалы (яисә Оренбург) кешесе, исем-фамилиясе ачыкланып бетмәгән, ул «хаттат № 7» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 9×28×120 см.

**№ 11. Шаһ-Гыйльман Тәфкилевкә куелган таш (1892 ел)**

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *Мәрхүм*
2) *Шаһ-Гыйльман*
3) *ибне мулла*
4) *Шаһ-Мөхәммәд*
5) *Тәфкилев 55 дә*
6) *Шаһиәхмәд хаҗи*
7) *нәбирәсе саратанда.*

Уң ягында (күпертмә язулы): *1892 сәнәдә.*

Ташъязманың авторы – Каргалы (яисә Оренбург) остасы, исем-шәрифләре ачыкланмаган, «хаттат № 8» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 20×30×160 см.

**№ 12. Биби Шакирә Мөхәммәдҗан кызына куелган таш (1894 ел)**

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *Шәһре*
2) *Каргалының*

3) *мәшһүр Һибәтулла*
4) *ишан хәзрәт*
5) *хәлиләсе мулла*
6) *Мөхәммәдҗан кызы.*

Арткы ягында (күпертмә язулы):

1) *биби Шакирә*
2) *62 дә маһ рәҗәб*
3) *23 ндә 1894 сәнә*
4) *һиҗрия 1311.*

Ташъязманың авторы имам вә мөдәррис Габделхак бине шәех Һибәтулла әл-Каргалый (?–1924) булуы ихтимал.

Якынча үлчәмнәре: 11×25×80 см.

### № 13. Биби Әминә Габбас кызына куелган таш (1896 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):
1) *мәрхүмә*
2) *биби Әминә*
3) *Габбас кызы*
4) *Шаһ-Гыйльман*
5) *хатыны 60*
6) *яшендә 11*
7) *нче августда*
8) *1896 сәнәдә.*

Бу эпитафия «хаттат № 8» тарафыннан язылганга охшаган.

Якынча үлчәмнәре: 11×30×140 см.

### № 14. Нәфисә Габдулла кызына куелган таш (1908 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):
1) *нәүвәрә Аллаһы*
2) *мәркадь әл-мәрхүмә Нәфисә бинте Габдулла хәлиләт Исхак ибне Исмәгыйль тәваффиәт фи сәнәи һ (һиҗри илән) 1326–1908...*

Ташъязманың авторы «хаттат № 4» булган дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 8×38×65 см.

### № 15. Габделгази хатыны Мәхбүбәгә куелган таш (1909 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *сахиб һазә әл-мәркадь Рәдүд*
2) *карьясендә имам*
3) *Габдулла хәзрәт*
4) *Габделгази*
5) *углы Ишморадов*
6) *әнкәсе Мәхбүбә*
7) *мәдфүн 1909*
8) *нче ел 25 нче февральдә...*

Ташъязманың авторы Габдулла хәзрәт Ишморадов булуы ихтимал.

Якынча үлчәмнәре: 8×32×120 см.

### № 16. Госман Хөсәеновка куелган таш (1910 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *нәүвәрә Аллаһы мәркадь*
2) *Госман Гомәр*
3) *углы Хөсәенов*
4) *вафат 62 яшендә*
5) *1910 нчы елда*
6) *11 нче сентябрь*
7) *дога өмид итә*

Ташъязманың авторы югарыда әйтеп үтелгән «хаттат № 4» дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 8×32×85 см.

### № 17. Мөгаллим Гобәйдулла Габдулла углына куелган таш (1912 ел)

Алгы ягында (уйма язулы):

1) *мөгаллим Гобәйдулла*
2) *бине Габдулла әр-Рәдүди*
3) *вафат 27 яшендә*
4) *ноябрь 28 ндә 1912 сәнә*
5) *үзенең нәзымләре*

6) *кешеләр шәб шәб атлаб үтерсезләр селкетеп йерне*
7) *онытмагыз берәү калмас бу йергә күмелми.*

Уң ягында (уйма язулы):

*кеше үлгәч аңа маллар гыяллар да кирәк булмас*
*гамәлләр изге халләр тик улыр кабер әһленә юлдаш*

Сул ягында (уйма язулы):

*биек шөһрәтле таулар бар җиһанда мәшһүр ирләрдәй*
*ләкин ирләр үлә таулар утырыб кала җирләрдәй*

Арткы ягында (уйма язулы):

*тәне чересә дә рухы саудыр әүвәл шаддыр йә әгълиядер*
*аның шадлануы әгъля вә би хакъ әмеренә багълиядер*
*кятиб Гобәйдулла мөэззин әл-Оренбурый*

Якынча үлчәмнәре: 22×31×155 см.

### № 18. Габдрахман хәлфә Бикчәнтаевка куелган таш (1914 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *мәрхүм*
2) *Габдрахман хәлфә*
3) *Габдессаттар углы*
4) *Бикчәнтаев*
5) *вафат 29*
6) *яшендә.*

Сул ягында (уйма язулы): *1914 елда*

Ташъязманың авторы – Каргалы яисә Оренбург остасы, исем-шәрифләре ачыкланмаган, «хаттат № 9» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 18×40×120 см.

### № 19. Мөхәммәдкәрим Мөхәммәдләтыйф углына куелган таш (1920 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *мәрхүм*
2) *Мөхәммәдкәрим*

3) *Мөхәммәдләтыйф*
4) *углы вафат*
5) *60 яшендә*
6) *...* сәнә майда * 1920 нче ел*

дип укырга кирәктер.

Арткы ягында (күпертмә язулы):

1) *фи сәфәр...*
2) *12 нче*
3) *фатиха*

Ташъязманың авторы югарыда әйтеп үтелгән «хаттат № 8» булуы ихтимал.

Якынча үлчәмнәре: 11×30×120 см.

## № 20. Шәрәфеддин Килмөхәммәдовка куелган таш (1922 ел)

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *Рәдүдле*
2) *мәрхүм*
3) *Шәрәфеддин*
4) *Садыйк углы*
5) *Килмөхәммәдов*
6) *81 яшендә*
7) *1922 нче ел*

Ташъязманың авторы – Каргалы яисә Оренбург остасы, исем-шәрифләре ачыкланмаган, «хаттат № 10» дип билгеләнде.

Якынча үлчәмнәре: 10×32×155 см.

## № 21. Мөәззин Кәлямулла Мөкәевкә куелган таш (1923 ел)

Алгы ягында (уйма язулы):

1) *көлли нәфсин заикател-мәүт*
2) *мөәззин Кәлямулла имам Газыймшаһ углы Мөкәев 69 яшендә вафат 1923 сәнә 31 март шагбан 15.*

Ташъязманың авторы билгеле түгел.

Якынча үлчәмнәре: 9×30×150 см.

## № 22. Имам Габделгафур мулла Һуд углына куелган таш (1924 ел)

Алгы ягында (уйма язулы):
1) *нәүвәрә Аллаһы мәркадь*
2) *имам Габделгафур*
3) *мулла Һуд углы*
4) *1924 сәнәнең*
5) *февраль 12 ндә*
6) *68 яшендә...*

Ташъязма остасының исем-шәрифләре төгәл билгеле түгел.
Якынча үлчәмнәре: 7×26–30×95 см.

## № 23. Имам вә мөдәррис Габделхак[1] Һибәтулла ишан углына куелган таш (1924 ел)

Алгы ягында (уйма язулы):

1) *мәрхүм*

2) *имам вә мөддәрис Габделхак бине шәех Һибәтулла әл-Каргалый 1924 нче сәнә 1 нче гыйнуар (да) мәдфүн.*

Ташъязма авторының исем-шәрифләре билгеле түгел.
Якынча үлчәмнәре: 11×30×115 см.

## № 24. Гобәйдулла Фәтхулла углына куелган таш
(ике өлешкә чатнап сынган).

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *нәүвәрә Аллаһы*
2) *мәркадь*
3) *Гобәйдулла*
4) *бине Фәтхулла*
5) *65 яшендә*
6) *рухына*
7) *(фатиха...).*

---

[1] Габделхак хәзрәт турында мәгълүматны кара: *Фәхретдин Ризаэддин.* Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 24.

Ташъязманың авторы югарыда билгеләп үтелгән «хаттат № 7» дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 8×30×95 см.

### № 25. Биби Шакирә Җөмһүр кызына куелган таш

Алгы ягында (күпертмә язулы):

*нәүвәрә Аллаһы мәркадиһа биби Шакирә Җөмһүр кызы Габдулла мөәззин хәляле 23 яшендә.*

Ташъязманы Каргалы остасы кятиб Сәйфеддин бине Хафизеддин язгандыр дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 8×29×80 см.

### № 26. Әбүбәкер Хөсәеновкә куелган таш

Эпиграфик һәйкәл дүрт кырлы сөтүн-багана рәвешендә ясалган.

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *нәүвәрә Аллаһы мәркадиһә*
2) *Әбү-әл-бәкер*
3) *Гомәр углы Хәсәнов*
4) *51 яшендә*
5) ...

Ташъязманың авторы Каргалы остасы кятиб Сәйфеддин бине Хафизеддин дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 26×26×115 см.

### № 27. Хаҗи Шаһ-Сәлим Тәфкилевкә куелган таш

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *әл-мәрхүм әл-мәгъфүр*
2) *хаҗелхәрәмәен*
3) *Шаһ-Сәлим ибне*
4) *Шаһ-Гали Тәфкилев*
5) *вафат* 79
6) *яшендә.*

Эпиграфик һәйкәлнең авторы югарыда билгеләп үтелгән «хаттат № 9» булгандыр дип фараз ителә.

Якынча үлчәмнәре: 10×38×160 см.

### № 28. Мулла Габделхак кызы Садыйкага куелган таш

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) *мәрхүмә*
2) *Садыйка мулла*
3) *Габделхак кызы*
4) *Мамина*
5) *(Батталова)*
6) *27 яшендә*
7) ...

* Һиббәтулла ишанның оныгы.

Эпиграфик һәйкәлнең авторы – югарыда билгеләп үтелгән «хаттат № 10» булгандыр дип фараз итәргә кирәк.

Якынча үлчәмнәре: 10×34×110 см.

# ТЕЛЕН БЕЛГӘН – ТАРИХЫН ДА БЕЛЕР

*Дария Рамазанова*

Оренбург яклары миңа балачактан таныш кебек тоела. Күршебез Кәшшаф бабай җилкәсенә кечкенә, ләкин бик авыр сандыгын куеп, Оренбург якларына тегүчелек белән кәсеп итәргә чыгып китә иде. Гомумән, безнең авылда өязгә йөрүчеләр шактый иде: Шәриб абзыйлар, Фазылҗан абзыйлар, Ислам абыйлар (кайсы тегүче, кайсы итек басучы) 1960 елларга кадәр өязгә йөрделәр. Өяз сүзе уезд сүзенең халык телендәге варианты. Хәзерге Татарстанның Кама аръягының көнчыгыш өлеше, көньяк Башкортстан, Оренбург яклары – Уфа өязе (Уфимский уезд) дип атала иде, соңга таба Оренбург губернасы оеша. Башкортстан татарларының тарихын өйрәнгәндә, архив материалларындагы кайбер фактларны ачыклау өчен, минем авылыбызның мөхтәрәм бабайларына мөрәҗәгать иткәнем булды. Мәсәлән, хәзерге Башкортстанның Баймак районы Юлук авылы кешеләре үзләренең бер үтенечләрендә (XIX йөз башы) безнең бабайларыбыз Арча даругасы Эзмә Пүкәле авылыннан килгәннәр дип күрсәтәләр. Мин авылыбызның исеме (Пүкәл) шулай икенче төрле аталып йөртелдеме икән дип баш ватканнан соң, әлеге өязгә йөрүче бабайларыбызга мөрәҗәгать иттем. Алар барысы да «безнең авыл документларда шулай аталып йөртелә иде, адресны Эзмә Пүкәле дип язмасак хат та бармый иде», дип аңлаттылар. Казан арты кәсепчеләребез шул рәвешле бөтен Урал буйларын, Оренбург далаларын иңләп-буйлап йөргәннәр, күрәсең. Идел буе һәм Оренбург далалары арасындагы

бәйләнешләрнең ерак традицияләре хәзерге чоргача килеп җиткәннәр. Бу мәсьәләләр белән Көнбатыш Башкортстандагы татар сөйләшләрен, андагы татарларның тарихын өйрәнгәндә безгә архивларда (Мәскәү, Уфа, Пермь, Оренбург, Казан) шактый озак тикшеренүләр алып барырга туры килде (Рамазанова, 1984; 2001; 2002, 1996, 1998 һ.б.).

Халык күбәя, җирләр җитми башлагач Башкортстаннан көньякка таба күчеш башлана. Мәсәлән, Оса даругасы йомышлы татарлары (хәзерге байкыбаш сөйләше вәкилләре) Уфа өязе Ногай даругасы (хәзерге Кырмыскалы районы) җирләренә күченәләр (РГАДА, ф. 248, тасв. 3, сакл. берәмл. 115, 647 б.), Казан, Ногай даругаларыннан хәзерге Стәрлетамак төбәгенә (РГАДА, ф. 452, тасв. 2, сакл. берәмл. 115, 62 б. һ.б.) күченәләр. Архивлардагы язма чыганаклар аларның Оренбург губернасы белән күрше төбәкләргә (хәзерге Стәрлебаш районы җирләренә) (Хәлекәй, Карагош һ.б. авыллар) күчүләре турында сөйли. Гомумән, Уфа өязеннән көньякка таба күчеш XVII гасыр азагында, XVIII гасыр башларында бик актив булган (РГАДА, 248, 452, 172 һ.б. фондлар)[1].

Оренбург губернасын үзләштерүчеләрнең зур өлеше Уфа өязеннән көньякка таба, Идел буеннан көнчыгышка таба иркенрәк җирләр эзләп килгән һәм урнашкан татарлар булган. Крайда формалашкан сөйләшләрнең камышлы һәм стәрлетамак, минзәлә сөйләшләре белән аеруча зур уртаклык күрсәтүенә шул вакытта нигез салынган булырга тиеш. Планлы күчереп утыртуларга хәтле әлеге җирләрдә азмы-күпме абориген төрки халыклар да яшәгән булса кирәк. Биредә тагын нугай компонентының ролен дә онытырга ярамый[2].

Рус хөкүмәте тарафыннан, Урта Азия белән бәйләнешләрне үстерү, Россиянең көньякта һәм көнчыгыштагы чикләрен ныгыту максатларын күздә тотып, Орь елгасы буена башта Орск, ә 1735 елдан Оренбург шәһәренә нигез салына. Алга таба әлеге

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. Б. 53.

[2] *Әхмәтҗанов М.И.* Ногай Ордасы. Казан, 2005.

шәһәрне Самара аша Россия башкаласы белән тоташтыру күздә тотыла һәм ул юлга «Яңа Мәскәү юлы» (Новомосковская дорога) дигән исем бирелә.

Оренбург каласына иң башта татар сәүдәгәрләре чакырыла. Сәгыйть Хаялинга һәм аның белән бергә Казан губернасыннан намуслы, сату-алу итә алырдай, моның өчен матди мөмкинлекләре дә булган 200 татар гаиләсе күчереп утыртыла. Шулай итеп Сәет бистәсенә нигез салына.

1745 елгы халык саны алу материалларыннан күренгәнчә, Сәет бистәсенә (ул икенче төрле Каргала дип тә атала) Казан өязе Арча даругасыннан Муслюм Кусюмов сотнясына керә торган Мәмәт пустыше (Маметева пустышь)[1] авылыннан Сеит (Сәет) Хаялин (ул Аид Хаялин улы була) һәм аның белән бергә Малые Сабы, Бубый, Тенекеево, Бурначи, Ст. Сабы, Адаево, Атлашево авылларыннан, Свияга (Зөя) өязе Яңа Тархан, Җөри даругасы Усюли, Алат даругасы Кумбыбаш, Ногай даругасы Старый Адам авылларыннан да күчүчеләр була (РГАДА, ф. 350, тасв. 3, сакл. берәмл. 2619). Шулай итеп, Сәет бистәсенә беренче башлап утыручыларның иң күбесе Арча даругасыннан, тагын Җөри һәм Алат даругаларыннан (Бу хәзерге Саба, Мамадыш, Кукмара, Дөбьяз районнарыннан дигән сүз) да булалар.

1743 – 1744 елларда Оренбургны Россиянең үзәге Мәскәү белән Казан аша тоташтырырга булалар. Бу юл «Большая Московская дорога» («Зур Мәскәү юлы») дип атала башлый, почта тракты оештырыла һәм ул трактта 20 – 30 чакрым ара калдырып авыллар утыртыла, алар ям куучыларның бистәләре дип аталалар һәм бушлай ям чабарга (почта йөретергә) тиеш булалар, рекрутлык йөкләмәсеннән азат ителәләр.

XVIII гасырның 50 нче елларында Мәскәү трактында 4720 кеше исәпләнә, шуларның яртысы татарлар була, Идел буеннан башка халыклар да катнаша (Материалы по истории Башкирской АССР. Т. IV, ч. I, М., 1956, 390 б.). Аларны «чемоданные татары» дип йөртә торган булганнар. Яңа Мәскәү тракты тирәләрен

---

[1] Саба районы Сәрдә авылы кешеләре 1970 елларда ул авылның урынын яхшы хәтерлиләр иде.

үзләштерүдә үзирекле, үз теләкләре белән килгән крестьяннар да катнаша. Оренбург өлкәсе дәүләт архивында (ГАОО) 138, 98 һәм башка фондларда төрле почмаклардан бу якларга күчеп килеп урнашучылар турында күп кенә материаллар саклана.

Оренбург төбәген үзләштерүдә нократ сөйләше вәкилләре дә катнашкан. Архив документларыннан күренгәнчә XVII йөз урталарында аларның бабалары хәзерге Әгерҗе, Актаныш төбәкләрендәге Ырыс, Салагыш, Мөшегә һ.б. авылларга нигез салалар (РГАДА, ф. 1173, тасв. 1, сакл. берәмл. 861, 23 б.). Экспедициядә йөргәндә әлеге авылларда аларның бабаларының карин татарлары булуы турындагы риваятьләр ишетергә туры килгән иде. Бу бәйләнешләр тел материаллары белән раслана. Соңга таба карин татарлары көньякка таба күчәләр. 1685 елгы документлардан күренгәнчә, Бөгелмә округы Утазы авылы кешеләре (Токтамышевлар), Бәләбәй округы Устюба авылыннан Дәүләтьяровлар (Сәгыйть Сараев һәм башкалар) үзләрен карин татарлары дип күрсәтәләр (РГАДА, ф. 1173, тасв. 1, сакл. берәмл. 642, 1, 2, 25, 74 б.; сакл. берәмл. 861, 1 б.), тагын да соңга таба аларның дәвамчылары Оренбург җирләрен үзләштерү кампаниясендә катнашулары билгеле һәм, Сәет бистәсендә халык артык күбәеп киткәч, алар Яшырган елгасы буйларына (Оренбург өлкәсенең төньяк чиге) күчереп утыртылалар. Гомумән, Оренбург җирләрен үзләштерүнең бай тарихы бар һәм бу тарихны өйрәнү дәвам ителергә тиеш.

Шулай итеп Оренбург өлкәсендә урнашып калган халыкларның этник составы Казан татарларыннан, типтәрләрдән, мишәрләрдән торган, аларның чыгышы Казан һәм Уфа губерналарының төрле районнарыннан булган.

Социаль катламнардан түбәндәгеләр билгеле: типтәрләр, ялгызаклар, ясаклы татарлар, «чемоданные татары», йомышлы татарлар, тарханнар, башкортлар, нугайбәкләр, мещаннар, казакълар.

Шулай итеп, чагыштырмача иркенрәк булган хәзерге Оренбург җирләрен үзләштерүдә төньяктан үзирекле рәвештә күчеп килгән халыкларның да роле зур була. Моңа Оренбург өлкәсендәге сөйләшләрне өйрәнүче галимә З.Р. Садыйкова

да игътибар итә[1]. Тагын шунысын ассызыклап күрсәтергә кирәк, Уфа өязеннән килүчеләр төрле сословиеләргә караганнар: тархан, башкорт, типтәр һәм башкалар. Галимнәрнең архив документларына нигезләнеп язган тикшеренүләрендә бу сословиеләрнең саф татарча сөйләшүләре, рухи һәм материаль мәдәниятләре белән Казан татарларыннан аерылмаулары исбатлана. Шуңа күрә, биредә бу сословиеләргә карата кыскача мәгълүматлар китереп китү кирәк.

**Тарханнар** ясактан азат ителгән йомышлы катламны тәшкил иткәннәр. Казан ханлыгы чорында аларга тарханлык турында грамота бирелә торган булган. Алар Уфа өязенә кергәч тә тарханлыкларын саклаганнар. Ләкин башкорт җирләрендә үзенең хакимлеген көннән-көн ныгыта барган патша Россиясе өстенлекле хокукларны бетерә бара һәм, нәтиҗәдә, XVIII гасырда тарханнарның өстенлекләре, гәрчә әле җир мәсьәләсендә берникадәр роль уйнаса да, юкка чыгарыла[2]. Халык арасында да тархан дип атау очраклары күзәтелә.

**Башкортлар.** Казан ханлыгы җимерелгәч, хәзерге Башкортстан җирләрендә яшәүче җирле халык, нинди милләттән булуына карамастан, башкортлар яки башкортлар-вотчинниклар дип атала башлыйлар. Казан өязенең көнчыгыш өлешендәге җир биләүчеләр Уфа ясагына (ул Казан ясагына караганда җиңелрәк була) күчкәч, шулай ук Башкирия халкы булып китәләр һәм аларга карата да башкорт дигән административ атама кулланыла башлый. Өстенлекле сословие булганга күрә, башка сословие вәкилләре дә башкорт сословиесенә күчәргә тырышканнар (бу турыда әдәбиятны кара: Рамазанова, 2002; Исхаков, 2002 һ.б.). Тархан атамасы кебек үк, башкорт сословиесе дә Оренбург өлкәсендә сирәк күзәтелә.

**Типтәрләр** Оренбург өлкәсендә шулай ук сирәк очрый. Күп кенә авылларда типтәр сүзен белмиләр дә. Бу социаль атама

---

[1] *Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань: Таткнигоиздат, 1985. С. 76; 1985. С. 7

[2] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. С. 20; Аныкы ук. Татары Восточного Закамья: их распространение, формирование говоров. Казань: Магариф, 2002. С. 46–47.

да, нигездә, Уфа өязеннән күчеп килүчеләр белән бәйле булса кирәк. Көньяк Урал далаларында күчеп йөргән башкортларның җирләренә утыручы крестьяннарның припущенниклар дип аталулары мөмкин. Гомумән, бу җирләрдәге халыкларның тарихы җентекләп өйрәнелгән дип әйтеп булмый.

Типтәр дигән атама рәсми сословие мәгънәсендә XVIII йөз урталарында кулланыла башлый. Бу сүз фарсыча дәфтәр сүзенең халык телендә таралган варианты, аның тагын девтяр дигән варианты да архив документларында теркәлеп калган (РГАДА, ф. 1173, тасв. 1, сакл. берәмл. 1198, 3 б.). Бу атама тагын «тептярской ясак», «девтярской ясак», «окладной тептярской ясак» дип тә аталган мондый ясакны башкортлар, ясаклы татарлар түләгән[1].

Оренбург экспедициясе оештыру, яңа чикләрне саклау линияләре төзү кебек әһәмиятле чаралар уздыру өчен, рус дәүләтенә барлык ресурсларны да барлау, икътисади мөмкинлекләрне исәпкә алу ихтыяҗы туа һәм хөкүмәт 1734 елның 31 мартында түбәндәге Указны чыгара: «всех припущенников края записывать и расправшивать, кто откуда и давно ль пришли и в подушный оклад положены ль...»[2]. Бу указ чыкканнан соң, типтәрләр аерым сословие буларак исәпкә алына башлыйлар һәм алар махсус ясак түләргә тиеш булалар.

Фәндә билгеле булганча, санап чыгылган сословиеләр XIX гасыр уртасыннан «башкиры из тептярей» дип атала башлыйлар[3].

## Оренбург өлкәсендәге татар сөйләшләре

Сөйләшләрне өйрәнү тарихыннан. Татар диалектларын лингвистик география методы белән өйрәнү башлангач, Оренбург өлкәсен эченә алган квадратны яшь галимә З.Р. Садыйковага тапшыралар. Ул, күп санда экспедицияләр уздырып, бай материал туплауга ирешә.

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984. С. 67.

[2] Полное собрание законов, Т. IX: 337–338.

[3] *Рамазанова Д.Б.* Татары Восточного Закамья... Таблица на с. 22–25.

Конкрет материалларны җентекләп анализлаганнан соң, З.Р. Садыйкова Оренбург өлкәсендә 3 сөйләш таралган икәнен ачыклый: каргалы, богрыслан (урта диалект) һәм шарлык (көнбатыш диалект), сөйләшләр эчендә урынчылыклар да аерып чыгара. Автор әлеге сөйләшләргә хас уникаль күренешләрне, оригиналь үзенчәлекләрне тасвирлап монография бастыра (1985)[1] һәм аны кандидатлык диссертациясе итеп яклый (1986). Крайда таралган сөйләшләр татар халык сөйләшләренең 2 томлык атласында чагылыш таба.

Оренбург краендагы татар сөйләшләренең З.Р. Садыйкова тарафыннан язылган тасвирламасы «Татар халык сөйләшләре» дигән 2 томлык китапта да урын алды.

Соңгы елларда А.Я. Хөсәинова тарафыннан әлеге төбәктәге сөйләшләрнең лексик-семантик системасын анализлауга багышланган тикшеренү уздырылды һәм диссертация якланды (2015)[2]. Хезмәтнең ике зур яңалыгы бар иде.

Беренчедән, Оренбург краендагы сөйләшләрнең лексикасы система буларак тикшерелде һәм номинациянең үзенчәлекләре ягыннан сөйләшләрдәге оригиналь күренешләр ачылды. Ике диалектка караган сөйләшләрнең үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән күренешләр табылды, шушы төбәккә генә хас лексик берәмлекләр аерып чыгарылды.

Икенчедән, Оренбург краендагы сөйләшләр Идел буе татарларының чагыштырмача соңгырак (XVIII–XIX йөзләрдә) чорда күчеп килүләре нәтиҗәсендә формалашканнар, аларның элекке яшәү урыннарындагы ана сөйләшләр белән уртак үзенчәлекләре күзәтелә. Бу факторларны ачуда Институт тарафыннан төрле төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыруның роле һәм әһәмияте зур булды.

Нәтиҗәдә, А.Я. Хөсәинова ана сөйләшләргә хас диалекталь лексиканың Оренбург краенда, ягъни яңа шартларда, төрле сөйләшләр белән үзара тыгыз контактта төрле характердагы үзгәрешләр кичерүен ачты. Мәсәлән: көнбатыш диалектка хас

---

[1] *Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань, 1985. 160 с.

[2] *Хусаинова А.Я.* Лексико-семантическая система татарских говоров Оренбуржья: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2015. 22 с.

*зәрә* (таң) сүзе шарлык сөйләшендә тагын *кен зәрәсе* (көн яктысы) дигән синтаксик деривациягә дучар булган һәм яңа сүз ясалган. *Баплы* – уңган, булдыклы сүзе каргалы сөйләшендә *баплану* – иркәләнү мәгънәсен алган һ.б.

Автор һәр сөйләшнең үзенә генә хас булган лексемаларның да составын баета.

Биредә ана сөйләшкә хас диалектизмнар сакланып килә: *йорт* – ишек алды, *йабу* – камыр ашлары пешерү, *пикеш* – чүлмәкнең бер төре, *дәдәй* – абзый, *т'ут'ыш* – түтәй һ.б. шарлык сөйләшендә, *сәwәнәйле уйнау* – өс киемен алыштырып танытмыйча йөрү, *ушы* – бу, *тақыйа* – түбәтәй һ.б. каргалы сөйләшендә, *битйаулық* – сөлге, *бәллү* – бишек һ.б. богрыслан сөйләшендә һ.б. Шулай итеп татар диалектологиясендә беренче мәртәбә күчеп утыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән сөйләшләргә махсус күзәтүләр уздырылды.

Бу юллар авторы үзе дә Оренбург өлкәсендә экспедицияләрдә булып күзәтүләр уздырган иде (З.Р. Садыйкова белән 1964 елда, А.Я. Хөсәинова белән 2014 елда). Автор күрше сөйләшләрне (1978 елда Самара өлкәсендә 2 ай, 1968–1969 һәм 1971–1972 елларда Башкортстанның Бишбүләк, Бәләбәй, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Ишимбай, Күмертау, Мәләвез, Татарстанның Баулы районнарында 6,5 ай) экспедицияләр уздырып, җентекләп өйрәнгән иде.

Күрсәтелгән районнар Оренбург өлкәсе белән берлектә үзенчәлекле зур ареалны хасил итәләр, аларда урта һәм көнбатыш диалектларга карый торган авыллар аралашып утырганнар.

**Сузыклар.** Бәлки көнбатыш диалектның тәэсире белән дә бәйледер, сөйләшләрдә ачык *а* куллану активлык күрсәтә.

Билгеле булганча, *а* авазының татар сөйләшләрендә берничә варианты бар[1]. Алар әле һаман да эксперименталь юл белән тикшерелмәгән хәлдә кала бирә. Мәсәлән, каргалы сөйләше вәкилләре арасында, нигездә Казан арты, Саба, Мамадыш төбәкләреннән чыккан татарлар күпчелекне алып торалар. Мамадыш төбәгендә *а* авазы, әдәби тел белән чагыштырганда,

[1] *Рамазанова Д.Б.* Урта Кама тирәсендә татар сөйләшләре: дис. ... канд. филол. наук. Казан, 1968.

көчлерәк иренләштерелә. Оренбург краенда бу көчле иренләшү сакланмаган.

Көнбатыш диалектка хас ачык *а* шарлык сөйләшендә тотрыклылык саклый.

Бу вариантларның барысын да З.Р. Садыйкова җентекләп күрсәтә[1].

Оренбург төбәге татар сөйләшләрендә иренсезләштерү тенденциясе *о, ө ~ у, ү* тәңгәллекләрендә дә актив күзәтелә. Мәсәлән, бер төркем сүзләрдә *о ~ у ~ ы*: *шолай*/*шылай* – әд. шулай, *орлау*/*ырлау* – урлау, *йоқа*/*йыка*/*йуқа* – йука (график. юка), *йымарт*/*йомарт* – йумарт (график. юмарт) һ.б.

Бу күренеш башка сөйләшләрдә сирәк күзәтелә торган мисалларда да чагыла: *қолжқаулық*/*қылжқаулық* – кулъяулык, *корка*/*кырка* – күркә һ.б.

Шарлык һәм богрыслан сөйләшләрендә: *бөгөн*/*беген* – бүген, *көңөл*/*кеңел* – күңел, *төгөл*/*тегел* – түгел һ.б.

Сүз уртасында *б* авазы алдында иренсезләштерү: *чыбар*/*чобар* – чуар, *чыбалту*/*чобалту* – чуалту, *чыбан*/*чобан* – чуан; шулай ук: *ыңгай*/*оңгай* – уңай һ.б.

Крайда *о, ө* һәм *у*/*ү* ирен авазларының үзара тәңгәл килүләре шактый актив күзәтелә: *богаз* ~ бугаз, *топса* ~ тупса – әд. бусага, *коллану*/*куллану* – куллану, *молла* ~ мулла, *тоқмақ* ~ тукмак, *нокта*/*нукта* – недоуздок һ.б.; *төбәкәй* ~ түбәтәй, *төбә* ~ түбә, *көзәтү* ~ күзәтү һ.б. Каргалы сөйләшендә югарыда китерелгән формалар, нигездә, әдәби телдәгечә.

Бу күренешләр гомум төрки характердагы закончалыклар белән бәйле.

Көнбатыш диалекты йогынтысында формалашу *а*/*ә* авазларына *ы*/*е* авазларының тәңгәл килүенә китергән.

*-ыр*/*-ер* кушымчалы фигыль формаларында: *сатырга*/*сатарга, сугыр*/*сугар, чыгыр*/*чыгар; үсәр*/*үсер, көләр*/*көлөр, тегәр*/*тегер* һ.б.

Хәл фигыль формаларында: *баргынчы*/*барганча* – барганчы, *күргенче*/*күргәнчә* – күргәнче, *аргынчык*/*аргынчак* – арганчы,

---

[1] *Садыкова З.Р.* Күрс. хезмәт. Б. 20.

*чыккынча*/*чыкканча* – чыкканчы, *бетергәнчә(к)*/*бетергенчә(к)* – бетергәнче һ.б.

Кабатлаулы фигыльләрдә: *баргыла* – баргала, *килгелә*/*килгәлә*, *йазгыла*/*йазгала* һ.б.

Аерым сүзләрдә: *йаңы* – яңа, *тотош*/*то*$^{ы}$*тыш*/*тытыш* – тоташ, *кылыну*/*кылану, кагыз*/*кийагыз*/*кагаз* – кәгазь, *сондок*/*сындық* – сандык һ.б.

Бер төркем сүзләрдә *ә ~ и, и ~ ә, э (е) ~ и* тәңгәллекләре күзәтелә. Әйтергә кирәк, бу күренешнең системалылыгы табылмый һәм, күрәсең, ул ана сөйләшләргә (чүпрәле, мамадыш) хас традицион үзенчәлекләрнең тотрыклылыгы белән аңлатыла. Әлеге тәңгәллекләрнең мисаллары көнбатыш (*нәк* – ник, *йәмерек* – җимерек) һәм урта (*кәбән* – кибән, *кәштә* – киштә, *мәләш* – миләш) диалектларга хас мисалларда чагыла.

Аерым авылларда *э ~ и* тәңгәллеге очрый: *энде* – инде, *эпи* – ипи, *эләк* – җиләк һ.б. Шулай ук борынгы күренешләрнең берсе.

Оренбург төбәге татар сөйләшләрендә дә, гомумән Урал төбәге сөйләшләрендәге кебек, тамырдагы *у*/*ү* иренләшмә сузыкларны иренсезләштерү күренеше таралган: *была* – була, *бысы* – бусы, *намыс* – намус, *былыша* – булыша, *быйақ* – бу як, *быйау* – буяу, *Быгырыслан* (< Богарыслан), *хушбый* – хушбуй һ.б.

Билгеле булганча, бу күренеш Урал алды татар сөйләшләрендә тагын да дәвам итә: *бийақ* < *быйақ* < бу як, *бийау* – буяу, *Сабан тийы* – Сабан туе, *сыw бийында* – су буенда һ.б.

Оренбург сөйләшләрендә дә сузыклардагы ирен гармониясе, нигездә, саклана: *тормыш*, *соло* – солы, *төлкө* – төлке һ.б. Тамырдагы ирен-ирен авазлары (*о*/*ө*) сакланса, аларның тәэсире белән киләсе иҗекләрдә *ы*/*е* сузыклары иренләшә.

Әлеге сөйләшләргә хас ярым иренләшкән тамыр авазларның (*о*$^{ы}$/*ы*$^{о}$*, ө*$^{е}$/*е*$^{ө}$) алдагы *ы*/*е* сузыкларына йогынтысы күзәтелми. Ассызыклап әйтергә кирәк, З.Р. Садыйкованың гаять җентекле тикшеренүләре киләчәктәге өйрәнүчеләр өчен төп кулланма ролен үтәячәк.

Билгеле булганча, төрки телләрдә сингармоник рәтләр (*ачы*/*әче*, *акрын*/*әкрен* һ.б.) азмы-күпме кулланыла. Татар телендә дә мондый янәшәлекләр күзәтелә. Шулай да калын әйтелешле

сүзләр урынына нечкә әйтелешле һәм, киресенчә, нечкә сүзләрне калынайтуның мисаллар составы белән татар диалектлары аерылалар. Мәсәлән, шарлык сөйләшендә яки аның урынчылыкларына түбәндәге сүзләр калын вариантта әйтелә: *кукай* – күкәй, *йыгыру* – йөгерү, *кырка* – күркә, *кычык* – көчек (әд. эт), *сыл'ык* – сөлек һ.б. Киресенчә: *бәлчек* – балчык, *йәр* – яр, *фәйдә* – файда, *сәлену* – салыну, *кечерткән* – кычыткан һ.б.

Түбәндәге сүзләр исә каргалы һәм богрыслан сөйләшендә, киресенчә, калынайтып әйтеләләр: *сақы* – сәке, *мазақ* – мәзәк, *табанақ* – тәбәнәк, *шал* – шәл, *хаммасы* – һәммәсе һ.б. Нечкә итеп әйтү: *йәбешү* – ябышу, *чәк кенә* – чак кына, *көңгерт* – коңгырт, *шер* – шыр (тоз), *җән* – җан һ.б.

Тикшерә торган сөйләшләрдә тагын сүз башында сузыклар өстәлү (протеза: *эчерек* – черек, *өтеру* – төрү, *эзерә* – рус. зря һ.б.) яки төшү (*йәңке* – өяңке, *йәреп йөри* – ияреп, *зат* – озат һ.б.) күренешләрендә дә үзенчәлекле мисаллар күзәтелә.

**Дифтонглар.** *Өй* дифтонгы бер аваз итеп тә, иренсезләшеп тә әйтелә: өй > *ү/ий, сүлә/сийлә* – сөйлә, *кү/кий* – көй, *күwәнтә/көйәнтә* – көянтә, *уләну/ийләну* – өйләнү һ.б.

Шарлык сөйләшенең кайбер авылларында *ай, әй, уй, өй* дифтонгларын бер авазга калдыру шактый системалы төс ала: *ул'а* – уйла, *фад'а* – файда, *бар'әм* – бәйрәм, *кат'а* – кайта, *сал'ый* – сайлый, *мун' – муйын* – муен, *ал'әнә/әләнә* – әйләнә һ.б.

Богрыслан сөйләшендә бер төркем сүзләрдә һәм туганлык атамаларында әдәби *-ый/-и (й)* урынына *-ай/-әй* дифтонглары тәңгәл килә: *әпәй* – ипи, *песәй* – песи, *угәй* – үги, *тәпәй* – тәпи, *әтәй* – әти, *әнәй* – әни һ.б.

Каргалы сөйләшендә әдәби *-ый/-ий* урынына *-ай/-әй* әйтү чикле.

**Тартыклар**. Өлкәдәге урта диалект сөйләшләрендә тартык авазларның әйтелешендә әдәби телдән аерымлыклар юк. Шарлык сөйләшендә *к, г* авазларының әйтелеше көнбатыш диалекттагыча. Кайбер авылларда нечкә тартыклар әйтелә: *кын'д'ык* – кендек, *т'ут'ыш* – тутай, *сил'ык* – сөлек, *йугат'ты, кыт'ыклау, Фат'их, Мус'а, Л'атифа* һ.б. Нечкә тартык авазлар ике сузык арасындагы позициядә күзәтелә: *баз'а* – баҗа, *наз'ум* – тирес, *Мус'а* һ.б.

Тартыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр төрле комбинатор үзгәрешләрне һәм позицион характердагы күренешләрне тәшкил итәләр.

Сөйләшләрдә борынгы төрки телгә хас әйтелешләр сакланып килә: *керпек* – керфек, *тупрак̧* – туфрак, *йебәк*/*йепәк* – ефәк, *калпак* – калфак, *Патыйма* – Фатыйма һ.б.

Алынмалардагы *ф* авазы да *п* авазына күчә: *пурман* – фурман, *нәпсе* – нәфес һ.б. Шулай да, *ф* авазының кулланылышы шактый актив: *филтә*/*пилтә* – фитиль, *пирме*/*фирме* – ферма, *ышкап*/*ышкаф* – шкаф һ.б.

Кайбер сүзләрдә *ф* > *п* һәм *п* авазы үзе дә яңгыраулашырга мөмкин: *пәлән* > *бәлән* – фәлән, *йебәк* – ефәк һ.б.

Сөйләшләрдә *м* авазының кулланылышы белән бәйле түбәндәге тәңгәллекләр бар.

*п* ~ *м*: *пич*/*мич, пичкә*/*мичкә*;

*м* ~ *б*: *мынан*/*менән* – белән, *малан*/*балан, мөре*/*бөре, чымылдык̧*/*чыбылдык* һ.б.

*н* ~ *м*: *калын*/*калым, агын*/*агым, ынтылу*/*омтылу* һ.б.; шарлык сөйләшендә *нөгез*/*негез* – мөгез.

*м* ~ *н*: *тырмау* – тырнау, *җ̧илем* – җилен, *үләм* – үлән һ.б.

Бер төркем фонетик үзенчәлекләр яңгыраулаштыру-саңгыраулаштыру белән бәйле.

Мәсәлән, *з* ~ *с*: *җ̧иләз* – җиләс, *баскыз* < *баскыс*/*баскыз* – әд. баскыч һ.б.

*п* ~ *б*: *потак*/*пытак* – әд. ботак, *пот*/*пыт* – бот, *пөтөн* – бөтен һ.б.

*г* ~ *к*: *чугыну* – чукыну, *тыг(ы)рык* – тыкырык, *игенче* – икенче, *тугу* – туку, шарлык: *тугызан* – әд. туксан, *сигезән* – сиксән һ.б.

Оренбург татар сөйләшләренә, нигездә, *җ̧*-ләштерү хас, ул *й*-ләштерү хас булган көнбатыш диалектка карый торган шарлык сөйләшендә дә күзәтелә, ләкин ул аффрикат аваз булып әйтелә: *дҗ̧ир*/*йир* – җир, *дҗ̧әй* – җәй, *дҗ̧әйәү* – җәяү, *мәрҗ̧ен*/*мәрдҗ̧ен* һ.б.

Оренбург татар сөйләшләрендә тагын авазлар төшү, охшашлану-охшашсызлану, авазларның урыны алмашу (метатеза) һ.б. күп кенә күренешләр табыла.

**Грамматик үзенчәлекләр.** Оренбург өлкәсендәге татар сөйләшләре грамматик үзенчәлекләре белән әдәби телгә якын торалар, сүз төркемнәренә хас грамматик категорияләр, аларның ясалышы татар әдәби телендәгечә.

Исемнәрдә һәм алмашлыкларда икеләтелгән тартым кушымчасы куллану күзәтелә: *аш урнысы* – аш урыны, *өй алдысы* – өйалды, *кайсысы* – кайсы, *берсесе* – берсе һ.б.

Тартымлы исемнәрнең төшем килеше *-ы*/*-е* кушмчасы белән ясала: *баламы* – әд. баламны, *йөрәгеме* – йөрәгемне, *суганыңы* – суганыңны һ.б.

Татар теленең барлык сөйләшләрендәгечә, кеше исемнәре кыскара һәм аларга *и*/*ый, ич, ит* һ.б. шундый иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгана: *Сәйфи* – Сәйфетдин, *Хайбыл* – Хабибулла, *Ибәт* – Ибәтулла, *Фәткыл* – Фәтхулла, *Фәйзүш* – Фәйзулла, *Калук* – Хәлимулла, *Йарук* – Ярулла, *Хамык* – Хәмдия һ.б.

Зат алмашлыкларының юнәлеш килеше еш кына нечкә вариантта ясала: *миңә* – миңа, *сиңә* – сиңа. Каргалы сөйләшендә тагын *мийә*/*мийа*, *сийә*/*сийа*. Бу вариантлар дөбьяз, бәрәңге, Урал тирәсе татар сөйләшләрендә таралган.

Стәрлетамак сөйләше территориясе белән күрше районнарда, ягъни богрыслан сөйләшендә юнәлеш килеш икеләтелгән кушымчалар белән ясала: *миңарга* – миңа, *сиңарга* – сиңа.

Күрсәтү алмашлыкларының составы ягыннан Оренбург татар сөйләшләре күрше сөйләшләргә якын тора: *мыни, маный, мынагынак* – менә, шарлык сөйләшендә ана сөйләшләргә (Чүпрәле, Кузнецк һ.б.) хас формалар саклана: *шандый*/*шонди* – әд. шундый, *шансы* – шунысы, *шалай* – шулай һ.б.

Каргалы сөйләше *ушы* алмашлыгын куллану буенча татар теленең борынгылыкны саклый торган касыйм сөйләше белән уртаклык күрсәтә.

*Мынау*/*мынаwы* – менә ул, *анау*/*анаwы* – әнә ул алмашлыклары Урал төбәге, лаеш сөйләшләрендә дә бар. Бу формалар нугай этносы катнашлыгында формалашкан сөйләшләргә хас.

Юнәлеш килештә икеләтелгән кушымчалар куллану күрсәтү алмашлыкларында да күзәтелә: *мынарга*/*мыңарга* – моңа, *тегенәрдән* – тегеннән һ.б.

*Нәрсә* сорау алмашлыгының *нәстә, нәстә(кәй), нийәстә, нийәрсә(кәй), нәмәрсә* һ.б. вариантлары күзәтелә.

*Калай* – ничек, нинди: *Қалай матур өйләре* – Өйләре нинди матур. *Чийәләре эре калай* – Чияләре нинди эре һ.б.

Шарлык сөйләшендә борынгы *кар'ы* алмашлыгы сакланып килә. Аның вариантлары көнбатыш диалектта киң таралган, бу яктан шарлык сөйләшенең бигрәк тә Пенза мишәрләре сөйләше белән уртаклыгы күренә.

Исемнәр һәм сыйфат сүз төркемнәренең ясалышы һәм кулланылышы татар әдәби телендәгечә.

***Фигыльләр.*** Билгеле булганча, фигыль сүз төркеме үзенчәлекләргә иң бай категорияне тәшкил итә.

Кабатлаулы фигыльләр шарлык сөйләшендә көнбатыш диалекттагыча (*баргакла, укыкла, сүләкли* һ.б.), богрыслан һәм каргалы сөйләшләрендә урта диалекттагыча (*баргала, укыштыр, сөйләштер*) ясалалар.

Урал төбәге сөйләшләренә хас *-ыңкыра/-еңкерә* (эшнең ким яки артык дәрәҗәдә үтәлүен белдерә) формасы да актив кулланыла.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең II зат берлек санда тарихи чыганак варианты саклана: *барасын* – әд. барасың, *күрәсен* – күрәсең, *китәсен* – китәсең һ.б.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат берлек саны *-дыр/-дер, -тыр/-тер* (< бор.-төрки *торыр*, себер диалектларында *-ты/-те*, мордва-каратай сөйләшендә *-т*) кушымчалары ала: *Йогрып чып китәдер* (китә) *дә хатны өстәлгә выргытадыр* (ыргыта) һ.б.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче зат күплеге *-сыгыз/-сегез* кушымчасы белән ясала: *куйарсыгыз* – куярсыз, *белерсегез* – белерсез һ.б. Әлеге форма татар теленең үзәк (казан арты, бәрәңге, керәшен һ.б.) сөйләшләрендә дә, Урал төбәге (минзәлә, бөре һ.б.) сөйләшләрендә дә билгеле.

Оренбург өлкәсе татар сөйләшләрендә хәзерге заман хикәя фигыльнең аналитик формасы да бар: *-а/-ып йат-* – *а/-еп йат-*. Мәсәлән: *Эшкә китеп бара йатам* – Эшкә барам. *Көтү кайтып йата* – Көтү кайта.

Бу форма эшнең шушы моментта үтәлеп торуын белдерә.

Тикшерә торган сөйләшләрдә үткән заман формалары да татар әдәби телендәгечә: *-ты/-те; -ган/-гән; -ган иде/-гән иде*. Мәсәлән: *Мин монда туган, монда үстем. Ул үрәнгән иртә торырга*.

Дәвамлы үткән заман әдәби телдәге кебек *-а иде, -ыр иде, -адыр иде, -а торган ид*е аналитик формалар белән белдерелә; билгеле киләчәк заман *-ыр/-ер*, категорик киләчәк заман *-ачак/-әчәк* кушымчалары белән формалашалар.

Сөйләшләрдә боерык фигыль, теләк фигыль формалары әдәби телдәгечә ясала. Шарлык сөйләшендә, богрыслан сөйләше территориясенең мишәрләр һәм урта диалект вәкилләре катнашлыгында формалашкан авылларда көнбатыш диалектка хас *-ак кели, -гы кели* һәм урта диалектка хас *-асы килә* формалары, сөйләшләрнең үзара тәэсир итешү шартларында, контаминацияләшкән вариантлар барлыкка килгән.

*-асы кили: күрәсем кили* – әд. күрәсем килә, *ашасы киләми* – ашыйсы килми.

*-ма кел-; барма кели* – барасы килә*, укыма келим* – укыйсым килә.

*-ырга келә-*: *китәргә кели* – китәсе килә, *сатып алырга келисезме* – сатып алмакчы буласызмы.

*-ырга телә-*: *сүләргә тели* – сөйлисе килә яки сөйләмәкче була.

*-ырга ит-: чыгаргайтә* – чыгарга тели яисә чыкмакчы була.

*-мак бул-: ашыкмак була* – ашыкмакчы була, *үрәнмәк була* – өйрәнергә тели яисә өйрәнмәкче була.

Урта диалект сөйләшләрендәге кебек үк, каргалы һәм богрыслан сөйләшләрендә дә *-асы/-әсе, -малы/-мәле, -ышлы/-ешле* формалары актив кулланыла һәм төрле мәгънә төсмерләрен белдерәләр: хәл фигыльләрнең дә (*-а/-ә, -ып/-еп, -ганчы/-гәнче, -гач/-гәч* һ.б.) Оренбург татар сөйләшләрендә төрле фонетик һәм семантик вариантлары табыла.

Затланышсыз фигыль формалары (*-ырга/-ергә, -у/-ү*) белән дә без тикшерә торган сөйләшләр ана сөйләшләргә якын торалар, күрше камышлы, минзәлә, стәрлетамак сөйләшләре белән дә зур уртаклык күрсәтәләр.

Китерелгән күзәтүләр турында З.Р. Садыйкованың хезмәтендә (1985) бай һәм этрафлы анализ бирелгән.

**Лексик үзенчәлекләр.** Оренбург өлкәсен һәм күрше регионнарын үзләштерү тарихына багышланган хезмәтләрдән аңлашылганча[1], крайга төрле төбәкләрдән төрле этно-социаль төркемнәрдән булган татарлар күчеп килеп утырган, алар арасында катлаулы үзара тәэсир итешү процессы барган. Нәтиҗәдә төрле сөйләшләргә хас диалекталь күренешләр катнашлыгыннан торган диалекталь сүзләр системасы да формалашкан.

***Туганлык атамалары*** ике системаны чагылдыра.

Урал төбәгенә хас вариантлар: *әнә(й)* – ана, *әнәй* – әни, мама, *инәкәй* – әникәй, *әтә* – ата, *әтәй* – әти, каргалы сөйләшендә *әннә* – әни, *эттә* – әти (икеләтелгән вариантлар – борынгы формалар, алар чуваш, карачай-балкар, бабатөрки чорындагы хеттлар телләрендә теркәлгән).

***Йола, уен атамалары:*** *билге бирү* – якын туганнарны чакырып уздырган мәҗлес, шунда кодаларга кызны бирергә ризалык билгесе итеп сөлге бирәләр, *аткылану* – төркемнәргә бүленеп уйнау, *урта чартау* – алга таба сикереп-сикереп уйнау, *титаклы* – классиклы уен, *зәрә йасау* – сабантуй алдыннан йомырка җыю (чагышт.: мамадыш сөйләшендә *зәрә итү* – 1) тау башына чыгып йомырка тәгәрәтеп уйнау; 2) сабан туена йомырка җыйганда әйтелә торган такмакның беренче сүзләре: *зәр-зәр-зәрәгә...*).

***Кеше белән бәйләнешле сүзләр.*** Әгъза атамалары, нигездә, әдәби: *баш*, *кул* һ.б., *уч табаны* – әд. уч төбе (чагышт.: аяк табаны, ягъни бу ике әгъзаның функциясе кайчандыр бертөрле булган), *урта тийәк* – урта бармак, *айак бите* – аяк башының өске ягы (чагышт.: *чабата чырайы* – минз., *чабата бите* – минз., камышлы, мамадыш һ.б.), *дөбә кабыргасы* – астагы кыска кабыргалар һ.б.

*Зыңкар* – авыру, чир, башка сөйләшләрдә билгеләнмәгән, *гозер* – зәгыйфьлек, кимчелек. Күргәнебезчә, әлеге алынмалар сөйләшләрнең специфик үзенчәлекләрен тәшкил итәләр, алар мәгънә функцияләре белән дә аерылалар, чагышт.: мам. *гозер* – үтенеч.

[1] *Садыкова З.Р.* Күрс. хезмәт. Б. 160; *Рамазанова Д.Б.* Күрс. хезмәт. Б.191; *Хусаинова А.Я.* Күрс. хезмәт. Б. 22.

*Шөкәтсез* – ямьсез, *чәм* – хурлану, көнләшү, *анкау* – ахмак, *комкүз* – комсыз, *кырку* – коры (мам. *кырку* – озак кайнап ачкылт тәм кергән аш турында), *әлекәй* – аумакай, кеше сүзенә бирешә торган һ.б.

Хуҗалык эшләре һ.б.: *кәртә* – абзар, *лай өй* – саман өй, *пикеш* – чүлмәкнең бер төре, *запраткы* – шәл җебен эрләгәндә, эчкә кертеп калдырыла торган җеп, *утар* – мал ябу урыны һ.б.

***Хайваннар дөньясы:*** *оргач/ыргач* – сарык (ана булганы), *ала ат*, *бурлы ат*, *чал ат* – ат төсләре, *кырка* – күркә, *әнәч* – тавык булачак чеби, *казайак бака* – күл бакасы, *багара* – кызылтүш, *сырка* – байбак, *рака* – кысла, *пупуп* – һөдһөд, *бакашар* – соры челән, *хәүле* – челәннең бер төре, *чәкелдек* – йомранның бер төре, *сагаwык* – укра һ.б.

Күргәнебезчә, бу лексик-тематик төркемдә үзенчәлекле, специфик диалекталь атамалар күп табыла.

***Үсемлекләр дөньясы:*** *кыр кишере* – *җонлы бәрәңге* (бутень клубненосный), *казчәй* – сөтле билчән, *сүwәрби/сийәрби* (< рус. свербига) – ачы какы, *йара үләне* – бака яфрагы (мам. шулай ук), *дүңгелди* – песи борчагы, *дурман* – тиле бәрән орлыгы; *карагай* – нарат, *чаган* – өрәңге, *бүтәкә* – русча белоус, *майран* – дүләнә һ.б.

***Кием-салым:*** *хөрти* – җиңсез камзол, *wәл* – мамык шәл, *чарык* – күн аяк киеме һ.б.

***Аш-су:*** *бөкөри* – зур пирожок, чагышт.: кмшл. – шулай ук, *паштик* – пирог, *самбуса* – бөккән, *чокорча* – ачы камырдан творог белән пешерелгән пәрәмәч, *көләчә* – көлчә, *кыйгыча* – кош теленең бер төре, *уралма/уратма* – рулет, *пичунка* – көлдә пешкән бәрәңге, *шеш* – туй мәҗлесенең тәмам булуын белдереп бәлеш өстенә махсус утыртып куелган камыр кисәкләре һ.б.

Каргалы, богрыслан, шарлык сөйләшләре буенча тупланган бай фактик материаллар тугандаш телләрнең, аерым сөйләшләрнең үзара тәэсир итешүе закончалыклары, күчешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән сөйләшләрнең, ана сөйләшләр белән үзара мөнәсәбәте кебек, теоретик мәсьәләләрне тикшерү өчен әһәмиятле чыганак булачак.

## Сөйләү үрнәкләре

### *Әңкәй бәгрем*

Әңкәй, бәғрем, өзләп сағынам сине,
Изге нурлар тулған йөзләрең.
Белсәң ийе ничек күрәсем килә,
Шәфкәт нуры тулған күзләрең.

Күз алдымнан китми синең гәүдәң,
Шундый ачық сыман күренә шул.
Ә йөзөңнән, моңсу күзләреңнән
Шундай матур нурлар сибелә шул.

Озаққамы болай айырым йәшәү,
Озаққамы сузылыр сағынулар.
Ғөмөр үткәнлеген сөйли-сөйли
Тағын күпме сулар ағырлар.

Тиздән мин сине қочармын,
Йәшле күзләреңдән үбәрмен.
Йомшақ сачләреңне сыйпый-сыйпый
Қайттым, әнкәй бәғрем, дийәрмен.

Күпме нечкә хисләр, изге уйлар,
Нинди сизгер йөрәк аларда.
Бала-бала дийеп көйә-көйә,
Аналарның саче ағара.

Қайчан синең мәрхәмәтле қулың
Сачләремнән йомшақ сөйәрләр,
Қайчан мине үпкән йомшақ иреннәрең,
Қайттыңмыни, балам, дийәрләр.

Кичләремдә чақ-чақ күзем йомсам,
Күз алдыма килеп басасың.
Хыйалыма кереп ураласың,
Ә уйансам миннән йуғаласың.

## ***Ана күңле***

И дусларым, шигыр йазам,
Матур кошларга карата.
Шигыр йазып уку минем
Кайгыларымны тарата.

Тирәзәгә килеп кунды,
Йәшел түшле матур чыпчык.
Балаларымдин айрылып калдым
Кереп халемне белүче йук.

Өй артында матур гөлләр
Сайрарсың шунда кунып.
Шулай ғөмөр узар инде,
Бер күрергә зар булып.

И матур кош, миңа иптәш,
Сандуғач, кил, җир кипкәч,
Безгә күрешүләр кайдинде,
Җырақ җирләргә киткәч.

Ишегалдым карама,
Туқыран килеп чуқый.
Балаларымдин айрылғач,
Китә икән тәмле йоқо.

И туқыран, түшең чобар,
Қанатың икән зәңгәр.
Балаларың бергә булса,
Шунда икән бөтөн йәмнәр.

Исем китә туқыранға
Қоро ағач чуқығанға.
Җөрәкләремә җал була,
Шиғыр йазып уқысам да.

Менә тағы исем китә,
Күгәрчен гөрләwинә.
Шиғыр йазмый ниләр йазыйм,
Җөрәкнең дөрләwинә.

Йоқыларымдин уйанам,
Күгәрчен қағынғанға.
Бу шиғырләрне йазамын,
Бәбекәйемне сағынғанға.

Тугыз ай күтәреп йөрдөм,
Йегермик ай сөт имездем,
Суwықларға туңдырмадым,
Сине үстергән анаң бит мин.

Туғыз ай күтәреп җөрдөм,
Туғач ақ сөтөм имездем,
Бу ни гәҗәп, бу ни хикмәт,
Баладин қатылык күрдем.

Бала анаға бик татлы,
Туғач бар җирләрен пақли,
Бу ни ғәҗәп, бу ни хикмәт,
Ана күңлен бала тапмый.

Алар үлсен дисәләр дә,
Wақытсыз кермиләр гүргә.
Бу ни ғәҗәп, бу ни хикмәт,
Ананы сөймиләр бер дә.

Доғада утыра үзе,
Йәше белән тула күзе,
Бу ни гәҗәп, бу ни хикмәт,
Бар да йалған ана сүзе.

Ни сачсән, шуны урырсын,
Дигәннәр бит бороңғолар.
Ана доғасы мәқбүл дийеп,
Хәдис бардыр пиғәмбәрдин.

Үлем ачылары күреп,
Балам, сине китердем мин.
Аwыр, қыйын чақларында,
Балам, сине үстердем мин.

Суwық, балам туңмасын дип,
Өстөгөзгә җабар ыйым.
Балам ачқа үлмәсен дип,
Ыризықлар табар ыйым.

Атаң үлеп йәтим қалғач,
Көмәндә күтәреп йөрдөм.
Бу ни гәҗәп, бу ни хикмәт,
Баладин қатылық күрдем.

Үләргә халләрем җиткәч,
Халемни сорамый балам.
Бала бәғре қаты икән,
Бәхиллек сорамый миндин.

Балам, дидем, балам, дидем,
Башымның ғакылы бетти.
Балам бик шәфкәтсез булды,
Анаға қатылық итти.

Әйа балам, йөрәк парәм,
Ики күзем дәхи қарам,
Синең йөзең күрер өчөн,
Диwаналар булып парам.

Гөлнөң қошо гөлгә куна,
Күңел қошо ирер бала.
Күрәсең, ходай қөдрәте,
Үсеп җиткәч қулдан ала.

Бала булғач, җана бәғре,
Китәрә йәшлекнең қәдрен,
Сағыш беләә тула садрым,
Сабыр бирсен үзи алла.

Бала дийеп сүзем бетмәс,
Йөрәкнең қайғысы китмәс.
Ғақылы һәм һушың кермәс,
Сабыр бирсен үзи алла.

Бала ғөмөрне уздырыр,
Җөрәк майыңны сыздырыр.
Ни шатлықтан да биздерер,
Сабыр бирсен үзи алла.

Қызыл булмаса иде,
Сачелеп тормаса иде,
Бери әҗәл, бери фәрқәт,
Бу ике булмаса иде.

*Гатия әби мөнәҗәте.*
*Абдуллино районы Чаганлы авылы.*
*Эксп., 1964*

# ТАТАРСКИЕ ГОВОРЫ ОРЕНБУРЖЬЯ

*Галина Мельникова*

Татарские говоры Оренбуржья были исследованы З.Р. Садыковой в 1964–1986 годах для составления Диалектологического атласа. Опубликована монография «Говоры Оренбургских татар»[1] и ряд статей, где описаны фонетические, грамматические особенности татарских говоров Оренбуржья в сравнении с другими диалектами татарского языка и некоторыми тюркскими языками; нашел отражение и лексический материал.

В 2013–2015 гг. А.Я. Хусаиновой было проведено исследование лексики татарских говоров Оренбуржья с точки зрения специального исследования лексико-семантической системы указанного ареала, и защищена кандидатская диссертация[2].

На территории Оренбургской области выделяются три самостоятельных говора татарского языка: бугурусланский говор среднего диалекта, каргалинский говор среднего диалекта и шарлыкский говор западного диалекта.

Бугурусланский говор среднего диалекта татарского языка распространен на севере Оренбургской области. Во время экспедиции были посещены населенные пункты Сарманаево (Сарманай), Зерикло (Татар Зиреклесе), Мустафино (Мостафа) Шарлыкского района, в которых распространен данный говор. Лексический состав бугурусланского говора в основе своей со-

[1] *Садыкова З.Р.* Говоры оренбургских татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. 157 с.

[2] *Хусаинова А.Я.* Лексико-семантическая система татарских говоров Оренбуржья. автореф… дис. канд. филол. наук. Казань, 2015. 22 с.

стоит из тюркских слов и заимствований. Здесь нами приведены некоторые лексические особенности, зафиксированные в ходе экспедиции, которые мы представили в виде лексико-тематических групп. Лексика говора проявляет общность с говорами Приуральского ареала, а также со смежными мензелинским, камышлинским, стерлитамакским и шарлыкским говорами.

Термины родства: *инәй* – мама, мать, *зур инәй / зурнәй* – бабушка, мать отца или матери, *үгәй зурнәй* – неродная бабушка, вторая жена деда, отца матери или отца, *зурәти* – дед, отец отца или матери, *йырақ әби* – бабушка, мать матери, *йырақ бабай* – дед, отец матери, *олан* – ребенок, *бийем* – свекровь, мать мужа, *биатай* – свекор, отец мужа.

Лексика, связанная с хозяйством: *битъяулык* – полотенце, *бидрә/бидыра* – ведро, *печ* – печь, *түр юрганы* – лоскутное одеяло.

Названия рыб: *шамбы* – налим, *табан балық* – карась, *қорбан балық* – лещ, *қара балық* – линь, *опто* – язь.

К словам, обозначающим абстрактные понятия, можно отнести словосочетание *зыйан чүлмәге* – шкодница (например, о козе).

Каргалинский говор среднего диалекта татарского языка распространен на юге и юго-востоке Оренбургской области. Нами были посещены населенные пункты Татарская Каргала (Каргалы), Верхние Чебеньки (Үрге Чебенле) Сакмарского района, Ново-Кульчумово (Кылчым), Шишма (Чишмә), Кабанкино (Кабан), Биктимирово (Биктимер), Никитино (Рәдүт), Аблязово (Әбләз) Саракташского района, в которых распространен каргалинский говор. Лексический состав каргалинского говора очень близок к татарскому литературному языку. Большую часть диалектальных слов составляют татарские слова и корни. В говоре употребляется также и заимствованная лексика.

Термины родства: *инәкәй/әнкәй/әнәй* – мама, мать, *әткәй/әтәй* – папа, отец, *картинәй/картнәй* – бабушка, мать отца или матери, *зур әнәй* – бабушка, мать отца, *йырақ әнәй* – бабушка, мать матери, *қартәтәй* – дед, отец отца или матери, *бием/әни* – свекровь, мать мужа, *биата/әти* – свекор, отец мужа, *әби* – теща, мать жены, *бабай* – тесть, отец жены, *иркә* – младший брат

или сестра, *абый* – старший брат, *апай* – старшая сестра, *абзый* – двоюродный брат, *токым* – род.

Названия пищи: *кымыс* – кумыс, *ләwәш* – закрытый сладкий пирог, *бүкән* – беккен, *бәлеш* – пирог, пәрәмәч – 1) открытый пирог с начинкой из творога, яиц и сметаны; 2) пирожки с начинкой из мяса, жареные в масле, *ипи* – ржаной хлеб, *күмәч* – пшеничный хлеб, *сумса* – маленькие пирожки, *кысыр аш* – постный суп, *қазы* – колбаса, *кызыл эремчек* – красный творог, *сөзмә* – катык, вид кисломолочного продукта.

Термины, связанные с хозяйством: *қалақ* – ложка, *кәнди* – тарелка, миска, *айақ* – большая металлическая посуда для замешивания теста, *тула* – тряпка для мытья пола, *фәрдә* – шторы, занавески, *каса* – пиала.

Флора и фауна: *күгән* – терн, *йеләк* – ягоды, *йимеш* – фрукты, плоды, *алабуга* – окунь, *йәйен* – сом, *йедәй* – боярышник, *бөрлегән* – ежевика, *чүкә* – щука.

Термины, связанные с вязанием пуховых платков: *шал/шәл* – шаль, пуховый платок, *дебет* – пух, *айа* – треугольная ческа, *шапалақ* – прямоугольная ческа, состоящая из двух частей.

Названия игр: *туплы уен* – игра в мяч, *бүкәнле уен* – третий лишний, *наза уен* – ручеек, *йөзек салыш* – колечко.

Абстрактные понятия: *чак кына* – немножко, чуть-чуть, *биш йарым* – половина шестого, *матакай* – мотоцикл, *аш булсын* – кушай на здоровье, *рәхмәт яwгыры* – спасибо, благодарю, *чекәннәп* – прыгать на одной ноге, *кыйммәтчелекле* – дорогой, *кичкелеккә* – вечером, на ужин, *өйләгә* – на обед, *удаwа* – вдова, *йыбану* – лениться, *әшнә* – друг, *әүкәй* – друг, задушевная подруга, *спыртқа* – на экспорт.

Шарлыкский говор западного диалекта татарского языка распространен практически на всей территории Оренбургской области. В ходе экспедиции мы посетили населенные пункты Новомусино (Яңа Муса) Шарлыкского района, Султакаево (Султакай), Яфарово (Яфар) Александровского района, которые относятся к шарлыкскому говору западного диалекта. Диалектная лексика шарлыкского говора состоит главным образом из слов и корней тюркского происхождения, а также заимствований. Лексика относится к разным областям жизни носителей говора.

Термины родства: *инәй* – мама, мать, *әтәй* – папа, отец, *картнәй* – бабушка, мать отца или матери, *карттәй* – дед, отец отца или матери, *зурапа/тәтәй* – старшая сестра отца или матери, *түтеш* – младшая сестра отца или матери, *кечанай* – жена брата отца, *нука/оныка* – внук, *дәдәй* – 1) старший брат отца или матери, 2) родной старший брат, *абзый* – двоюродный брат, *бырат/энем/туганым* – младший брат, *агайне* – родственники.

Лексика, связанная с хозяйством: *эргә* – фундамент, *ызба* – дом, *йырт/йерт* – двор, *шаwа* – миска, посуда, *шыша* – бутылка, *бидра/бидыра* – ведро, *дисбе* – бусы, четки, *виранда* – двор, *пул* – скамейки в бане, *мийеш* – угол, *винек* – веник, *кухна* – летняя кухня, *лафкачы* – продавец.

Названия пищи: *таба ашы* – блюда, приготовленные на сковороде, *катык* – вид кисломолочного продукта, *коймак* – оладьи, *ләwәш* – пирог со сладкой начинкой, *белен* – блины, *күмәч* – хлеб, *пәрәмәчә* – открытые пирожки с начинкой из картофельного пюре, жареные в масле, *питрас/питырас* – квадратики из пресного теста, *самса* – маленькие пирожки.

Названия растений: *кузгалдак* – щавель, *чәчкә* – цветы, *элән* – лен.

Названия игр: *зилем әйләнү* – весеннее мероприятие, которое проводится во время разлива рек на возвышенности, открытом месте, *шыша тәгәрәтү* – игра в бутылочку.

Абстрактные понятия: *йафалану / нужа куу* – нуждаться, мучиться, *күкәй эчендәге сары* – неспособный, *нык матур* – очень красивый, *кыйлы* – килограмм, *гайланып китү* – выздороветь, поправиться, *йәйәү* – пешком, *холыксыз* – непослушный, своевольный характер.

**Образцы текстов**

Йул буйында сарықлар йата диб уйлыйсың / ә сарықлар йатмый анда / сарық көтүwе кебек таш йата / тезелеп тау битендә / кеше уйлый шуны сарық йата дип / ә дийствитилнә анда ақ таш йата // шуның өчен теге ақ сарықларға сарақташ дип қуштылар татар сарақташына //

*Кутлукаев Закир, 1936 г.р.*
*с. Шишма, Саракташский район*
*(каргалинский говор)*

Бер вахыт внук / вилдан исемле / бәләкәйрәг иде / печән апқайтырға барабыз ат белән / үземнең ат барыйе минем / қолын барыйе моның / атның баласы қолын диб атала инде / атның баласы // тегендә дальшерак бер күпердән чығабыз инде / бераз барды инде / ат чаба / ат қызу иде минем / бераз барғач / хәзер / бу малай әйтә бит инде / внук / зур эти диб сөйләнде дә қалды ди / мин колын диб уйлыйм бит / мин әйтәм йарар қалса / йөрер әле / йөремәсә арттан килә ул / килмәсә мин әйтәм кайтып китә ул / өйгә кайта ул дидем дә / хәзер барып җиттек / туқтадық ат белән / зур эти нәрсә белән төйәбез ди / мәйтәм сәнәк қайа / сәнәк бит төшеб қалды / мәйтәм нишләб әйтмәдең миңа аны / мин бит сиңа әйткән ийем ди / қалды диб ди / син бит ул қалса йарар / үзе йөри йөри үзе килә ул / килмәсә қайтыб китә ул // мин килеп җиткәнче аптыраб килдем сәнәк ничек арттан килә икән ул дип мин әйтәм / хәзер борылдык та / сәнәкне алып / мин аны қолын диб уйлыйм / ничег инде ул сәнәк арттан килә икән ди // мин аwылнықы инде аканчателнә / эш йуқ йәшләргә / тегендә эш бар / қыз тужы ике институт бетерде / тегендә эше дә бар / квартир бирделәр / менә безнең йылға / река неть диб атала ул / ул теге йақтан аға ул / әнә үлән басыб беткән / қазлар җәйәү йөриләр / күптән безнең йаңғыр йауған йуқ / ходай бирде / шуңа қуанып рәхәтләнеп / чыланыб йөрим / балығ бар монда // бақчам әйбәт / бақчам бар минем //

*Бикмухаметов Ильдус, 1952 г.р.*
*с. Мустафино, Шарлыкский район*
*(бугурусланский говор)*

Миңа сиксән өч бара хәзер / алты айы үтте инде // ой балақайем без яшь wақыт / бөтенләй бала wақытта / минем эти мәчеттә хәзрәт ийе ул / ул барыб манараға менсә / мин дә менеп шунда тора ийем // шуннан соң ийе / аңардан соң / ул манараны аударып / ул мәчетне мәктәп йасап шулай иттерергә булдылар инде // менә шул бу wақытта без барып эти белән қарап тордык та / эти йылый бит / шуңардан соң ул анда барып йөрмәде / аны хәзрәтлектән чығарып ташладылар // аннан суң / менә нәрсә диб әйтәсең инде / шуннан соң эти мәрхүмне шуннан

алдылар да / монда пожарный итеп қуйдылар // ну шуңардан соң нәрсә килә инде / суғыш башланған wақыт инде / суғышқа халықны алдылар / аны да хәтерлим шуннан инде // нәрсә диб әйтәсең тағын / аларны ничег диб әйтәсең инде / эти мәрхүмне трутармийәгә алып киттеләр / вот / ә Шәгыйлман абый мәрхүм әнә шул эш бетүенә бер нәрсәгә қарамастан армийәгә чығып китә / вот / Шагыйлман абый сугыш та күрми исән сау монда қайтып / монда үлә инде / бер сүз белән әйткән wақытта // ә эти мәрхүм нәрсә диб әйтим / кырығ ике үтеп китте / кырығ өч бара инде / кырығ өченче йылда этидән хат килде инде / март айында / и мартның умбишләреме / купмеләре булғандыр / март урталарында ужыэти мәрхүмнән безвисти пропавший дигән исем килде // мин эшли башлағанда / тәүгедән күлим әле / аннан сүлим әле / мин эшли башлаған wақытта / әни мәрхүм / улым син менә эшли белгән кешеләр / қартлар бар бит безнең / менә нигъмәтуллин шәмсетдин бабай / ул абый молотилкада / шуннан соң инде шундый ниләр / тырмалар / ниләр / и зур иләк тазарта игеннәрне менә / син карап тор / кара / күр / во / син аларны үзең эшли алырсың // әни мәрхүм минем шулхадәр тырыш ийе ул / ширинбану исемле / аның этисе ситдыйқ / алар рәхмәтуллиннар иде // минем исем күтеп алынған мәгънәгә килә / ни өчен дигәндә / минем алдымда өч абыйым булған / алар һәрқайсы тормағаннар / ә апаларым торғаннар инде // менә шушы йортны салған wақытта әни / шакирә апа / өчәү қалдық // суғыш wақыты да / безгә ни ашарға / ни эчәргә / ни кийәргә / ни йығарға йуқ бит инде // без бик йығар идек / ә җибәрмиләр ийе урманға / ә инде ашау эчү йағы ул бөтенләй начар булдыйы / инде ул wахытта аны әйтеп тора торған түгелийе / без бирешмәдек / бирешмәдек без // йаз көне без башаққа йөри башладық / әни белән мин / хәтеремдә уналтынчы март көнне қырығ өченче елның / уналтынчы март көнне беренче мәртәбә башаққа чығып киттек // шулай итеп күпме булдыра алабыз / шулай күтәреп апқайттық / киптереп ашап // ну қырығ өчтә туже бирешмәдек //

*Мухаметов Гакыйп, 1932 г.р.*
*с. Ново-Кульчумово, Саракташский район*
*(каргалинский говор)*

Әти сугышка киткәндә мин биш көнлек калдым / биш көнлек / вәт / кырыг беренче елны / беренче синтябрьдә / Ленинградка / Ленинградны ишеткәнең бармы / вәт / строитель мин гомер буйына / үрнәктә тудым / элекке комуна / әтинең кем икәнлеген белмәдек без / вот шул // вот шулай гомерләр узды / җитмеш дүрт яшь тула синтябрьдә // менә хатын да тайак / кереп китәм / кереп китәм ди // минем әтиемнең абзыйсының хатыны кечанай була / минем әтинең абзыйсының хатыны / ә абзыйсы дәдәй була / дәдәй дибез / әтинең абзыйсына дәдәй дибәтәбез // әтисенең сеңеле түтеш була / түтеш / әтинең әнинең сеңелләре түтеш була инде // кара кигәwен кунган / кигәwен талабүтерә бит үзеңне // әдә сеңелем чәй эчеп кит / сусыз йөремә / главный су // ә мин денгә бәг ышанмыйм / мин денгә каршы / искелеккә бару ул / чабата киенү була / син чабатаны беләсеңме нәрсә / лаптига кабат күчерергә уйлыйлар халыкны // мине көп шулар алдадылар динлеләр / дини халыклар / намаз укый / намазга баскан / ә үзе акча ала працинтка дип / кача / шуңа күрә мин денгә каршы / ух // сет ашы / таба ашы коймак диләр / ләwәш / таба ашы ләwәш / пирук / ләwәш менә кузгалдак ләwәше була / йасыйбыз / кузгалдак йафрагы / урысча пирук ә безнеңчә ләwәш / ләwәшне духовкага тыгасын / чәwел белән // типтәр / нацияне беләсенме типтәр / шулар башкирия ягыннан килеб утырганнар / ә безнең / менә безнең тумыш / менә минем нукам ужы җиденче буын / кыз балага внучка дибез / безнең бабалар пензадан / безнең йахъйа бабай килгән / мең җидейөз ничәнче еллар / адʹа карыйбыз / минем дә эчкем кили / аwзым кепте / адʹа // мин канʹаган су гына чәм / шуны бел / канʹаган су гына чәм / мин холодныйны вадаправоттан эчмим // Йахъйа бабайдан безгә калган фамилия йахын // сүлә син / сүлә Рәшидә / кличкасы тайак / аның бабасы теге көнбагыш / көнбагыш бит кояшка карап ничек әйләнә / ул да шулай / туп туры йөрегән / тайак / көнбагыш тайагы кебек / прустой тайак тегел / көнбагышныкы / эче буш / ике митыр озынлыктагы халык алар / бу да миннән озын // бу минем нукам / бәләкәй малайның бәләкәй малайы // минем исемем Зинит / ник Зинит кушканын беләсенме син / историясен / сугыш вакытны безнең зенитный артилерияләр немец самалетларын

бәреп төшерә башлаганнар да / шуннан бер апай / бу малайга давай Зинит куштырабыз дигән / ват миңа Зинит кушканнар // ә күрше тирә / карт коры / Зинәтулла дип йери / Зинәтулла тәк Зинәтулла // без пенза мишәрләре / мишәр без // шул күпернең бу йагы типтәр диләр / ә теге йагы йаңаwыл / ә теге центрга базар эче / шакшак эче // типтәр дә бар / мишәр дә бар / татар да бар / типтәр халкы башкириядән килгән // ә менә без тарханнар / пензадан / пенза мишәрләре тарханнар // нукама ызба салып бирдем ужы / ват // үлгенчи йафаланабыз / нужа куабыз дигән сүз // зилемдә / зилем кулга кул тотынышып әләнәсең / җир ачылгач / күпер өсләрендә җир ачыла бит / тау башына менеп / кастерлар йагып шунда / тау башында зилем / ташу ташыганда / гармунчы булмаса такмак / хур белән такмак әт'әләр / вет шулай //

*Яхин Зенит, 1941 г.р.*
*с. Новомусино, Шарлыкский район*
*(шарлыкский говор)*

Шунда туыб үстем / әйе / чистый татарлар монда килгән халык кына // кызым кил / бер апай белән күреш // бабай белән сүләргә ыйалмый ул / бабай белән оста сүли / минем оныкам бар казанда / баныкта эшли / ә нидә туймазыда бар внукларым / алар яны йерт салдылар // бу аwылда туыб үстем / әтийем сугышта йугалды / үлде инде / сугышта үлеп хәбәре килде / ват // тагы ни сүлим / мин инде аwылда эшләдем / эшләмәгән эшем калмады / ну ул вакытта гел на общественных началах иде // үзем в основном шул ике аwылның егерме ел бригадир булып эшләдем / учетчик та булдым / сет тә ташыдым / аннан заведущий фермы булдым / народный контрольдә булдым / районда засидатил булдым / сугыш йылларында обеспечение йуг иде / икешәр класс бер класста укыдык / бер помещениедә бер укытучы укыта иде / дүрт кенә класс иде ул вакытта образованийе / дүрт кенә класс иде // тукайда бер йел укыдым бишенчене / алтынчыны зеленарощада укыдым // тагын ни / аннан инде / шул пинсийәгә чыгар йылны / авырдым да / Айрат абый ничек булса да йөрерсең инде / бәлки гайланып китәрсең / бәлки ниткәч / айак бил белән мин мучитса идем / ну мин эшли алмадым / авырдым / ташладым /

шуннан пенсийәгә чыктым // аwылда мин иң олы кеше инде / мужской яктан инде // женщиналар бар // минем нием буйынча / бабам минем мусаныкы / мусаныкы wыл / ә әбийем булган султакайныкы / әби лафкачы булган / бабай әбине тапкан да шунда калган / минем бабай шуннан йәйәү килә иде / әйе // дәдәй вәт / например минем олы абыйем булса дәдәй була миңа / дәдәй була әйе / монда күбесе миңа дәдәй дибәтәләр / дәдәй дип йөртәләр // мусада безнең агайнеләр бар анда / шундый хал′ // синең исеңдә тегелме / килеп килеп күренәләр / торналар / бездә торналар йәйен үткәриләр // тотабыз / сарыклар тотабыз / кәҗәләрне бетердек / сбыт йук / алмыйлар / хәзер халык күбәйде / күп тоталар / вәт //

*Сафаров Айрат, 1932 г.р.*
*с. Султакаево, Александровский район*
*(шарлыкский говор)*

# ЕЛЛАР ҮТКӘН ХАЛЫК ЙОЛАСЫ

## Оренбург сөйләшләрендә халык традицияләре һәм фольклор (этнолингвистик аспектта)

*Флера Баязитова*

Оренбург өлкәсе Евразиянең үзәгендә, көнчыгыш белән көнбатыш кисешкән бөек ефәк юлы өстендә утырган. Әлеге өлкә төньяк-көнбатышта Татарстан, төньякта Башкортстан Республикасы, төньяк-көнчыгышта Чиләбе өлкәсе белән, көнбатышта Самара, көньяк-көнбатышта Саратов өлкәләре белән, көнчыгышта һәм көньякта Казакъстан республикасы белән чикләнә.

Оренбург өлкәсе Россия Федерациясенең зур регионнарыннан санала. Биредә татар культурасының күренекле шәхесләре турында тарихи истәлекләр саклана. Мәсәлән, Шарлык районы Мостафа авылында герой-шагыйрь Муса Җәлил туып үскән. Авылда аның истәлегенә бик зур мемориаль-музей ачылган. Оренбургта Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге татар драма театры эшли.

Бу төбәкнең табигате бай һәм үзенчәлекле. Биредә дәвалау үзенчәлекләре белән танылган Соль-Илецк (Тозтүбә) тозлы күле бар.

Оренбург өлкәсе – күпмилләтле, биредә 126 милләт яши. Күп өлешен бөтен өлкә буйлап сибелгән татар халкы алып тора. Төбәктә 150 меңнән артык татар яши, барлыгы 88 татар һәм 63 катнаш авыллар бар.

Оренбург өлкәсендәге татар сөйләшләрен беренче булып Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел,

әдәбият һәм сәнгать институтының тел белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Зидә Рәшит кызы Садыйкова өйрәнде.

Зидә Садыйковага моңа кадәр беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән Оренбург татарлары сөйләше кандидатлык диссертациясе темасы итеп бирелә. Ул Оренбург өлкәсендәге 70 ләп авылны монографик планда да, «Диалектологик атлас» төзү өчен дә лингвистик география методы белән өйрәнеп чыга. Озак еллар экспедицияләрдә йөреп, авыл халкы белән аралашып бик күп материаллар туплый. 1985 елда аның «Говоры оренбургских татар» дигән фәнни китабы басылып чыга. Әлеге хезмәт җәмәгатьчелек кулына кереп, әйбәт бәяләмә алгач, 1986 елда шул ук темага (кушымталар: 50 картадан торган атлас, шәл бәйләү үрнәкләре һ.б.) кандидатлык диссертациясен яклый. Аны да аспирантура курсы үтмичә, төп эшеннән аерылмыйча яза. Зидә Садыйкованың тикшеренүләре нәтиҗәсендә бу зур территориядә татар теленең ике диалекты (урта һәм мишәр) сөйләшләре таралган булуы ачыклана.

Оренбург өлкәсендә таралган җирле сөйләш үзенчәлекләре башка төрки телләр белән мөнәсәбәттә өйрәнелә. Мәсәлән, башка диалектларда күзәтелмичә, бары тик Урал һәм Сакмар буйларында яшәүче Оренбург татарлары сөйләшләрендә генә кулланыла торган *-акай (-әкәй)* формалы сыйфат фигыльнең күп кенә угыз һәм кыпчак телләрендә дә кулланылуы ачыклана. Бу борынгы сыйфат фигыль формасы Себердә таралган төрки телләрдә дә күзәтелә. Аннан тыш *-акай* формалы сыйфат фигыль (*киләкәй кеше* – килә торган кеше, *пешерәкәй әби* – пешерә торган әби) төрек, гагауз (*-ка*), якут (*-аай, -маай*), кыргыз, алтай, хакас, шор, тува, тофалар, чулым-татар (*-гай, -кай, -багай, баай*), кырым татарлары, каракалпак, карачай-балкар, караим (*-гай*), казах (*-кай*) телләрендә актив кулланыла. Болар барысы да җирле сөйләшләрне башка төрки телләр белән бәйли торган фәнни ачышлар булып тора.

Зидә Садыйкова үзенең тикшеренүләрендә лексик үзенчәлекләрне тематик яктан, башка төрки телләр белән чагыштырып өйрәнүгә дә зур өлеш кертә. Аның тарафыннан, беренчеләрдән

булып, Оренбург өлкәсе өчен характерлы булган кәҗә мамыгын эшкәртү, шәл бәйләү терминологиясе, бизәк атамалары һ.б. фәнни әйләнешкә кертелә.

Халык традицияләрен саклау һәм үстерү, культура казанышларының синтезын булдыру, халыкларның дуслыгын ныгыту хәзерге заманның приоритетлы бурычы итеп куела. Төрле халыклар арасында икътисади һәм сәяси килешүләр белән генә түгел, рухи байлыклар белән дә уртаклашып яшәү сорала.

Бүгенге көндә туган телебез саегып бара дип саналган чорда халыкта сакланган һәр лексик берәмлек язылып, күтәрелеп, текстлар, иллюстратив материаллар белән бергә киләчәк буыннарга тапшырып калдырылырга хаклы. Тематик төркемнәрне өйрәнеп чыгу нәтиҗәсендә бик тә әһәмиятле борынгы катлам – сүзләр һәм сүзтезмәләр, лексик-семантик «оялар», терминнар күтәрелә. Алар исә тарихи лексикология, тарихи этнография һәм тарихи фольклор өчен дә бик зур хәзинә. Кадерен белгән кешеләр, рәхмәт әйтеп, тиешле урында файдаланырлар дип уйлыйбыз.

## Гаилә йолалары. Туй

### *Йаучы*

– Элек йаучы булып бер ир кеше килә иде. Бер балағын өскә күтәргән, берсен төшергән. Йаучы икәнен шуннан беләләр инде. Ул бер көн генә килми эле, қат-қат килә. Тегеләр риза булғанчы килеп йөри. Җайлап сөйләшә.

Менә минем үземә бер атна йөрде йаучы.

«Мин бер зур йомыш белән килдем, қызығызны сорарға килдем», – ди (*Мостафа*).

### *Сөлге бирү*

– Қыз йағында риза булсалар, сөлге бирәләр. Сөлгене иңенә салып, қайтып китә инде йаучы. Көтеп торалар қайтқанын (*Мостафа*).

### *Башкода, башкодалый килү*

Башкодалый киләләр йегетнең ата-анасы. Менә миңа килделәр. Әнийем ат′а: «Тизерәк мен пич башына».

Кан′ана-кан′атага күренү йук кушылмича.

– Башкода килә. Йастык салалар. Түргә менеп утыра. Бер балагы күтәргән (*Яңа Муса*).

### ***Киңәш***

– Бер килгәндә генә бирмиләр ризалыкны. Агай-эне белән киңәш кирәк. Киңәшеп бирергә риза булалар (*Яңа Муса*).

### ***Билге, билге бирү***

– Кызның билгесен бирәләр. Билгегә пирчәткә, битсеберләр (сөлге), шарфлар бәйләгән, ак шәлләр, кулйаулык чиккән (*Яңа Муса*).

### ***Билге күрсәтү***

– Кийәү йортында билге күрсәтәләр (*Яңа Муса*).

### ***Көн куйу***

– Көн куйарга киңәшәләр. Кас′ы көнне туй (*Яңа Муса*).

### ***Кодалашып йөрү***

– Йаучы килеп кызны килешкәч, кодалашу башлана. Кодалашып йөрү булды бездә. Сөлге алганнан соң кыз йагы да, йегет йагы да йақын туғаннарын чақырышып, қодалашып йөрүне сөйләшкәннәр. Биш пармы, ун пармы йөрешә. Қара-қаршы шулай чақырышалар. Бер көнне бер қодада, икенче көнне икенче қодада ашта буласың. Шулай иттереп бер йарты ай ашта йөрисең. Қодалашып йөргәндә йақшы атларга утырып урам әйләнгәннәр (*Мостафа*).

### ***Қодаларға жҷырлау***

Иртән торып тышка чыгам,
Йәшәрә суганнарым.
Йәшәргән суганнар кебек
Йәшәгез, туғаннарым.

Аллар булғанда ғына,
Гөлләр булғанда ғына,

Күтәрелә күңелләрем
Бергә булганда ғына (*Мостафа*).

### *Туй атлары*

– Қыш көне бит туйлар. Чаналы атлар. Атлар бизәлгән. Битйаулықлар, қыңгыраулар элгән. «Җидешәр ат белән килгәннәр», – дип сөйләделәр (*Мостафа*).

### *Бирнә, бирнә тарату*

Йаучы килеп қызны килешкәч, бирнә бирүне сөйләшәләр, бирнә тараталар.

**Бирнә таwар:** күлмәклек, шәл, шарыф, наски, бийәләй.

Менә қодағый йагында унсигез кеше була икән, мин унсигез кешегә бирәм таwар, күлмәклек таwар, шәл, шарыф, наски, бийәләй. Үзем бәйләгәнне бирәм (*Мостафа*).

### *Өшәнчек*

– Өшәнчек белән килә йәш килен. Битҗаулығы, тастымалы, өйгә эләргә чаршаwы була.

Күпертеп чиккән намазлықлар булды.

Күпертеп чиккән мендәрләр булды (*Тукай*).

**Қул өшәнчеге:** – Йәш килен үз қулы белән өләшә, бийәләй, шарыф, қулйаулық, йанчық. «Қул өшәнчеге өләшә», – диләр (*Тукай*).

### *Элү*

– Килен төшә. Бийеменә[1] сөлге элә, таwар элә. Сөлге чикмәгән бездә (*Сарманай*).

### *Өйгә элү*

– Өйгә эләргә алып бара төшкән йортына. **Тәрәзәсенә челтәр, караwат өсләренә** йабарга.

**Түр йурганы** алып бара.

Ап-ак кийезен дә алып бара.

[1] Бийем – кайнана.

**Кәштәгә (киштәгә) күтәреп куйу:**

– Өй эченә кәштә куйып, йастықларын, йурғаннарын кәштәгә күтәреп қуйа торғаннар ыйы (*Мостафа*).

– Таwар фәрдә, тәрәзә фәрдә: – Дүрт тәрәзәлек таwар фәрдә алып бара. Тәрәзә фәрдә элә, таwар фәрдә элә.

– Чыбылдык, мендәр кабы (мендәр тышы): – Чыбылдық элә сәке кырыйына. Мендәр қабы алып бара. Мендәр қабы икене алып бара. Чигүле түгел, теккән генә (*Рәдүт*).

### *Ызба бизәү*

**Ызба бизәү** – килен әйберләре белән өй бизәү.

– Қызның әйберләрен китереп, таwар китереп ызба бизиләр.

Битйаулықлар (сөлгеләр), мендәр қаплары белән олы йаққа да, бәләкәй йаққа да чаршау эләләр (*Рәдүт*).

### *Кийәүлек, кийәүлек әзерләү*

**Кийәүлек** – кияүгә бара торган кыз әзерләгән әйберләр: бирнә, өйгә элү, кием-салым һ.б.

– Кийәүлеккә дип әзерли кыз. Кийәүгә, кийәү йегетләренә, өйгә эләргә әзерли.

Өйгә кергәч **тастымал** бирә.

**Наски, пирчәткә** бирә кийәүгә, кийәү йегетләргә.

**Пута:** – Пута бәйлиләр кийәүгә. Утыз-қырық күздән, английский вязка белән бәйлиләр путаны. Кийәүгә бүләк. Кийәү биленә бәйли путаны (*Рәдүт*).

Билбугычлы күлмәк кийәүгә. Җылы ыштан, пирчәткә әзерли кыз. Кийәүгә күлмәк, йақалар қайулы (*Мостафа*).

### *Қызлар йаны*

**Қызлар йаны** – туй алдыннан уздырыла торған мәҗлес.

– Қызлар йаны дип киләләр җыйылышып. Җырлыйлар, бийиләр, кереп чәйләр эчеп чыгалар.

Хәзер менә йегетләр дә килеп тула қызлар йанына (*Каргалы*).

### *Ишек баwы тоту, кийәү пәкесе*

Кийәү йегете белән кийәү килә қыз өйенә. Шау-гөр килеп қапқаны биклиләр, ишек баwына басалар малайлар.

Кийәү туй көнне килә. Ишек бауы тотучылар була. Ишек төбендә торалар.

Кийәү ишек дөбердәтә. Аңа әйтәләр:

Сикереп төштем бакчаға
Бастым бақыр ақчага
Без апайны сатмыйбыз
Биш тин бақыр ақчага.

Ишек бауы – бер сум,
Безнең апай – мең сум,
Пәкең булса – кисеп кер,
Пәкең булмаса – көтеп тор,
Акчаң булса – түләп кер.

Шуннан кийәү пәке бирә малайларга. Ишек бауын пәке белән кисеп керә була инде, йәнәсе (*Сарманай*).

### *Кийәү пәкесен чәкчәкигә*[1] *қадый*

– Чәкчәки чығаралар. Өстенә әйбер йаққан. Аны бийи-бийи чыгаралар да ачалар.

Чәкчәки чыгаргач, кийәү пәке қадый чәкчәкигә. Ул пәкене қәйнешләр ала.

«Чәкчәки нық қаты, пәкесе үтми», – диләр.

Ничә пәке қадый кийәү. Зур бүләк булған шул кийәү пәкесе (*Кабан*).

– Кийәү пәкене чәкчәкигә қадый. Ничә малайы бар, әллә ничә пәке қадый (*Мостафа*).

Чәкчәкигә пәкеләр қадый кийәү. Ничә пәке қадый?

Ничә ир малайы бар, шуның хәтле пәке қадый (*Чишмә*).

### *Бүлмәгә бару*

**Бүлмәгә бару** – кияү белән кызның икесе кавышкан көнендә хәл белергә бару.

– Бүлмәгә бару булды. Бер киленне билгелиләр. Ул боларны қарап, чәйләр эчертеп тора. Килен белән кийәү икесе генә утыралар.

[1] Чәкчәки – чәкчәк.

Әшнәләрен чакыралар хәл белергә дип. Кем нәстә алып бара. Падарык бирәләр килен белән кийәүгә (*Рәдүт*).

### *Йәш килен тоқмачы, килен салмасы*

– Йәш киленгә тоқмач җәйдертәләр дә аның тоқмачын берәү килеп йырта. Тоқмачын йыртсалар, йәш килен аны йаңадан басып җәйәргә тийеш була.

**Тоқмач йыртқан кешегә күчти (күчтәнәч) бирү:**

– Қулйаулық булды инде күбесенчә, үзебез чигеп әзерләп қуйдық. Токмачны йыртқан кешегә күчти булды ул (*Каргалы*).

– Салма йәйдерәләр, кистереп карилар. Wакмы кисә (*Яңа Муса*).

### *Йәш киленгә су йулы күрсәтү*

– Йәш киленгә су йулы күрсәтүләр булды элек. Миңа менә иремнең сеңлесе күрсәтте. Ике митыр тасма бирдем, йефәк тасма. Қызлар чәчләрен тасма белән үреп, бантиклап қуйалар ыйы.

– Су ташу ул йәш киленнең зур эше булып торды инде. Иртүк, таң башыннан су ташып қуйабыз. Сақмар суwына төшәбез иртүк, алтышар көйәнтә су алып қайтабыз (*Каргалы*).

– Килен төшерәләр. Ике бидыра, күwәнтә әзерләп торалар.

Су йулы күрсәткәнгә кайын сеңелләргә кулйаулык, пирчәткә бирә килен (*Яңа Муса*).

### *Тел йәшерү*

– Тел йәшерү булган әwәле. Кан'ата белән сүләми. Килен түргә үтми, бусагадан атлап керми. Ишектән генә бирә чәйне (*Яфар*).

– Бийем-бийатадан узмадық. Алар қушқанны ғына эшләдек.

Бийатай белән әз генә сөйләшә килен (*Чишмә*).

### *Айакчылар*

**Айакчылар** – туйда хезмәт күрсәтүчеләр, пешекчеләр һ.б.

– Айакчылар була туйда. Кем нәрсә булдыра, шуны пешереп китерә туйга. Алар табын әзерли, саwыт-сабаларны йуwалар, кунакларны карилар.

Туй беткәч инде хуҗа булган кеше айакчыларны чакырып үзләрен кунак итә, хөрмәтли, рәхмәт әйтә.

– Айакчылар ике йакта да була. Алар йардәм итүчеләр. Алардан башка туй булмый.

– Киленнәрне айакчы итеп куйалар. Менә күршеләрнең тәүге кызын биргәндә айакчы булдым.

Айакчы булган кеше җырлап та бирә туйда:

Әй, илаһи, илаһи,
Тагын бер кат илаһи.
Каwым-кабиләгез белән
Йаратамын, билләһи (*Яфар*).

### *Кулсебергеч*

**Кулсебергеч** – кул сөрткеч; тастымал.

– Айакчыларның алйапкычына кулсебергеч кыстырган.
Ару кулсебергечләр тотып йөриләр айакчылар.
Кунакларга да кулсебергечләр куйалар алларына (*Яфар*).

### *Кодаларның пималарына (киез итекләренә) сөйәк салу*

– Туйда йәшләр, унөч-ундүрт йәшлекләр дә күп була. Алар самаwыр кайнатып, булышып йөриләр, айақчылар була инде алар да.

Шунда менә шайартып кодаларның пималарына сөйәк салалар ыйы. Қайсына қазның ботын, қайсына қанат салалар.

«Қарале, минекенә ничек салғаннар», – дип көлешәләр ийе (*Мостафа*).

### *Киңәш ашы*

– Киңәш ашында киңәшәләр. Кем нәрсәне пешерә туйға. Киңәшкә җыйылып киңәшәләр (*Мостафа*).

### *Аш китерү*

– Туйга аш китерәләр. Ун пар булса ун аш, унике пар булса унике аш килә. Ике күмәч, утызлап җәймә, ләwәшләр, пешкән пар казлар, чәкчәк, бәлешләр килә. Зур күмәчләр салалар кабартып.

Туйга чакырылган һәрбер кеше аш алып килә. Ит, бәлеш, күмәч (*Мостафа*).

«Менә йөз таба аш килде» дип сөйләгәннәр.

– Безнең Мостафада туйга җәймә, күмәч, ләwәш, катлама салалар.

Башта салма чыга, аш, ит белән бәрәңге. Казны турыйлар (*Мостафа*).

### ***Ашларны күчтәнәч итеп бирү***

– Туйда ашларны күп китерәләр. Ул ашларны туганнарына тараталар күчтәнәч итеп. Өйләренә алып китәләр.

### ***Май ашы***

– Май ашы этелә. Хазер менә пәрәмәч этәләр.

«Йакшы кабарган май ашлары», – этәләр (*Яфар*).

### ***Аш эчү***

– Туйда аш эчәбез. Түгәрәк токмач салалар ашка (*Чишмә*).

### ***Чәлпәк***

Туйга кырык чәлпәк алып бара идек тәүдә. Күкәйгә генә камыр басып, аны йока гына итеп җәйә. Зур казанга салып, майда гына пешереп ала.

Сындырып куйалар чәлпәкне, дүрт кешегәме, ике кешегәме (*Яфар*).

### ***Бәлеш***

**Бодай бәлеше** пешерәбез. Бодайны төйәбез, аны сөткә салып зур казанда пешерәбез. Бодай тәмле булып пешә. Шул бодайны бәлеш эченә сала. Бәлешнең бөкесен алып май сибәләр. Бик тәмле була (*Чишмә*).

### ***Катлама***

– Катлама ул күмәч камырыннан. Җәйәбез дә пешереп алабыз. Берсе өстенә берсен куйып, майлап пичтә пешерәбез. Иң өстәге катламаны бизиләр ийе (*Мостафа*).

### *Пилмән*

– Кичкелеккә пилмәнгә чакыралар кодаларны. Өч көн пилмән ашаталар. Өч көн мунча керә.

### *Кийәү пилмине*

– Кийәү пилмине пешерәбез wак кына итеп. Ит күп, башмаклар суйабыз туйга (*Яфар*).

### *Кийәү пилмәне*

– Кийәү пилмәне бик wак була. Бер агач қашық, шул қашыққа биш пилмән сыйа торган ыйы.

– Зур бабай дип йөртә торган ыйық әтәйнең дәдәсен. Менә аларның пилмәне бер қашыққа биш пилмән сыйа торған ыйы. Зур пилмән йасасалар «бақа хәтле пилмән йасағаннар», – дип әйткәннәр. Пилмәннәр эре булса, ул ғәйеп булған. Күп wахыт кирәк булса да, кич утырып зур-зур тәпәннәр тулы пилмән йасап қатырып қуйғаннар туйға (*Мостафа*).

### *Әби кимагы*

– Әби кимагы дип кийәү акча сала кимакка. Кийәү кимагы, дип күчтәнәч белән килә кийәү (*Яфар*).

### *Қыстыбый*

– Қыстыбыйларын күп пешердек. Бәрәңге эчле қыстыбый пешерәбез (*Яфар*).

### *Кыйгача*

– Қыйғачалар, күмәчләр қуйылган табында чәй эчәбез (*Чишмә*).

### *Самбуса*

– Бәрәңге самбусасы пешерәбез. Сөткә суды, тоз салып камыр басасы. Бәрәңгене айырып пешерәбез. Бәрәңге өстенә суган, ак май, тоз салып изәбез йақшы гына итеп. Қамырны токмачка җәйгән кебек җәйәбез дә дүрт қырлы итеп, өстенә бәрәңге йагып пичтә пешереп алабыз (*Сарманай*).

### ***Җәймә***

– Безнең Сарманайда җәймәне күп пешерәләр қунаққа да, туйларга да. Йарты литыр сөткә бер күкәй, тоз салып камыр басасың да шуны йегерме биш кисәккә бүләсең. Шул кисәкләрне нәзек кенә итеп җәйәсең дә йанып торган пичтә пешерәсең. Ул ут йалкынында бик тәмле булып пешә пичтә (*Сарманай*).

– Җәймәне дүрткә бөклиләр дә, шуңа каз итен урап, кодаларга бирәләр ийе. Табында шулай коданы сыйлыйлар ыйы (*Мостафа*).

### ***Чөче җәймә***

– Безнең Йафарда чөче җәймә пешерәбез. Белен пешерәбез дә каймак белән шәкәр, ванилин салып крем йасап, шул белен өстенә канат белән сөртәбез. Кунакка чөче җәймә куйабыз сабан туйында. Нәзек йәймә пешерәләр туйларга күп итеп (*Яфар*).

### ***Катлама***

Чөчели катлама пешерәбез, ачыли катлама.

### ***Ләwәш***

– Туйларга ләwәшне үзем пешерәм. Дүрт таба ләwәшкә: 1 кг. сливочный маргарин, бер кг. шикәр, бер кг. он, бер л. сөт, ун күкәйдән камыр басам.

Шушы камырдан эченә йә чийә, йә күрәгә салып пешерәм (*Каргалы*).

### ***Кош теле, лақша, чумар***

– Кош теле, лақша дип күкәйгә генә басып майда пешерәбез. Қайсы кеше бал да сибә.

– Бер табақ қош теле пешереп бара туйга.

**Чумар** – өзеп сала токмач камыры (*Биктимер*).

### ***Тәңкә токмач, бәлеш***

– Туйларда тәңкә токмач салып шулпа куйалар. Шулпадан соң бәлеш, каз ите белән (*Каргалы*).

– **Қабақ бәлешен** өлешләп кисәләр (*Чебенле*).

### *Салма*

– Камырны өзеп, салма салабыз (*Чишмә*).

### *Пашкит*

**– Пашкит** салалар туйга алтышарны. Өстенә павидло йагып пешерә, бизәкләп. Шуны туйда ашаганнан соң бүлгәлиләр дә алып кайтып китәләр күчтәнәч итеп (*Үрге Чебенле*).

### *Шишара*

– Әче камырны кабарталар да җәйеп, шакмаклап кисеп майда пешерә. Шул шишара була (*Үрге Чебенле*).

### *Төш өсте*

– Әчегән күмәч камырын түгәрәкләп җәйеп, көлчә итеп пешерә. Шуның өстенә күкәй белән сөтне тугылап сөртә дә пичкә тыга. Икенче йагын әйләндереп пешерә дә каймак сөртә. Нык тәмле әйбер була (*Үрге Чебенле*).

### *Питырач, бәләкәй күмәч*

**Питырач** – төче күмәч.

– Тары оныннан питырач пешерәбез казан төбендә.

Питырач – чөче камырдан була, хәйергә пешерәләр.

Эләннән дә питырач пешергәннәр тирмән тартып.

**Бәләкәй күмәч** – аны хәйер өчен пешерәләр. **Питырач** дип төчедән пешереп хәйер бирәләр (*Яфар*).

### *Чүрәк*

**Чүрәк** – вак күмәч.

– Чүрәкләрне зур таба белән пешерәбез. Чүрәк өстенә җәймәләр қуйабыз.

Чүрәкләрне урап пешерәбез. Ул wак күмәч була инде (*Яфар*).

– Коръән ашында күчтәнәчкә чүрәк тараталар, хәйерләр бирәләр. Чүрәк ул күмәч кебек wак кына була, табада кабара. Өстенә қукай сөртәләр, тмин сибәләр (*Яңа Муса*).

### *Баwырсақ*

– Баwырсақны эре итеп пешерәләр бездә. Күкәйгә генә басалар камырны (*Сарманай*).

– Кийәү йегете белән кийәү киләләр кичен. Алар килүгә кыз өйендә баwырсақ пешереп әзерләп торалар. Ул баwырсақ баллаган баwырсақ булмый. Аны очраган бер кешегә тараталар кыз нәселләре. Шулай кийәү килгән көнне тараталар (*Урге Чебенле*).

### ***Баллы баwырсақ***

– Ә туйга инде баwырсақны баллап қатыралар ыйы.

«Терсәк буйы булсын, бийек булсын, – дип, чүмәлә-чүмәлә баwырсақ булды (*Сарманай*).

### ***Кийәү ашы, чәкчәк, чәкчәги***[1]

– Кийәү ашына қыз йағыннан чәкчәги китерәләр. Шунда инде кийәүгә өс-баш, пирчәткә, шарыф, күлмәк тә килә.

**Чәкчәги** – йегетләр үзләре генә утырған мәҗлесне шулай әйтәләр. Кийәү ашыннан соң була ул. Қыз йағыннан биргән кийемнәрне кийенеп утыра кийәү. Йегетләр күп булып җыйылып утыралар.

– Чәкчәк мәҗлесе, диләр. Ул йегет йагында була. Кыз йагыннан чәкчәк пешереп җибәрәләр.

### ***Чәкчәк, чәкчәги***

– Чәкчәкне wақ қына итеп кисеп пешерәләр. Туйларға пешергәндә бийек итеп пешерәләр:

«Терсәк бийеклеге булсын», – дип бийек чәкчәкләр пешереп қуйалар (*Сарманай*).

– **Чәкчәги** – иң атаклы аш. Қыз йағыннан алып чығалар икешәр патнус чәкчәги.

– Тоқмач кебек итеп кисеп пешерәләр. Бүләк салалар. Бер туйға җиде патнус чәкчәги.

### ***Ләwәш***

– Алма, чийә, кузгылдактан ләwәшләр пешерәләр туйга, кунакларга.

---

[1] Чәкчәги – 1) чәкчәк; 2) егетләр мәҗлесе.

### ***Тутырған таwық***

– Таwық суйсалар, таwықны тутырып пешерәләр ийе. Суйалар, әйбәтләп йуwалар, эчен чистарталар. Қайнарламыйлар. Тиресен итеннән айыралар да ике араға күкәй белән қаймақны туғылап салалар, унар-унбишәр күкәй салалар. Бәйләп қуйалар аны җеп белән. Ул бик зур булып, қабарып пешә матур булып. Безгә, балаларга, бүлеп бирәләр. Аwыл зур, бер өйдә бишәр-алтышар бала була иде.

– Таwықны йолқыйбыз. Йыртырга йарамый. Тиресен қуптарабыз итеннән. Түшен нәзек энә белән тегәбез. Бугазыннан тутырабыз күкәй белән сөтне, қаймақны тугылап. Әзрәк тоз салып. Бәйләп қуйабыз да сүрән генә утта пешерәбез. Әзрәк пешкәч энә белән төрткәләп эченнән һаwасын чыгарабыз. Йарылмасын дип (*Кылчым*).

### ***Қаз турау***

– Қазны табында турыйлар. Иң элек кийәү турый башлый. Шулай тийеш. Ул қазны турарга инде бер ғәйрәтле генә әбигә бирәләр. Майлары агып тора, бөтен кеше қарап көтеп тора. Аны менә Ғәлийәнең зурнәсе Мәхүп әби турый торған ыйы күбрәк. Берәү турый, берәү таратып тора.

Ә қодаларга қаз итен җәймәгә төреп бирәләр ийе. Бер җәймәне дүрткә бөкләп, эченә каз ите салып бирәләр табында (*Мостафа*).

### ***Каз бүлү***

– Бер казны кырыкка бүләләр ашта wак-wак кына итеп. Пар қаз була туйда (*Чишмә*).

### ***Кодагый күчтәнәче***

– Кодагый алып килә пар каз, чикчәги (*Рәдүт*).

### ***Кыстыбый***

Кыстыбыйларны күп пешердек. Тары эчле кыстыбый. Бәрәңге эчле кыстыбый (*Яфар*).

### ***Күмәч йабу***

– Күмәч йаптык. «Күмәчем чыкты, чәй эчәргә керегез», – дип чакырган күршеләрен (*Яфар*).

– Күмәч йапса, табагач, ухват, кучаркаларын алып тора күршедән. «Синеке чыксын, мин алырмын», диделәр.

Күмәч пиче бар, алты күмәч сыйа. Колмак белән пешерәбез күмәчне (*Чишмә*).

### *Йылы күмәч хәйере*

Йылы күмәчне хәйергә күршеләргә кертергә тырышканнар әбиләребез.

«Йылы күмәч хәйере – корбан чалган белән бер булыр», – ди. (*Кылчым*).

### *Кырынды күмәч*

**Қырынды күмәч** – күәсне кырып алган камырдан пешерелгән күмәч.

– Күмәч салганда қырынды күмәч салып хәйергә илтәләр ийе. Қырынды ул күәстә йабышып калган камырны кырып шуннан пешерелгән кечкенә күмәч. Бер әйберне дә әрәм итмәделәр элеккеләр.

Күмәч салган сайын әни шул күршеләргә һәркайсына кырынды күмәчен хәйер күмәче итеп биреп җибәрә торган ыйы. Шул кырынды күмәче, хәйер күмәчен төргән тастымал өстенә моннан шырпы да салып җибәрә торган ыйы. Шундый ырымы булган инде, күрәмсең. Шулай кешедән кәм йәшәмәдек (*Сарманай*).

### *Үрә*

– Пийала шиша белән бодайны йарабыз да үрә пешерәбез. Күрше әбине чакырабыз үрә ашарга (*Султакай*).

### *Өйрә*

– Кул тирмәнендә тартабыз бодайны, бер учтай гына йарма була. Өйрә итеп аш эчәбез (*Биктимер*).

### *Тары төйү*

– Тары төйәбез киледә. Ботқа пешереп ашыйбыз (*Биктимер*).

### *Талкан, «талқаны коры»*

– Бодайны йуwасы да казанга салып пешерәсе. Пичкә табалар белән тыгасың. Ул пичтә кибә. Кул тирмәне белән йарасың.

Пешергәндә суга май саласың. Шуны түгәрәкләп куйасың, балаларга бирәсең.

«Талканы коры» дигәнне ишеткәнең бармы. Талкан майны йарата ул. Кырыс, усалрак кешене дә әйтәләр бит «аның талканы коры» дип (*Султакай*).

### *Дурочмак*

– Дурочмак пешерәбез ак эремчектән, өстенә күкәй сөртәбез (*Каргалы*).

### *Кәкүрткә*

**Кәкүрткә** – бөккән.

– Ат кузгалагыннан кәкүрткә салалар табага әwәләп. Түгәрәкләп шикәр сибеп пешерәләр. Кәкүрткә итеп салдым, диләр (*Кылчым*).

### Үсемлекләр, җиләк-җимешләр

– **Җиләкне** күп җыйдык.

Җир җиләге, қайын җиләге күп була бездә.

Менә быйыл қорылық булды, йаңгырлар йаумады җәй буйына.

Быйыл җиләкләр темәләнгән дә кипкән, күдергән җиләкләрне.

Үткән йыл кучалап җыйдылар җиләкне. Бер бидерә җиләк бер адым җирдән, күз ачып йомганчы тула бидерә (*Яфар*).

– **Карлыған,** йалан карлығаны, бөрлегән, миләш җыйдық, қамырлық, гөлҗимеш җыйдық. Мәләш қағы қойдық (*Мостафа*).

– **Қарағат қағы, алма қағы, миләш қағы** қойдық (*Тукай*).

– **Шомырт** күп була. **Қара шомырт** үсә. **Қызыл шомырт** үсә.

Шомыртны җыйып киптереп, қул тирмәнендә тарттық. Қышқылыққа бик шәп була. Қайнар суға болғатасың да шикәрләп қуйасың табынга (*Биктимер*).

**Чийә, майлы чийә** ашадық.

– Йаланнан қыр чийәсе җыйып алып қайтабыз, салқын суда йуwабыз.

Сары майны қайнатып чийә өстенә қойабыз. Ул инде бозылмый. Қышқысын әйбәт була (*Кабан*).

– Ашакайын ашаган үләннәрне.

Бибекә үләне, песәй үләне, кәҗә мөгезе, андыз җыйабыз.

Қуйан тубылдыгы – төбендә бәрәңгесе була (*Чишмә*).

Ашый торган үләннәр дә күп үсә.

Қымызлық, сийәрби, кузғалақ, йуwа, тау қыйары, балтырған ашадық.

Ашқа турап ашый торган үләннәр халықны ачлықтан сақлап қалдылар (*Сарманай*).

**Қамыш туқмағы** була башында.

Ашый торған ыйық қамыш (*Сарманай*).

**Кырмалау тамыры** була, кучаны була кырмалауның. Шуны ашадык. Ул әрекмән инде казанча (*Султакай*).

– Тубалдык үсеп чыга. Ак чәчкә ата. Бәрәңге тубылдыгы диләр. Ашадык (*Сарманай*).

### *Балтырган ашы, балтырганлы умач*

– Май айында балтырган ашы пешереп эчәбез. Умач уwабыз күкәй белән, ашқа салабыз.

Каймаклап, қатықлар салып балтырган умачы ашыйбыз (*Биктимер*).

### *Алабута онынннан умач*

– Алабута онынннан умач пешереп ашадық. Ул қап-қара умач инде, ашы да қап-қара була алабутаның. Ул қара орлыклы була алабута.

Қатық қатып ашадық. Қатық салсаң, ашарға була ул алабута умачын (*Сарманай*).

### *Алабута питырачы*

– Алабута онынннан питырачлар пешердек бик тырышып. Әзерәк сөт белән майың булса, әзрәк оның булса ул да ашарлык була. Алабута питырачын да күршеләр белән бүлешә торган булды. Халык бик тату, дус йәшәде (*Чишмә*).

### *Өшегән бәрәңге кимагы*

– Йаз башын җирдән бәрәңге казырга чыга идек. Ул көздән калып кар астында кышлаган өшегән бәрәңге була инде. Шуны

берәр бидыра казып, эзләп алып кайтабыз. Тапсак – куwанышабыз әле.

Шул казып алган чергән бәрәңгене чичтартып, кабыгын алып әрчеп түгәбез. Булса – он кушабыз, май салабыз, тоз салабыз. Пичкә йагып бәрәңге кимагы пешерәбез. Күрше-тирәне чәй эчәргә чакыра идек. Шул өшегән бәрәңгедән пешергән кимак белән гөрләшеп чәй эчә идек (*Султакай*).

– Йаз башын туңган бәрәңгене казып җийабыз. Аны кип-терәбез дә кул тирмәнендә тартабыз. Оны булса он кушып кимагын пешерә (*Яфар*).

– Йылак кели башлый элекеләрне искә төшерсәң.

## Җеназа

– Җеназада Наҗийә җыwа. Кайсы йортта мәйет, бөтен аwыл килә. Хайер илтәләр, төнәтергә киләләр.

Төне буйы, йорт тулы, ызба тулы кеше утыра.

**Төнәтүчеләр** төне буйы утыралар. Күрше-тирә төнәтүчеләрне чәй эчәргә чакыра.

Дисбе тартып утыралар әбиләр. Зиратка чакырмыйчы, үзләре белеп, ишетеп баралар. Саwаплы ул зиратка бару.

Мәйет озаткач, энә сабаклап өләшәләр.

Өчесе, җидесе, кырыгы була. Кырыгына хәтле йасин укилар (*Яңа Мус*а).

## Хатем ашы

– Хатем ашына иң алдан салма пешереп куйалар, ит куйалар, йәймә, баwырсак.

Ашка хатле коръән укилар, хайер тараталар бөтен халык.

«Әрwах өчен», «әрwахлар рухына».

Әрwахларны онытырга йарамый. Атна көн, йома көннәрне хайер тараталар.

Эчәкәй кешегә хайер бирергә йарамый.

Лә илаһа дигән сүзне
Укик китаплардан алып.
И, туганнар, амәл кылик,
Ахирәтне искә алып (*Яңа Муса*).

## Даладагы серле ташлар

### *Утырткан таш*

– Йафар аwылыннан йырак түгел бер таш бар. Ул кеше бийеклеге таш. Утырткан таш дип йөртәләр. Аны аударганнар машина белән төртеп. Шуннан соң менә үзләре аварийәгә очрап бәрелеп үлделәр ул кешеләр.

Ул ташны кабат утыртып куйдылар. Ул таш элек коршаган урын[1] булган диләр. Дин таратып йөргән кеше үлеп калган. Әнийемнең әнисе шылай сүли иде. Сезнең аwылда шынди таш бар, уратып куйыгыз ул ташны дип. Йәпәк кенә таш ул, кеше бийеклеге.

Аwылдан чыкканда тигез урында ул таш. Элеке зур иде, озын иде. Хәзер инде йиргә иңә. Дин таратып йөрүче булган диләр (Яфар).

### *Киле таш*

– Аwыл кырында шундый зур таш, таудан чыгып тора. Ул ташка элекеләр исемнәрен йазганнар. Таш өстенә әзрәк чокырлар чокыганнар.

«Кошларга эчәргә су жыйылып торсын». Шуны Киле таш дип атаганнар (*Яфар*).

### *Утарташ*

Утарташ – ул тау. Чишмәсе бар. Йаңгыр теләргә чыгабыз.

Утарташ – бийек тау. Шунда күл, бик тирән (*Кабан*).

## Кыр җәнлекләре, йорт хайваннары

– Қылғанны далалар булды бездә элек. Ап-ак чәчәк ата, чайкалып утыра далада қылганнар.

Қыр җәнлекләре күп бездә.

Қыр кәҗәләре, қыр қуйаннары күп.

Қуйанны төлкеләр ашый.

Қыр чучқалары, бурсықлар, бүреләр бар.

Қыр песәйе – рысь бар Чагыл тауда.

**Бурсық** аталар аучылар.

---

[1] Коршаган урын – киртәләп алынган урын.

Бурсыӄ итен үпкә аwыруыннан ашыйлар. Бурсыӄ ул тамырлар белән туклана, җир тәме килә бурсык итеннән. Ӄайсы җиреӊ аwыртса, шул җирен ашарга ди бурсыӄның.

**Пошилар** да күп бездә. Пошиның бәбиләп йатканын күрдек. Ул йаман үкерә икән бәбиләгәндә. Усал була икән.

Поши ул **мөгезе белән түки[1],** имгәтә.

**Бүреләр** дә килә аwылга.

Менә Нурҗиһанны **сарык тәкәсе түкәде.** Шул сарыӄ тәкәсен төннә бүре килеп алды. Сарай эченә төшкәннәр бүреләр.

«Мине **түкәгән** өчен бүре алды сарык тәкәсен», – диде.

– Менә күршеләр бүре баласын алып кайтканнар. Төннә шул бүре баласының анасы, ана бүре килеп, ӄыйыӄчадан (түбәдән) төшеп, бөтен сарыкларны буwып киткән, үч алган баласы өчен.

Көзәннәр, әрләннәр, йомраннар күп.

– Көзәнне тиресе өчен тоталар. Ул сасы була, итен ашамыйлар. Капкан белән тоталар. Тиресе ӄыйбат була көзәннеӊ.

– Әрләннәр таwыӄларны буwалар (*Яфар*).

## *Йомран тоту*

– Йомраннар элек бик күп булды. Сызгырып утыра ул йомран, ойасыннан чыға да.

Йомран тотарға чыгалар ӄар китә башлауға уӄ.

Йомранның ойасын табып, ойа тишегенә ӄарлы су салалар. Тишек авызында берәү тора. Йомран шул тишегеннән атылып чыга. Чыӄӄан көйенә эләктереп алалар wаӄ ӄына йомран балаларын. Ӄулны да тешли инде ул эләктергәндә.

Йомран ул көздән ойасына иген ташып, башаӄлар ташып ӄуйған була. Кышлый шуны ашап симереп йата. Йазга чыӄӄанда ул бик симез була. Тик ашап йатӄан инде ойасында. Шул йомраннарны менә йаз көне тотып ашадыӄ. Күп кеше йарата йомран итен.

Йаз көне без шулай шаwа-шаwа[2] йомран ашадыӄ. Таба тулы майы чыга пешергәндә. Кар әз генә ачыла тау башында, менә

---

[1] Түки – сөзә.

[2] Шаwа-шаwа – табак-табак.

шул чагында тоталар йомранны, бик тәмле аның ите. Жареный таwык та андый тәмле булмый.

Йомран ите чөче була икән ул, чөчкелтрәк ул ашарға.

Алдан тозлап қуйарға кирәк икән аны, йомран итен.

Шундый күп ашадык йомран итен. Тау башында тотабыз йомранны, қар китә башлаганда.

Тау башында шул чагында кичке уйын да була инде. Без балалар йалан айақ йөгерешәбез (*Сарманай*).

### *Атлар утлап йөри*

– Бүреле тау артында атлар утлап йөри. Бер йаратқан атым бар ыйы, Зәрә исемле. Әти шуны аwызлықлап бирә дә атланып китәм. Атларны алып қайтып сарайга йабам. «Әти атларны йаптым» (*Мостафа*).

### *Рабучи атлар*

– Рабучи атлар айырым тора. Аларға ашарға печән, салам, солы салабыз.

### *Чабыш атлары*

– Чабыш атларын айырым ашатып торалар сабан туйларына. Атны йаратқан кеше генә ат чабышына чыга ала (*Яфар*).

### *Кырыкмыш*

– Кырыкмышларны күп карадым. Йигәргә йараганчы кырыкмыш була ул атлар.

Атның ике йәшлеге кырыкмыш дип атала. Сарайда тотабыз кырыкмышларны. Эрәнмәгәннәре тибеп җибәрә (*Яфар*).

### *Тай*

– Тайлары үзләренә башка була. Аларны үзе бер кеше карый иде.

### *Башмак*

**Башмак** – бер йәш тулган бозау була. Сугымнарга әйбәт була башлыклар.

### *Азбар*

**Азбар** – әд. абзар.

**Карды** – ачык абзар.

– Азбарга кыш көне йабабыз, йәйгелеккә кардыга чыгарабыз (*Яфар*).

## Өмәләр. Күмәк эшләр

### *Кийез басу*

– Кийез басарға өмәгә чақыралар. Алты-җиде җыйылып барабыз.

### *Җон түшәүче*

– Җонны аны тигез итеп түшәргә кирәк. Бер оста кешене җон түшәүче итеп қуйалар кийез басқанда. Бөтен аwылға йөртәләр оста итеп кийез түшәүчене.

### *Кийез түшәүче*

– Кийез түшәүче дә бик белеп кенә түши кийезне. Иң башта чүперәк җәйеп қуйа да шуның өстенә түши җонны. Җон өстенә җылы сулар сибәләр дә шуны әйләндерәләр. Бераздан ачалар, тағын су сибәләр, басалар.

### *Ике көчле кеше кирәк*

– Ике көчле кешене қырыйға қуйалар. Көчле кеше булмаса, кийез бүлтәйеп чыға. Шуңа көчле кешене қырыйға қуйалар.

### *Уртадагылар*

– Уртадағылар җырлый-җырлый тәгәрәтәләр кийезне. Ул керешә башлый.

### *Кийез басу – кыш көне*

– Кийез басу ул қыш көне була бит. Шул кийезне кисәү ағачларына элеп, мәкегә (бәкегә) чайқарга алып китәбез.

Бидерәләр (чиләкләр) белән өстенә су қойабыз боз өстенә җәйеп. Кийезебез ап-ақ була торған ыйы.

### *Кийез – тоташ ақ җоннан була*

– Бездә кийезне тоташ ақ җоннан ғына бастылар. Кыш көне басабыз бит күберәк. Боз өстенә җәйеп, мәкедән (бәкедән) су

алып жуwабыз. Шулай өстенә су Койып торабыз. Күп кеше булғач аwыр эш түгел ул. Шап-шап иттереп әйләндерәбез, шапылдатып қағабыз да алып қайтып хужаға тапшырабыз.

### *Кийез басучыларны сыйлау*

– Хужа инде сыйлый кийез басучыларны. Итен, ашын пешерә хәл кадәренчә. Қоймағын, қыстыбыйын пешерә. Итне шулпалап бирәләр. Бал қуйалар (*Мостафа*).

### *Көзге йон*

– Көзге йоннан кийез бастық, көзге йон кирәк. Йазгы йон керешми ул.

### *Йонны теттерәбез, түшибез*

– Көзге йонны теттерәбез дә түшибез. Ләписең йонны, тигез булсын. Өстенә кан'ар су сибәсең. Ул тигезләнергә тийеш. Сирәк йиренә йон өстисең.

Чүперәкне өтөрәсең дә **қатат' итәсең.** Йон керешкәнче **тәгәрәтәсең.**

Кийез безнең ак йоннан, ак кийез бастык. Кырыйына кара йон белән йазып куйасың исемеңне.

### *Урдыкка (сәкегә) кийез җәйү*

– Түрдә урдык (сәке). Урдыкка да кийез җәйәбез. Урдык ул сәке була инде карича. Ак кийез бөтен ызбаны йактыртып тора, матур булып (*Яңа Муса*).

– Йоннарны кич утырып ийылып тетәләр. Идәнгә иске-москы чүперәкләр, чаршаулар җәйәләр дә йоннарны чүперәкләргә түшиләр. Йон өстенә су бөркиләр, йылымса су. Тагы урыйлар. Бераз баскач сүтәләр дә тагы су бөркиләр. Биш-алты катын әүмәләтәләр. Карилар, тигез генә барамы. Тигез булмаса, тигезлиләр. Шул күгә йәйеп кенә киптерәләр. Керләнсә, су буйында йуwалар. Ап-ак кийезләр була торган ыйы (*Султакай*).

### *Кийездән ойоклар кидек*

– Кийез ойок ул **пимадан** да йылы була (*Султакай*).

### ***Кийез басу***

– Кийез бастым килен булып төшкәчтен. Көзге йонны теттерәләр. Сарык йоны көзге йон кирәк. Йазгы йон басылмый ул.

Шул йонны түшибез тигез иттереп. Өстән дә, астан да чүперәк белән каплыйбыз. Берничә кеше җыйнала. Урыйлар. Тигез барырга тийеш. Биш-алты кеше шушылай итеп басалар, тәгәрәтәләр. Көзге йон үзе керә бара, үзләнә, таралмый. Чүперәктән төшерәләр, сулыйлар да тагын басалар (*Тукай*).

**Кийезне** күп кулландык.

– Ак кийезне сәкегә җәйдек. Идәнгә дә ак кийез җәйдек. Элек өстәп дигән нәстәкәй булмады ул.

Кунакны да ак кийез җәйеп идәнгә утырттык, табын йасадык.

Үлгәч тә кешене ап-ак кийезгә урап зиратка илтәләр (*Тукай*).

### ***Мамык өмәсе***

– Мамык өмәсенә агай-эне, күрше-тирә ийыла.

**Кәҗә тарагы:**

– Кәҗә мамыгын тарап алалар. Мамык ул қыш башында ук күтәрелә, йамбарда күтәрелә. Шунда иң йакшы мамык була. Фиврал, март, апырилләргә калса, мамык кылы белән чыга. Кылын чүпләсе була мамыкның. Кәҗә тарагы була, кәҗә мамыгын тарарга йасалган була.

Мамыкны тетәсең.

Айалый идек элек (*Султакай*).

– Дыркынныйлар хазер энәле тарак белән. Бүген мынарда, иртәгә анарда.

Берәү дыркынный, берәү эрли орчык белән.

– Киләп йасыйлар. Берсе ката йепне орчык белән.

Шәл башлыйлар бәләргә.

Берәү кайма бәли, берәү урта бәли (*Султакай*).

### ***Мамык айалау***
### ***Мамык айаларга кулалмаш***

– Әниләребез мамык айалый иде. Менә сезгә барып мамык айаласак, алар да безгә килеп мамык айалыйлар иде. Шулай қулалмаш йасап мамык айаладық (*Каргалы*).

### *Дебет айалау*
### *Дебет айаларга кулалмаш*

– Дебет айаладық.

Айаға тыгалар дебетне дә айалыйлар.

Бер көнне беребез дебетен, икенче көнне икенче кешенең дебетен айалау булды. Кулалмаш йасадылар (*Каргалы*).

### *Дебет тарак*

– Дебет айаладык тарак белән. **Дебет тарак** белән дебет айаладык.

Хәзер **шапылдык** белән шапылдаталар. Дыралкы диләр шапылдыкны.

### *Дебет кыллау*

– Дебетне кәҗәдән тарап алабыз да қыллыйбыз. Қылын чүплибез, йуwабыз, эрлибез (*Каргалы*).

### *Дебет өмәсе, шәл бәйләү*
### *Дебет айалау*

– **Энәле айа** була, йегермеләп камыт энәсе кебек. Дебет айалыйбыз. Айалағанда бер төйене, бер нәрсәкәйе дә қалмый.

Бер-ике кеше айалап утыра, бер-ике кеше эрли.

– Дебет айаларга өмәгә йөрдек.

**Кийезгәк дебетне** теттерәләр.

Дебетнең **түбере** чыга, аны теттергәндә кала аламасы.

Шулай **ташлақай түбере** чыға айалаган дебетнең. Шул ташлақай түбердән дә бийәләй бәйләделәр, наски. Ул ташлақай инде, бәйләделәр әниләр (*Кылчым*).

– Үзем шапалатам (айалыйм) дебетне. Үзем эрлим, катлыйм, чиратам, бәйлим шал. Шал бәйләп, сатып көн күрдек.

– Эштән қайтабыз. Өмәгә әйтәләр дебеткә. Анда утырып, дебетне эрләп, қатлап қайтабыз. Аннан хуҗа үзе бәйлиме, кешегә биреп бәйләтәме, шәл бәйли.

Мин өмәгә барсам, теге кеше дә миңа килә қулалмашқа. Шулай қулалмаш йасап йөри торган ыйық. Бер-ике кеше айалап утыра, бер-ике кеше эрли (*Кылчым*).

### *Шәл сату, күчти алып кайту*

– Бер-беребезгә шәлләр бәйләп йөрдек. Аны сатарга йөрдек Ырынбурга, Шарлыкка. Сатып кайткач куwанабыз.

– Күчти алып кайтабыз шәл сатып. Күчтисез кайту йуқ. Балалар көтеп тора. Кәнфит, алма алабыз балаларга (*Сарманай*).

### *Кулалмаш*
### *Чит бәйләргә кулалмаш*

Чит – ул шәлнең чите. Шәл чите бәйләдек бер-беребезгә кулалмашка барып.

### *Кайма бәйләргә кулалмаш*

– Кайма – эшәлнең чите. Без, бала-чагалар, кешегә кайма бәйләдек. Үзебезгә кирәк-йаракка акча эшләдек.

Чәй эчереп җибәрә кулалмашта.

Күмәч пешкән, чәй кайнаган (*Яңа Муса*).

### *Җитен, киндер эшләре*

**Элән** (< рус. лен) – җитен.

– Элән чәчәбез. Аны йолкыйбыз да суга салабыз. Илтеп йәйәбез.

Эләнне мунчага күтәреп киптерәбез дә талкы белән талкыйбыз. Киндер тугибыз.

**Мошко** (< мордва. киндер). – Мошко да чәчтеләр. Аны йерләп йеп йасадык, ойоклар бәләдек (*Яфар*).

### *Зилем әйләнү, зилем уйнау*

**Зилем әйләнү** – яз көне су ташыганда җырлап, түгәрәк әйләнеп уйнаулар.

**Шарлык районы Яңа Муса авылында:**

– Күпер төбендә уйын өсте. Йаз башы су акканда төшәбез. Менә монда гына күпер. Шунда гармуннар белән төшәләр, каракаршы әйтешәбез. Кул белән тотынышып зилем әйләнәбез.

Зилем-зилем зиләйлән,
Кашың кара, күзең кара,
Орчык кебек бер әйлән.

– Зилем уйныйлар, тауда йырлыйлар, тугайларда уйныйлар.

Зилем-зилем Зөбәйдә,
Калдырып китәргә жәллим,
Алып китәмен әйдә.

Зилем-зилем Зөбәйдә,
Зөбәйдәсе торып торсын,
Хөбәйбәсен үп әйдә.

Зилем-зилем-зиләләй,
Зилем дийәрсең әле.
Кайда минем wәгедәле
Йарым дийәрсең әле.

Исемнәре Хәлимә,
Әллә кайларда йөрисең,
Һич кермисең хәлемә.

Исемнәре Гөлсара,
Минем кайда икәнлекне
Сандугачлардан сора.

Исемнәре Нурый да,
Үзен әллә кемгә саный,
Тәмәкесен урый да.

**Мостафа авылында язгы уеннар:**

– Су киткәндә йар башында уйныйбыз. Тауға менәбез тау кипкәч, туғайларга да төшәбез су киткәндә.

«Сақмар буйлары» дип жырлап әйләнәбез.

Сақмар буйлары қалдинде.
Сары чәчәк алдинде.
Сағынышып, сарғайышып
Хат йазарға калдинде.

Сақмар буйында
Үсә алмағачлары.
Күңелле иттереп
Сайрый сандугачлары.

Ал алам сезнең өчен,
Гөл алам сезнең өчен.
Аққан дәрйәләргә төшеп
Йуғалам сезнең өчен.

Их су алулары,
Сунық болғанулары.
Су алғанда су төбенә
Төшеп йуғалулары.

Алым дийәрсең әле,
Гөлем дийәрсең әле.
Кайда минем wәгедәле
Йарым дийәрсең әле.

Бийек тауға менгән чақта
Йулға тайақ ташладым.
Ғәйеп итмәгез иптәшләр,
Инде бии башладым.

**Сакмар районы Үрге Чебенле авылы:**

– Йаңгыз тирәк дигән җиргә су ташуны карарга барабыз. Сакмар су ташып ага, калын-калын бозлар буладырыйы. Без менә борын-борыннан әниләр җырын җырлыйбыз.

Туган аwылым Чебенлем,
Урамнарың киң синең.
Урамыңда матур кызлар,
Йәш йегетләр күп синең.

Тәрәзә төбем пар кына,
Үстерәм сыйпап кына.
Пар каендай без йәшәрбез,
Бик тату булсак кына.

Машинага утырмагыз,
Машина алып китә.
Алып китеп чит илләрдә
Башларны wайран итә.

Аллар булырсың әле,
Гөлләр булырсың әле.
Их, бер генә күрим дигән
Көннәрең булыр әле.

Сандугачлар басып сайрап
Сындырган гөлләремне.
Сынган гөлләргә ошатам
Айрылган көннәремне.

Әйдә, иркәм, барасыңмы,
Мин барам кар су wына.
Кар суларын эчеп торам
Йөрәгем йарсуwына.

**Шарлык районы Сарманай авылы:**

***Төртмә җырлар***

– Кич утырғанда шәл бәйләп утырабыз. Йегетләр керсә, төртмә җырлар җырлыйбыз. Алар да безгә төртмә җыр җырлый.

Сақмар суwы буйларында
Тырактыр чирәм ача.
Төртмә җырлар җырлыйк әле,
Төртмә җыр күңел ача.

Ишек алдым ақ балчық
Бата күрмә, атлап чық.
Син дә әллә кем түгел әле,
Тик әзерәк мақтанчық.

Йуғарычтан түбән очка
Тәгәрәп бара бер пичкә.
Әби кызың бик нечкә,
Түзәр микән бер кичкә.

Бийек тауларның башында
Күренә пәри шәһәре.
Хәзер қызларның мәһәре
Бер подаука бәрәңге.

Зөлхәбирә көлтә бирә
Эскерттән кибәнләргә.
Безнең дә исебез китми
Мин кем дип йөргәннәргә.

Айағыңның берсе озын,
Икенчесе кыскарак.
Икесе дә тигез булса,
Бийер идең остарак.

**Шарлык районы Яңа Муса авылы:**

***Төртмә җырлар***

– Йаз башында күпер төбендә җыйылабыз. Йегетләр белән кара-каршы төртмә җырлар җырлый идек, тотынышып зилем әйләнү дә булды.

Кара кәчтүм ак йака,
Кара кәчтүм ак йакага
Исебез китми пака.

Түтәл-түтәл кийарлар,
Борыныңны бик күтәрмә,
Чиләк элеп куйарлар.

Чийә чийәләнми ул,
Үзең ийәләндермәсәң,
Йатлар ийәләнми ул.

Чәпелдәтеп басыйым,
Синең кебек гармунчыны
Бәлчектән дә йасыйым.

**Көйәнтә** сүзе белән төртмә җырлар күп җырлана иде:

Көйәнтәләрегезне,
Нигә алып килмәдегез
Сөйәркәләрегезне.

Көйәнтә буламыни,
Илдә илле, кырда кырык
Сөяркә буламыни.

Көйәнтәләребезне,
Без ийәртеп йөремибез
Сөйәркәләребезне.

Тимерләт көйәнтәңне,
Үзең бармаган җирләргә
Җибәрмә сөйәркәңне.

Агып килә йомычка,
Йырларыгыз беткән булса
Чакырыгыз пумичка.

***Қарғалы авылы җырлары***

Безнең Қарғалы аwылы
Түбәләре зәңгәр бит.
Йәмле Қарғалы аwылын
Ташлап китүwе җәл бит.

Қарғалының қызлары
Шәлләр бәйлиләр икән.
Йегетләре үткен икән,
Арттан қалмыйлар икән.

Қарғалының қапқасы
Барысы да запорсыз.
Әллә сағынуларым җитте,
Әллә үзем сабырсыз.

Қаз қанатларын саныймын,
Тезелеп қағынғанда
Тулған айларға қарыймын,
Өзелеп сағынғанда.

### *Кулымдагы йөзегем*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сәкинә.
Бийемәсә йалынмыйбыз,
Тик утырсын сәкедә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Саҗидә
Агым суда агар идем,
Туктармын дип сай җирдә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фелүрә.
Аримбурга барып укы,
Шунда булырсың түрә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Шәмсенур.
Син минеке түгел хәзер,
Үз күеңне үзең күр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Галимҗан.
Гыйшык уты уртак булсын,
Мин йанганда син дә йан.

## МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР

### Шарлык районы

**Сарманай авылы:** Рәшитова Миңкамал, Үтәгәнова Сәрвәр, Хәмитова Флера (74 яшьтә), Якупова Фәнүрә Бари кызы (86 яшьтә), Иблиева Әлфия.

**Яңа Муса авылы:** Сәфәрова Рушана, Сөбханкулова Мөкәррәмә (93 яшьтә), Әхмәтова Наилә, Якупова Сәйдә, Алтынчурина Галимә, Аббясова Рәшидә (66 яшьтә), Бадамшина Алсу (60 яшьтә), Гыйләҗева Рәйсә, Мангутова Динә (77 яшьтә), Бадаева Рима (71 яшьтә), Гомәрова Саимә (75 яшьтә), Гомәрова Рәшидә (76 яшьтә), Яхина Зөһрә, Бәхтияров Наил (77 яшьтә), Гомәров Даут (78 яшьтә).

**Зирекле авылы:** Дәүләтшина Сәвия (69 яшьтә), Кәбирова Зәрә Задретдин кызы (97 яшьтә), Мәвликаева Шәмсеруй (85 яшьтә), Ямалетдинова Зөлфирә (67 яшьтә), Шахмуратова Тәзкирә (79 яшьтә).

**Мостафа авылы:** Сәгъдиева Мәйсәрә (82 яшьтә), Саягфарова Сәбилә (72 яшьтә), Гобәйдуллина Гөлнара (40 яшьтә), Сәгъдиева Флера (75 яшьтә), Фаткуллина Миңнегөл (74 яшьтә).

## Александр районы

**Султакай авылы:** Дабаева Рәсимә (36 яшьтә), Асяева Нажия (80 яшьтә), Агишева Галия (70 яшьтә), Исмәгыйлева Вәсилә (75 яшьтә), Сәфәрова Лена (61 яшьтә), Салихов Фуат (62 яшьтә), Агишев Фатыйх (75 яшьтә), Ибраһимова Мөнәвәрә (79 яшьтә), Мусаева Сания (80 яшьтә).

**Тукай авылы:** Мурзакаева Наилә, Мурзакаева Люция (77 яшьтә), Мурзакаев Әсгать (80 яшьтә), Даутова Руза, Даутов Мөхәммәтгаян (85 яшьтә).

**Яфар авылы:** Ишмөхәммәтова Дания (83 яшьтә), Дабаева Әлфинур (50 яшьтә), Яһүдина Рәшидә (66 яшьтә), Айукаева Сәрия (87 яшьтә), Асяева Рәмзия (90 яшьтә), Яфарова Саҗидә (88 яшьтә), Асяева Румия (56 яшьтә), Мифтахова Фәнүзә (52 яшьтә), Яһүдинә Гөлнур (48 яшьтә).

## Сакмар районы

**Каргалы авылы:** Дәүләтьяров Ягъфәр, Хәйретдинова Флера (76 яшьтә), Ягъфарова Назира (54 яшьтә), Кывандыкова Наилә (75 яшьтә), Гафарова Мөнирә (79 яшьтә), Даутов Гирфан (85 яшьтә), Ягъфарова Гөлназ (92 яшьтә), Сафиуллина Илсия, Рәҗәпова Фидая (76 яшьтә), Халикова Гөлнур (77 яшьтә), Мөлекова Зәйтүнә (76 яшьтә), Мөлеков Габдерәүф (82 яшьтә), Улеева Розалия (80 яшьтә).

**Үрге Чебенле авылы:** Әбделмәннанова Наилә (44 яшьтә), Рәхмәтуллина Зөһрә (92 яшьтә), Кунафина Мәгъдәлинә, Искәндәрова Әлфия (75 яшьтә).

## Сарыкташ районы

**Кылчым авылы:** Бакеева Нурҗиһан (75 яшьтә), Хәсәнова Гылара (74 яшьтә), Фазлыева Хәмдия (75 яшьтә), Гомәров Илсур (55 яшьтә), Гомәрова Зөһрә (86 яшьтә), Гомәров Шәрәфетдин (87 яшьтә), Фазлыева Рәшидә, Фазлыева Хәмдия (80 яшьтә).

**Чишмә авылы:** Рәхимова Хупйамал (80 яшьтә), Әбүбәкиева Мәүҗидә (88 яшьтә).

**Кабан авылы:** Кадыйрова Гөлия, Солтанхуҗина Алсу, Ишмөхәммәтова Гөлчирә (80 яшьтә), Ядеханова Фәрдәнә (77 яшьтә), Абдрашито-

ва Рушания (50 яшьтә), Мөхәммәтова Нурия (87 яшьтә), Бәйрәмгулова Рәйхана (81 яшьтә), Алтынчурина Бүләк (55 яшьтә).

**Биктимер авылы:** Гомәрова Миңсылу (86 яшьтә), Гомәров Хөснетдин (86 яшьтә), Низаметдинова Зөһрә, Хәсәнова Бадима (64 яшьтә), Муллазыйанова Нәфисә (84 яшьтә).

**Рәдүт (Никитино) авылы:** Макаева Фәния (85 яшьтә), Сәйфетдинова Сәгыйдә (85 яшьтә), Макаева Саҗидә (80 яшьтә), Мәҗитова Фәния (55 яшьтә), Именкулов Марат (78 яшьтә), Мәвлиева Эльвира, Байгильдина Галия.

**Әбләз:** Әхмәрова Гөлнара (75 яшьтә), Вәлитова Гөлнара (44 яшьтә), Вәлитова Фирдәвес (85 яшьтә), Абдуллин Әхтәм (80 яшьтә), Абдуллина Фәйрүзә (78 яшьтә).

# ӘДИП ИШНИЯЗ БИНЕ ШИРНИЯЗНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН БИЛГЕСЕЗ ӘСӘРЛӘРЕ

*Марсель Әхмәтҗанов*

XVIII гасыр татар әдәбиятына мәгърифәтчелек фикерләре чәчкән Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми (1725–1791) тормышы һәм иҗаты хакында матбугатта язып чыккан идек инде[1]. Ул үз дәверендә татар әдәбиятына инде халыктан шактый ераклаштырылган мәгърифәтчел сюжетлы әсәрләр белән яңа сулыш өрде. Мөселман дөньясында, төрки әдәбиятларда популяр булган Ләйлә-Мәҗнүн, Баязид Бистами, Мәхмүд Газнави, Ибраһим-Әдһәм һ.б. популяр тарихи шәхесләр турында хикәяләрне яңартып җибәрүдә аның хезмәте зур.

Казанда Татарстан милли музеенда татар археографиясенең күренекле вәкиле Зәйнәп ханым Максудованың (1897–1980) шәхси архивында аның үзе исән чагында туплаган борынгы кулъязмалар коллекциясенең бер өлеше саклана. Алар арасында Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи-Болгар» сюжеты язылган, XIX гасыр башы фабрикалары су билгеләре булган 20×32 см зурлыктагы ике яшькелт кәгазь бар. Шушы мәгълүм әсәргә ялганып, кара тушь белән бер «Хикәят» тә күчерелгән. Күчерүче әлеге хикәятне, Ишнияз бине Ширнияздан ишетеп яздым, ди. Ихтимал, ул күчерүче Таҗетдин бине Ялчыгол үзе булгандыр. Чөнки XVIII гасырның 70 нче елларыннан Оренбург Каргалысына Ишнияз хәзрәттә укырга татарның күп укымышлылары барганнар.

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Әдип Ишнияз бине Ширнияз Хәрәзми // Гасырлар авазы. 2005. № 1. Б. 79–88.

Бу хикәяттән күренгәнчә, Ишнияз хәзрәт Каргалы мәдрәсәсендә җирле, татар тарихына, сюжетларына кагылышлы әсәрләр дә иҗат иткәнгә охшый. Аның эчтәлеге Казан ханлыгы оешу дәверләренә караган легендар Соңкырый вәзир турындагы хикәядән гыйбарәт.

Хикәя оригиналда авыр телдә язылганлыктан, аны хәзерге укучыларга аңлаешлы итү теләгеннән чыгып, язылу стилен үзгәртмичә, телен җиңеләйтеп бирергә булдык. Бу хикәя – XVIII гасырның икенче яртысындагы милли татар хикәятләренең бер кызыклы, тапкыр тарихлы үрнәге. Ул Ишнияз бине Ширниязның иҗат мирасына яңа бер сәхифә булып тора. Аны безгә 1978 елда Зәйнәп Максудова телдән дә сөйләгән иде[1]. Шулай ук аның бер тексты С.-Петербургта – Көнчыгышны өйрәнү институтының С.-Петербург филиалында саклаучы Ризаэддин бине Фәхретдин кулъязмалары арасында да барлыгын ачыклаган идек.

Хикәянең бер версиясендә Казан ханының Болгар хакименә куфи хәрефләре белән хат язганы, аны анда укый белүче кеше табылмыйча, Соңкырый вәзирнең укыганда хатны үз файдасына яраклашырып укуы сөйләнә.

## Хикәйәт

Кадими дәвердә кальга-и Казан мөселман вакытында ханның бер вәзире бар иде. Аны Сонкырый дирләр иде. Соңра бу Сонкырыйның башына бер четрекле эш бәйләнде. Ул бу эшдин качып Болгар каласына барды, дәрвиш кыяфәтенә кереп, ханның каршында хезмәт итәр иде.

Ахыры бер көн Казанның ханы вәзиренең анда икәнен белеп, Болгар ханына хат язды. Хатында болай димеш ки:

«Бу Казандин минем Сонкырый исемле вәзирем качкан иде. Аны хәстәрен күреп, тамгалап бәйләп кире үземә җибәрүеңне сорыйм».

---

[1] Бу телдән сөйләнгән вариант «Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 28 б.) китабында басылып чыкты.

Хат Болгар ханына килде. Бу хатны кем укыр, – дигәндә, Сонкырый вәзир, үзенең зирәклеге белән, аның үзенә зарар китерү өчен язылганлыгын аңлап, шаһтан әдәп белән генә сорап алып, и, ханым, үзем укырмын, – диде. Аны алып шулай укыды кем:

«И, Болгари шаһы, бу «Коръән»нән «Бирсен каберең фәләнесе...» – дигән аять качкан, аны теркәп-бәйләп, безгә җибәрерсең», – дигән.

Хан моны ишетеп берничә фикерләргә төште. Ахыры, хәтеренә килде ки, аятьне теркәп-бәйләп җибәрергә кирәге. Аятьне хатка мәгънәви бәйләнешен күчерү авырлык мөнәсәбәтендәдер дип, аңа мәгънәви тәфсир язып, мөһер сугып җибәрде.

Соңра бу хат Казан ханының кулына барып иреште. Хан хатны укып карап, хат эчтәлеге турында бер фикергә килеп әйтте:

«Ханның кулыннан алып, минем хатымны кем укыды? Мин болай язмаган идем бит», – дип сорады.

Аңа җавап биреп, хатны бик гадел бер дәрвиш укыды, – диделәр.

Соңра Казан ханы белде кем, бу дәрвиш аның вәзире икәнен. Ул аңа хат язды, кайт, гаебеңне гафу итәм, – дип, хатны сәлам кылып җибәрде. Вәзир шатлык, исәнлек белән, әүвәлгечә Казан ханы хезмәтендә вазифа үтәде. Ишнийаз бине Ширнийаз хәзрәтләреннән ишеткәнемчә.

## Хикәйәт (оригиналы)

Кадими дәвердә кальга Казан мөселман вакытында ханның бер вәзире бар ирде. Буны Сонкырый дирләр иде. Соңра бу Сонкырыйның башыйна бер эш уграды. Бу эшдин качуб кальга-и Болгарә варды, дәрвиш сурәтинә керүб ханның хозурында хезмәт идәр ирде. Ахыры бер көн Казанныйң ханы бу вәзиринең анда ирдүкен белүб, бу Болгар ханына хат йазды. Хатыйнда димеш ки «Бу Казандин бәнем Соныран исемле вәзирем качмышдур, аны кыйд-бәнд идүб кәнд үзүмә йибәрәсен», – дийү. Бу хат (Болгарга. – *М.Ә.*) хана килде. Бу хатны кем укыр дидүкдә, бу Сонкырый вәзири чәпәклик (зирәклек. – *М.Ә.*) илә

кәндүлгә зарар йөкләмеш хат идүкене белүб, шаһдин әдәбәнә теләб әйдүб, – И, ханым, кәндим укыйурәлүм! Бу алуб шәйлә укыдый кем: «И, шаһ болгари, бу «Корьән»дин «бир синкабрең фәләнесе» дигән айәте качмыш. Аны кыйд бәнд идүб монда йибәрсен, – дийү, хан моны ишедүб берничә тәфәккерә варуб, ахыры хатеринә килде кем, бу айәтнең мәгани кыйд вә бәнд идүб йибәрмәк эстәдүке. Айәтнең мәгани мәгаляка вә тәфсир мәнзүбәтәседүр, – дийу, айәтнең мәгани тәфсиренә бәййан идүб, хата кичүрүб, миһер өзүб йибәрди.

Соңра бу хат Казан ханыныйң әлинә варуб ирешди. Хан укуб карайа, хат фикерә варуб әйде – «Кем укуды бәнем хатымны ханныйң әлендин алуб, – дийү, мин буилә йазмаган идем? Җаваб әйдиләр, – дәрвишрәк хадиме укуды, – дийү.

Соңра хан Казани белде кем, бу вәзиридүр. Хат йазды, – кайтсун, гөнаһын гафу кыйлдым, – дийү хатны сәлим кыйлды. У шадлыйк әйләб, хуш идүб әүвәлгүнчә вәзир улды. Самыйганә (ишетүче) хәзрәти Ишнийаз бине Ширнийази.

**«Мөнәҗәте Ишнияз әфәнде»**

Ишнияз бине Ширниязның тагын бер шигъри «Мөнәҗәте Ишнияз бине Ширнияз» исемле әсәре табылды. Аны без 1982 елда Татарстан Республикасы, Лениногорск районы Югары Чыршылы авылында табылган кулъязмадан ачыкладык. Ул кулъязма җыентык ТФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 39 коллекциядә № 7195 шифры белән саклана. Бу әсәр әлеге мәгърифәтченең поэтик әсәрләр язуына да дәлил булып хезмәт итә. «Мөнәҗәт» Ишнияз әфәнденең вәзен-рифмаларны, иҗекләр структурасын тоеп иҗат итүен күрсәтә. Шунысы кызык, автор әсәренең ахырында шигырь юлына үз исемен дә кушып җибәрә:

«Йөзи Нийази гасый,
Йыглаб түгелмәс йәши.
Кабул улсун догасый –
Иман улсун йулдашый!»

## *Мөнәҗәте Ишнияз әфәнде*

Йарлыкагый җибәрсен,
Сәндин үзгә кемем бар.
Җәлил Гаффар җибәрсен,
Синдин үзгә кемем бар.
Сагыйрь улды колагым,
Зәгыйфь улды күзләрем,
Тәсбих, тәһлил телдә йук,
Гайбәт, һава сүзләдим.
Зикре тәсбих әймәдим,
Тәгать-коллык кыйлмадым,
Үтди гомрем файдасыз –
Кәндү халем белмәдим.
Кеше, гайбәт сүзләдим,
Үз гаибими гизләдим,
Хакыйкать ни сүзләдим.
Гәр әҗәлдер бу кәлмәт,
Саум, салават һәм зәкят,
Фитыр, гошер вә иҗабәт,
Өстемездә чук калды.
Йил тик үтди бу хәййәт,
Шәриф тәндин җан очса,
Пәрваз кыйлып газиз җан,
Гөл тик йөзләр, хуш буйлар,
Сулыб калыр бел [тамыб].
Җөмлә карендәш-туганлар,
Ушпу тәнни йугайлар,
Җиңсез тунлар кидереп,
Гүргә илтеб куйгайлар.
Мөнкир-Нөнкир килгәндә,
Сөәлләрне сорганда,
Җавабымны асан кыйл,
Мин, Раббикә, – дигәндә!
Гөнаһларым кичергүл,
Тәмугь утын өчөргел

Фазлың берлә йа Кәрим,
Сират күпрен кичүргил.
[На]рың бездән ала күр,
Гафулыйк сарый бара күр,
Шул гаҗизлек көнендә –
Рәхим-рәхмәт кыйла күр.
Йөзи Нийази гасый,
Йыглаб түгелмәс йәши.
Кабул улсун догасый –
Иман улсын йулдашы!

## СҮЗЛЕКЧӘ

*Йарлыкагый* – кичереп
*Җәлил* – Аллаһның бер титулы
*Сагыйрь* – начар
*Һава* – тәкәбберлек
*Зикре* – яхшы
*Тәгать* – буйсыну
*Кәндү* – үз
*Кәл(и)мәт* – сүз
*Саум* – ураза
*Салават* – Аллаһны мактау
*Зәкят* – түләү, малдан өлеш чыгару
*Фитыр* – сәдака
*Гошер* – уңышның уннан берсен җәмәгать файдасына бирү
*Иҗабәт* – риза булу
*Чук* – күп
*Хәййәт* – тормыш
*Пәрваз кыйлып* – очып
*Сөәлләрне* – сорауларны
*Фазлың* – өстенлегең
*Кәрим* – Аллаһның эпитеты
*Нарың* – утың
*Гасый* – гөнаһлы

# ОРЕНБУРГ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ФОЛЬКЛОРЫ

## Халык иҗаты үрнәкләре

*Ильмир Ямалтдинов*

Әлеге өлкә җирлегендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну моннан нәкъ 55 ел элек башлана. Оренбургның татарлар яшәгән районнарына хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының иң беренче фольклор экспедициясе 1960 елның май-июнь айларында атаклы фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә түбәндәге хезмәткәрләр катнаша: Х. Ярми, Х. Гатина һәм Х. Гарданов. Фольклорчылар ике төркемгә бүленеп барлыгы 7 районның 11 авылында булалар (Шарлык районының Мостафа, Сарманай, Яңа Муса авылларында, Александр районының Тукай, Султакай авылларында, Октябрь районының Биккол авылында, Сакмар районының Каргалы авылында, Сарыкташ районының Рәдүт, Әбләз авылларында, Тоз-түбә районының Линевка авылында, Илек районының Озерки авылында). Аларның экспедиция хисапларына күз салсак, түбәндәгеләрне күрәбез: барлыгы 36 әкият, 2530 кыска җыр, 32 сюжетлы җыр, 27 бәет, 215 мәкаль һәм табышмак, 12 халык уены, 64 мәзәк, 28 көй, 18 истәлек язып алынган. Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре бер ай эчендә фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын туплап кайтканнар.

Һәм, ниһаять, 2015 елның июнь ахыры – июль башында әлеге төбәктәге татар авылларына яңадан комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Шарлык, Александр, Сакмар, Сарыкташ районнарында урнашкан ундүрт татар авылында булып, шәхсән

мин үзем дә атна-ун көн эчендә өч йөздән артык берәмлек авыз иҗаты үрнәкләре алып кайттым.

Оренбург өлкәсендә яшәүче татарлар арасында сан ягыннан караганда, иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була. Өч йөзгә якын җыр язып алынды. Аларның күбесе кыска җырлар.

Александр районы Султакай авылы музеенда 7–8 ел элек вафат булган Альбеков Рәшит Закир улы (1926 елгы) дәфтәреннән 224 татар халык җыры язып алынды. Әлеге дәфтәрдәге җырлар Рәшит абыйга истәлеккә моннан 74 ел элек, 1941 елның октябреннән алып 1942 елның маена кадәр, сигезенче сыйныф укучылары тарафыннан язылганнар. Мәсәлән, «Чит илләрдә» җыры: «1942 елда ФЗОда укыган вакытта язылды», – дип теркәлгән. Әлеге дәфтәрдә рус җырлары, русчадан татарчага тәрҗемә ителгән җырлар да бар. Дәфтәргә язучылар кыска җырларны төрле исемнәр астында теркәп куйганнар: «җырлар», «татарча җырлар», «көлке җырлар», «җыентык җырлар», «җырларым», «җырлар җыентыгы», «хат аша килгән җырлар», «төртмә җырлар». Ә менә Сакмар районы Татар Каргалысы авылыннан Кывандыкова Наилә Гыйният кызы (1940) безнең өчен махсус утыз җыр (ул белгән җырларның саны ике йөзгә тула икән) җырлап күрсәтте.

Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла.

Шарлык районы, Яңа Муса авылында Абдршин Марат Рузит улыннан (1962 елгы) татар халык көенә И. Юзиев иҗат иткән «Ике егет китә армиягә» җырының варианты язып алынды. Әлеге җыр халыклашкан.

Язгы ташкыннарда урсып аккан карда,
Икәү-икәү урам буйладык.
Берсе җырлый шашып, изүләрен ачып,
Икенчесе гармун уйнады.

Сау булыгыз, кызлар, сагынырсыз, кызлар,
Сагынырсыз әле без киткәч.
Сагынсагыз әгәр, без кайтканга кадәр
Шушы җырны отып җырларсыз.

Бозлар ага, кызлар, сизәсезме, кызлар,
Сизәсезме, җилләр искәнен.
Искән җилләр исәр, исегезгә төшәр,
Бездән сезгә сәлам шул булыр.

Озын көйләр татар-мишәр авылларында (Султакай, Тукай һ.б.) күбрәк сакланган, ләкин һәрбер авылда «Олы юлның тузаны», «Рәйхан», «Сарман буйларында» һ.б. җырларны очратырга була.

Татар эстрадасында да, халык арасында да популяр булган автор-композитор Рәис Ханнанов иҗат иткән «Килә ява, килә ява» җырының тарихы язып алынды. Бу җыр нәкъ Оренбург җирендә, Яфар – Сарыкташ арасында татар халык җырлары нигезендә туган булган.

Татар халкы – җырлы халык. Туйларда яисә төрле мәҗлесләрдә күңел ачкан вакытта да, авырлыклар килгәндә яисә туган ягыннан аерылып, моңсуланган чакта да, җыр кешенең юлдашы булган. Оренбург татарлары да гомер буе җырлап яши. Кунакларны каршы алу – озату традицияләренә тугры калып, алар (аерым алганда, Шарлык районы Яңа Муса, Александр районы Яфар, Сарыкташ районы Никитино (Рәдүт) авыллары халкы) безне дә изге, матур теләкләр әйтеп, җыр белән озатты.

Ерак юлны якын итеп,
Хуш килдегез, туганнар.
Хуш килдегез, сау кайтыгыз,
Сау йөрегез, туганнар[1].

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Җырласак шушы көйләргә,
Калыр сагынып сөйләргә[2].

---

[1] Кунакны каршы алганда, озатканда Шарлык районы Яңа Муса, Александр районы Яфар авылы халкы шушы җырны башкара.

[2] Кунак озатканда Сарыкташ районы Никитино (Рәдүт) авылы халкы башкара торган җыр.

Ияләр, җеннәр турындагы мифологик хикәятләр халык арасында борынгыдан сөйләнеп килгән, халык аларга ышанган, буыннан-буынга тапшырган. Бигрәк тә, татар халкында киң таралганы – атның ялын үрүче йорт анасыннан[1] башлап, Оренбург төбәгендә генә була торган, аерым алганда, Тукай авылы тирәсендәге Пәрилекүл ягында төне буе басуда эшләүче механизаторларның таң атканда трактор тәрәзәләрен шакучы, яисә Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызының (1940 елгы) әтисенең яшь вакытында каршына тавык-чебешләр булып чыгучы, аннары Яфар авылы тирәсендәге сары күпер астыннан ак ат булып килеп чыгучы, яисә әби куаклары тирәсендәге адаштыручы җеннәр-шайтаннар турындагылар бар.

Оренбург төбәгендә барлык татар халкы өчен хас уеннар язып алынды. Түгәрәк уеннан башлап, «Лапталы», «Ал тирәк, күк тирәк» белән беррәттән, аулак өйләрдә[2] традицион уйналып килгән «Наза», «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар. Әлеге кич утыруларда, шулай ук, «Почта куу», «Мунча кертү», «Күгәрчен туйдыру», «Ярма ярулы», «Үрдәккәем, чумасың», «Дуадак», «Тамчы, там», «Кристанцы», «Саңгырау телефон» кебек һ.б. уеннар аеруча яратып башкарылганнар. «Зилем» уены да булган, кич утыру уеннарын кайбер авылларда, гомумән «Зилем сугу» дип тә йөрткәннәр.

Берничә ел элек туксанынчы дистәләрен вакласалар да, малай вакытларында уйнаган уеннарын Сакмар районы Татар Каргалысы авылыннан Даутов Гыйрфан Гыйният улы (1930 елгы) һәм Сарыкташ районы Кылчым авылыннан Мөхәммәтев Гакип Сафиулла улы (1933 елгы) бүген дә бик яхшы хәтерлиләр. Г. Даутовтан «Ашыклы», «Чүрәкә» (өч төрле), «Түк-түк», «Туплы», «Мура», «Ходули», ә Г. Мөхәммәтевтән «Гәрәй алышлы», «Звезда», «Сака», «Ма» уеннары язып алынды.

Әкиятләргә килгәндә, 1960 елда язып алынган 36 әкият арасында «Әйдә, кызым, безгә» (Александр районы Тукай авылында Х. Сәлимовадан), «Аю белән өч кыз», «Әйдә, кызым,

---

[1] Оренбург өлкәсендә татарлар абзар иясен йорт анасы дип сөйли.

[2] Оренбург өлкәсендә татарлар аулак өйне кич утыру дип сөйли. Шарлык районында аулак өй дип әйтәләр.

безгә», «Алтынбай» (Сакмар районы Каргалы авылында Х. Исмәгыйлевадан), «Песәй», «Сеңлесе кәҗә булган», «Аучы», «Карунбай», «Алпамша» (Октябрь районы Биккол авылында М.Гапсаттаровадан), «Кучер малае» (Александр районы Султакай авылында Р. Яһудиннан) кебек әсәрләр бар. 12 томлык «Татар халык иҗаты»ның әкият томнарында әлеге әкиятләрнең дүртесе («Аю белән өч кыз», «Песәй», «Сеңлесе кәҗә булган», «Әйдә, кызым, безгә») басылып чыга[1], калганнары вариант буларак күрсәтелә, яисә архивта саклана. Быелгы экспедициядә бер генә тулы әкият тә язып алырга насыйп булмады. Ләкин Яфар авылында Асяев Бари исемле әкиятче булганлыгы ачыкланды һәм аның улы Ришат Асяевтан өзек-өзек булса да, әкият сюжетлары язып алдык. Чебешләр чыккан вакытка туры килү сәбәпле, Ришат Асяевның вакыты бик тар иде. Шуннан соң Л. Җамалетдиновның «Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым...» мәкаләсендә бәян ителгән хәл искә төште. Ул 1976 елда Лениногорск районында гомер итүче Миңҗамал әбидән, аның чакыруы буенча, әкиятләр язып алыр өчен экспедиция планлаштыра һәм аңа янә бер хат килә. Ул хатта аңа чебиләр чыккан вакытта килмәскә кушыла, чөнки андый чакта әкият сөйләшергә вакыты булмаганлыгы әйтелә[2]. Безнең белән дә шулайрак булып чыкты. Әмма ул хәлдән аермалы буларак, Яфар авылында кайчандыр әкиятче Бари бабай булганлыгын, хәзерге вакытта аның улы Ришат Асяевны очратасыбызны алдан белмәдек. Аның күңелендә әтисенә, аның әкиятләренә карата тирән, җылы хисләр саклана. Әтисенең әкият сөйләгәннәрен түбәндәгечә искә ала: «Аның бер әкияте айга сузыла. Ноябрь айларында сүли башлый, декабрьга бетә. Икенче елны бүтән әкият сүли. Нык озакка сузыла инде, бер-ике сәгать сүли, 15–16 яшьлекләр керә иде. Нәгыйм

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 64–67, 98–100, 172–174; Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Икенче китап /томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 222–224.

[2] *Җамалетдинов Л.* Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым... // Казан утлары. 1978. № 3. Б. 139–146.

братишкалары белән керә иде, барыбыз да йоклап калабыз шунда. Шундый иде аның комически дә, трагически да, азагы әйбәт бетә. Көн дә кичен сүли иде. Озын әкият, аны озак сүләргә кирәк».

Балалар әкиятләрне яраталар. Ришат Бари улы да әтисенең әкиятләрен бик яраткан һәм, әкият сөйлә, дип йөдәткән. Шундый вакытларда әкиятче Бари бабай «котылу» яки шаяртып алу өчен улына алдавыч әкият, яисә үзенчәлекле бер әкияткә охшаган хәл, уйлап чыгарылган хикәят сөйләгән:

«Апкайткан әкият капчыгым тышта калган. Иртән торгач чыгам да:

– Кая теге капчык? – дим.

Әти:

– Әй, телке орлаган, – атя.

Әй, елыйм ышанып.

– Ник соң кертмәдең аны?

– Онытканмын, атя, атта – чанада. Төн эчендә телке орлаган әкиятне»[1].

Әкиятче Бари бабайның улы Ришат Асяевның да күңелендә шул әкиятләр саклана. Ул аларны үзенең кыз-улларына да сөйли торган булган. Аларны күңел төпкелләреннән барлап балаларның балаларына сөйләргә кирәк. Буыннан-буынга тапшырыла барса, безнең халкыбызның авыз иҗаты, аерым алганда әкиятләре яшәр. Сөйләгәндә, һич югында, диктофонга яздырырга, яисә кәгазьгә төшерергә була.

1960 елгы экспедиция Яфар авылына да барып җиткән булса, безнең халык иҗаты фонды, шул исәптән әкиятләрнеке дә, тагы да баеган булыр иде. Бүгенге көндә Яфар авылында язып алынган материаллар шуны күрсәтте. Киләчәктә Яфар якларына янә бер экспедиция оештырылыр әле, бәлки.

Балалар фольклоры үрнәге буларак 3 алдавыч әкият, 2 әйтеш үрнәге, яңгыр теләү, берничә бишек җыры һ.б. язып алынды. Алдавыч әкиятләр чын әкият шикелле башланып китәләр һәм өчесе дә бер циклны тәшкил итәләр:

---

[1] Александр районы Яфар авылында Асяев Ришат Бари улыннан (1961 елгы) язып алынды.

«Бабай әкият сүли иде: Борын-борын заман. Ү салган иде агачтан да таштан. Сөйлимме (яңа. – *И.Я.*) баштан. Аннан балалар әйтә:

– Сүлә-сүлә.

Аннан тагы тотына сүләргә. Борын-борын заманда булган ди, бер әби белән бабай. Аларның үләре булган мордадан. Хәзер сүлим уртадан.

Борын-борын заманда булган, ди, бер әби белән бабай. Аларның үләре булган казактан. Хәзер сүлим азактан. Шулай бәхетле генә яшәгәннәр, ди.

И шуның белән әкият беткән»[1].

Әйтешләр дип балалар репертуарында диалог формасында төзелгән шигъри әсәрләр турында әйтәләр. Аларны капма-каршы ике кеше дә, бер генә бала да башкара ала[2]. Бишек җырларыннан башка, әйтешләр һ.б. балу багу поэзиясе үрнәкләре Яфар авылында гына очрады. Аларны Рәшит Асяевнең әнисе Рәмзә әбидән (90 яшь) ишеттек. Ул оныкларын кулга алу белән шуларны әйтә торган булган.

Язып алган әйтешнең «Төлке-Төләйман», «Төлке-Төләнтәй», «Төлке-Төләмби», «Аксак Төлке» кебек басылган вариантлары билгеле. Без язып алган «Төлке-Төләнби» әйтешенең иң якын варианты 1977 елда Мордва АССРның Темников районы Тархан авылында 9 яшьлек Рәшит Яфаевтан язып алынган һәм 1993 елда басылган[3].

Оренбург төбәгендә «Йокла, балам, йом күзең» һәм «Аллаһу-Аллаһу» бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек. Яфар авылында Әлфия Альберт кызы Асяевадан (1969 елгы) үзенчәлекле көе белән бергә бишек җыры язып алынды.

---

[1] Александр районы Яфар авылында Асяева Рәмзә Газиз кызыннан (1925 елгы) язып алынды.

[2] Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Р.Ф. Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 19.

[3] Шунда ук. Б. 267.

Бу төбәктән мөнәҗәт һәм бәет жанрларына караган үрнәкләр дә алып кайтылды. Алар арасында татар халкында еш очрый торган «Раббым Алла, диде Муса», «Сиңа сыгынам, Рәсүл Аллам», «Сабыр итик», «Үлем бәете», «Рәсүлулла бәете» һ.б. бар. Шарлык районы Мостафа авылында Саягфарова Сәбилә Гайса кызыннан (1943 елгы) үзенчәлекле «Әлки-әлки әлләли, Әлхәм белмәс әлләзи» башламы булган мөнәҗәт язып алынды. Ул аны әнисеннән (әнисе үзенең әнисеннән) өйрәнгән булган. Оренбург төбәгендә «Лә иләһе иллә Аллаһы» мөнәҗәте киң таралган. Берничә вариантта язып алынды.

Сирәк булса да халыкта бәет чыгару традициясе яши әле. Шарлык районы Яңа Муса авылында Сафарова Зөмәрә Бәсим кызыннан (1946 елгы) «Наза бәете», Абдершина Раушан Бари кызыннан (1940 елгы) «Наил бәете», «Раушаным» бәетләре һ.б. язып алынды.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълуматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән мөмкин кадәр бер күренеш буларак язып алырга тырыштык.

Шарлык районы Мостафа авылында Муса Җәлил, Сакмар районы Каргалы авылында Пугачев, Каргалы авылы яну турындагы сөйләкләр һәм Юрий Гагарин турындагы истәлек тә язылды.

Оренбург өлкәсе Шарлык, Александр, Сакмар, Сарыкташ районнарында яшәүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

## Мифологик хикәятләр (ияләр, женнәр турында)

Картлар сөйли иде. Каравыл куышларында шунда печән өстендә. Җыелабыз малайлар. Анда куна яталар инде. Конюх була инде. Ул әкият эчендә йөзгән Мөдәрис абый дигән. Ул мәрхүм булды күптән түгел. Минем дус та иде. Төрле куркынычлы әкиятләр. Ул чын итеп сөйли иде, еланнар турында, әллә нинди, кеше буып үтерә, дип.

Йорт анасы дип сөйли иде Мөдәрис абый. Минем, ди, бер атны, ди, үрә, ди ялын һәрвакыт. Сүтәм – үрә. Яратканга, ди. Ничәмә ничә ел үрде, ди.

Убырларны сөйлиләр иде. Куркыта дип бала-чаганы. Урманга бармагыз – елан чагыр, убырлар бар дип. Убыр җен кебек, белмим. Вроде тунны кирегә кисәң шулай була дип. Шундый ошаган, ямьсез. Убыр куа – үтерә, үзенә алып китә. Урманда яши, өе бар.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Сәфәров Фатих Фәйзи улыннан (1944 елгы)*
*язып алынды*

Бу якта Иске чокыр, Кәтәмин чокыры дигән – шушы тау ягы бит ине. Шүрәле чокыры бу якта, әнә Котыев турында.

Быел әллә 300 ел була диме безнең авылның салынганына. Авыл артмый, шүрәле каргаганга артмый, диләр. Инәйләр сөйли ине. Кыйнаганнар икән дип сөйлиләр ие. Шуңа күрә Шүрәле каргаган да. Мона соңыдан утырган авыллар арта, безнең авыл шуңа күрә 60 ка җитә дә кими, 60 ка җитә дә кими, 70 кә дә җиткәне юк.

Каршыда гына Түгәрәк тау, аның кырында имәннек дигән урман бар, Шакмай чокыры бар авылны чыккач.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Кәбирова Зәрә Заһретдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

Менә элгәре, без школда укыганда безгә әтәләр ие. Школның бер класында ике пич ие. Шул пичтә җеннәр бар дип сүли иде. Школны карап техничка әби шулай ди торган иде.

Нәнәй[1] (әни дидем инде мин аны, әни урынына калган) безнең завхоз да булды, пич тә якты. Шул чагында мин бара ием, бәләкәй чагым. Сызып-сызып куя иде теге пич яннарын.

– Җеннәр килә, балам, монда ятма. Акбур белә сыза, Аятелкөрси укый да шулай иттереп сыза. Без шунда ятабыз, акбур белән сызган круг эченә. Ә тегендә биишеп йөриләр ие, без бәләкәй иек. Акбурны мичтән ераграк, ята торган җиребезгә сыза. Парталар күчерә иек тә, шунда йоклый идек. Мәрхүмкәем, әни

[1] Нәнәй – әби.

бит инде олы кеше. Йокламыйча бит иртә пич ягарга кирәк. Кирпич-тизәк белә ягырга ие. Кайчак соң кайтабыз аннан, кайчак иртә китәбез дә ятып торабыз. Пичкә ут куябыз да ятабыз. Ике пичкә. Ул кирпич (тизәк) кайчан узып бетә. Хәзер бала-чага школга килә укырга. Кайчан килгәч әле кирпичне тыгалар да бала-чага, төтен чыгара да, узмаган дип кайтып китәләр, исе бар дип, бала-чага шундый усаллар ие.

Җен чыннан булган. Фәзилә исемле әби ие. Постоянно әйтә ие Фәзилә әби мәрхүмкәем:

– Балам, читтәрәк йөрегез, менә шунда сызам да, аятелкөрси укыйм да, шунда ятыгыз. Укыгыз безнең арттан дип әби укыта иде. Укып шунда ята идек.

– Ана йөриләр, ана йөриләр, дип әйтә иде.

*Александр районы Тукай авылында*
*Морзакаева Люция Саях кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

«Пәрилекүл» – пәриләр булган. Әле дә җеннәр бар. Механизаторлар төнгелеккә эшләсә таң алдыннан тәрәзә суккан кебек дип куркалар.

*Александр районы Тукай авылында*
*Вахитова Сәрия Самат кызыннан (1970 елгы)*
*язып алынды*

Безнең элгәре әтиебез Гарифулла Хәтчәсе белән йөри торган булган. Әбиебез яратмаган. Аның бер баласы ятим, тынышмаслар дип. Әти әтә ие: шул Ягафар бабаңнарның проулыгыннан кайтканда вак чебеш ияртеп чыга тавык һәрвакыт дия иде. Юк җирдән чебеш-тавык килеп чыга. Аннан югала. Бу безнең өске урамнан. Фәрхәнә проулогы диләр иде ул урынны. Җеннәр булган, шуннан аннан йөрми башладым. Инәй: менә, Аллаһы Тәгалә риза түгел, дип әйтә иде дип сөйли иде әти.

Мин комсомолга тордым, пионер идем. Әбиебез яратмый бит инде. Шуннан, Алла юк, дип әбиебез белән спорлашып торам. Бермәлне берәү тәрәз суга: туктыйсыңмы юкмы, дип. Ник шуннан соң бер тавыш чыгарыйм. Әбиебез әйтте: Йорт иябез яратмады сине, Алланы яманлап сөйләгәнгә, дип. Йорт иясе шул абзар иясе инде ул. Ул белдерә. Менә сыер бозауласа шакый ие.

Менә шундый ие элгәре. Хәзер юк. Ат тотаек без. Шуны үрә иде. Ялын матур-матур иттереп үреп куя иде, ә яратмаса, шыбыр суга төшә ие – тиргә бата ие.

Көтү чыкканда күкәй бирә иек. Бөтен авылдан 1–2 бидра җыела. Хәер итеп бирелә: күкәй кебек исән сау тәгәрәп йөрсен маллар, дияләр ие.

*Александр районы Тукай авылында*
*Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Җеннәр былган күп. Сары күпер бар анда җен былган бер атка әйләнеп чыга былган постоянно күпер астыннан. Ак ат булып и туктаткан. Например, барасың күрше авылга, урыс авылына, чыга былган, атлар бармыйлар. Аннан анда юлчылар төшеп чыбыркы шартлаталар, теге ат кире кача булган күпер астына кереп. Чыгып сүгенгәннәр наверно, потому что ничек куркытасың шул женне. Әле чыкмый, әле ул күпер дә ишелде. Или бүтән ергә күчкәнме?

Әби куаклары бар. Анда җеннәр күп. Анда постоянно адяштыра любой кешене. Шунда янәсе әбиләр җирләнгәннәр. Ничектер әбиләр адяшеп үлгәннәрме шунда, әби куаклары дип йөртәләр анда женне куакларны. Анда җәен дә адяшеп, кемнәр килмәсен, то теге якка китәләр, то кире китәләр. Шундый җир.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяев Ришат Бари улыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Әбиләр сөйли торган ие. Пәри булган, җен булган анда. Булмаган әйберләрне бар иттереп.

Значит, бәләкәй вакытта ятасың бит, 3–4 бала күршегә кереп. Әби караулап ята, ул да шунда ята безнең белән бергә. Шул хәтеремдә торып калган бер әкияте:

Имеш, бер дию дип әйтә иде микән. Менә ятам, ди, тәрәзәдән, ди, боз каткан, ди, җәй көне.

Теге дию, ди, телен чыгарып теге бозны ялап торадыр ие, ди.

Без инде куркып (куркабыз. – *И.Я.*), бәләкәй бит инде. Шундый фурмыда сөйли торганнар ие.

Шуннан, әгәр дә китсәң, синең йә булмаса күзең сукыраеп кала, йә кулың кәкрәеп кала.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Даутов Гыйрфан Гыйният улыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

Әбиләр сөйлидерие:

Эссе мунча, суык таш,
Чабына икән ике таз, – дип.

Шул ике таз – җен булган икән. Эссе мунча булган, ә ташы суык булган.

* * *

Минем әнинең әтисенең сараенда атлар, маллар булган. Нык зур ут чыкканчы бөтен авыл янганнан алда әби-бабайның маллары күп булган. Ике этажлы өй ул вакытта. Асты таш, өсте агач. Вич Каргалы яна. Аста таш сарайлар гына калган. Теге кухня, ә өстә вич янган бөтен 2 этажлы өй. Андый өй 1 генә Каргалыда калган. Ут килеп еткән дә туктап та калган. Нинди өй булган ул? Әле ул тора. Сельпо өе диләр. Анда сельпо булды. Шуннан бу әби-бабайлар вакытында әни сөйли болай дип:

Иртән чыксалар сарайга, атның ялы үрелгән, ди.

Шуннан балалар сорау бирә икән:

– Әти, ә нигә чәчләре үрелгән аларның?

– Аларны – атларны җеннәр ярата. Алар атның бугын ашый. Алар атларның чәчен үрә, дип әйтте, ди.

Сарайларда җеннәр булган. Ә элекке җеннәр – шайтаннар даже күренеп йөргән дип сөйлиләр. Ак төстә булган алар. Төннә караңгы, алар ак икән, озын. Ул кеше түгел, ә шәүлә кебек. Бабайлардан сорагач, минем бабай, әтинең әтисе, ә аны бит җеннәр үрә аларның ялларын. Иртәнчек чыксалар, атлар вич тиргә батып тора икән, тирләп.

Әй, шайтаннар, тагын атларны чапканнар ине. Әти тиргәнеп керәдерие, ди.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Кывандыкова Наилә Гыйният кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Әйтәләр ине шулай. Мәктәпкә барган вакытта минем бер туган сеңлемнең улы ул, мин әйтәм менә шушы ердә, ай алла, убыр, диләр ие. Шушы өй, тыкрык янында үткәндә. Убыр дип сөйли идек. Ут күренә дип. Убыр бар, тыкрыктан йөгерә. Әйтәләр ие соңга калып мунча кермәскә, караңгыда. Җен була имеш, дип.

Өйдә берүзең генә тормыйсың, өй анасы бар диләр. Тыныч булмаган өйләрдә була икән ине. Борынгы әбиләр әйтәләр ине.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Даутова Гөлҗиһан Әбдерәшит кызыннан (1926 елгы)*
*язып алынды*

## Риваятьләр-легендалар, сөйләкләр, авыллар тарихыннан

Әтидән сорыйлар иде. Бу авылның датасын белмим, күптән инде. Муса дигән бер кеше елкы – атлар куып килгән. Башкириягме, Татария ягыннан микән, корылык булган, монда ашатырга килгән. Монда шундый таулар бар: ике ягы Тәңгре тау дибез – Ходай бирде, дигән сүз. Сарай кебек ике яктан каеннар каплаган. Бетте ул. Безнең мონаннан ук урман тотына иде, бернәрсә калмады. Җир өчен. Шул Муса монда атларын керткән. Тәңребирде тау зиратның теге ягы. Аны белмиләр дә хәзер.

Илькульган бар. Анда сазлык кругом булган. Аның һаман тәрҗемәсен табалмыйлар. Минем әтидән килеп, Казаннан кайчандыр сорадылар. Илькульган – Елкы үлгән дип. Анда елкылар тоттылар, дип. Сазлыкка атлар батып үлгәннәр. Эсседәме, өркеп, таудан килеп төшеп, шунда батып үлгәннәр. Елкы үлгән – Илькулган дип исемен биргәннәр шул урынга. Хәзер анда авыл – рус авылы. Мусага 200 дән артыктыр инде, 220 ләрдер.

Аккош күле бар иде. Бетте алар кибеп. Аккошлар төшә иде. Күл юкка чыкты. Анда буа буалар иде ел саен, тегермән торды.

Бәбәй тавы – бәләкәй тау. Шунда ведролар белән су алып менеп укыганнар – теләгәннәр Алладан. Минем әти коммунист – бармаган инде анда. Төшүләренә яңгыр яуды, ни хикмәт, ди.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Сәфәров Фатыйх Фәйзи улыннан (1944 елгы)*
*язып алынды*

Минем нәнәй әйтә иде. Якуп исемле абыем, Ильяс исемле абыем булган. Якуп дигән абыем, менә, ферманы үткәч второй ферма бар, шунда илтеп салган избаны, Ильяс исемле абыем «Якут»ны (авыл исеме. – *И.Я.*) салган. Якут чыккан Тукайдан. Нәнәй Рәхмәтуллина Разия Юныс кызы 1883 елгы иде. Тукай борынгы авыл. Бездә 400 йорт, Якутта 60–80 генә. Тукайда чишмә бар. Батакүл дибез. Белмим. Берәрсе батканмы? Мал фәлән батып шулай Батакүл дигәнбезме. Таулар – картыс тау дибез.

*Александр районы Тукай авылында*
*Морзакаева Люция Саях кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Белмим ни өчен Тукай. Бүрлек елгасы, Картус тау – шунда бер таш утыра, биек таш. Ташның бер ягы кителеп алынган, шунда без йә ашарга, йә акча куеп китә идек менеп бала-чагалар белә.

Әби тавы – әбиләр туңып үлгән, без юк идек ул вакытта. Апрель аенда тирмәннән кайтышлый. Тирмән казанкада ие. Үзем дә барганым бар бәләкәй чакта. Уфалла арбасы белән кайтып барганда, адашып, биш әби туңып үлгән. Авылда җирләгәннәр.

*Александр районы Тукай авылында*
*Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Җәгъфәр дигән кеше килгән булган. Урыс авыллары бит инде. Берәүдән:

– Куда едешь? – дип сораганнар.

– Яфару.

Шулай Яфар булып калган. Асяевлар Пенза ягыннан килгәннәр 1790 елларда. Безнең авылыбыз элек Клат (Кулатка) дип аталган. Элеккеләр Яфарны белмиләр иде, дия иде әби. Әбиебез әйтә икән:

– Минем әтием, күп баласы булган, килгән Искедән.

Әби сораган:

– Нинди Искедән?

Иске Клаттан, дип җавап биргән әтисе.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Рәкыя Бари кызыннан (1954 елгы)*
*язып алынды*

Пугачев Каргалыда булган. Сакланган йорты бар. Кызыл таштан ясалган. Пугачевның штабы булган. Өлкәннәр шулай дип сөйли торганнар ие.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Даутов Гыйрфан Гыйният улыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

Килгән ул (Пугачев). Бер көн йоклап киткән.

Каргалының беренче өен – крепость кебек салынган – кызыл таштан. Беренче кешеләр Хаялиннар. Шул иң беренче килеп шул өйне салып Хаялин, шул Каргалыга нигез салган.

240 семьяны вич таратканнар Кушкүлгә, Үрге Чебенне, Түбән Чебенне, Сакмар, Каргал, Башкирия ягына.

Шуннан Пугачев шул өйдә кич кунып киткән. Гаскәре белән. Восстание ясап йөргән кешеләре белән.

Безнең аклар-кызыллар сугышы көчле булган. Безнең авылда 72 кешене – безнең коммунистларны бер көндә атып үтереп аклар, братский могилада 72 коммунист ята.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Кывандыкова Наилә Гыйният кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Биятай мәрхүм сөйлидерие. Мин, ди, зияратта булганмын 3 яшемдә дип сөйлидер ие. Зияратка менеп киткәнмен дип. Шуннан соң бием мәрхүмә сөйлидерие. Сакмар суына төшеп утырды халык, ди, киезләр вич шунда, ут төшә, ди. Күгәрченнәр очып килә дә өйне яндыра, очып килә дә өйне яндыра, ди. Шундый ут чыккан. Ике мәртәбә янган ул Каргалы безнең.

Берәүдән ут чыккан. Сагыз кайнатканнармы борында, шуннан соң күгәрченнәргә ут эләгә дә икән, күгәрченнәр өйгә килеп төшә икән. 1919 елны. 1919 елны минем зур абыем туган. Кулымда, ди, әни мәрхүмә сөйлидерие: бала, ди, и поднос, өй биек иде, ди, баскычтан шуның белән төшеп калдым, бер поднос чинаяк кына алып калдык дип, вич гөрләп янды. Менә 1919 елны янган исемә яңа төште. Күгәрчен ут чыккан ергә килеп куна да, оча да, икенче өйгә барып куна. Ут хәтәр ул.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Монасыйпова Фирдәвес Абделгазиз кызыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

## Йолалар, гореф-гадәтләр, ышанулар

Мин кечкенә вакытта миңа «Карга боткасы»на дип зүрнәй күлмәк тегә торган иде. Яңа күлмәк киеп без күпер башына бара торган идек. Ә менә хәзер балалар белән шул «Карга боткасы»н үткәрәбез. Беренче көнне чыгабыз урамга, балалар кулларына кәрзиннәр тоталар, йортларга килеп җиткәндә инде:

«Өйдәме, түтәй?
Тизрәк бир күкәй.
Безгә бирсәң 3 күкәй,
Тавыгың салыр 100 күкәй.
Он кирәк, ярма кирәк, май кирәк,
Карга боткасына бар да кирәк.
Чыгар, түтәй, тизерәк!

– Рәхмәт, түтәй, синең кебек уңган түтәй бу дөньяда бик сирәк!»

Шундый такмаклар әйтеп. Бу сүзләр электән үк килә шушы фурмыда. Шулай итеп, балалар күкәй җыйнаганнар. Кечкенә чакта мин үземнең алай йөргәнемне белмим, тик зүрнәйгә ияреп, күпер башына карга боткасына барганым истә. Ботка ашаганым да истә түгел. Ну менә исемдә күпердә яшьләрнең (апайлар инде безнең ул вакытта) төрле кичке уеннар уйнаганнары исемдә. Ә карга боткасын кешеләр шулай итеп көтә торган иде. Ә хәзергесе вакытта без күкәй генә җыйнамыйбыз, безгә ярма да бирәләр, он да бирәләр.

Акча да бирәләр, кәнфитләр дә бирәләр. Кешеләр көтеп торып бирәләр. Кайбер апайлар пешереп апчыгалар, ашагыз балалар, дип. Ул көнне дә инде балалар өчен бәйрәм була, арыйлар инде ике урамны да йөреп чыкканчы. Икенче көнне инде, без элек клуб каршысында үткәрә торган идек, хәзер безнең реконструкциядән соң менә монда площадка бар – шунда борынгы тастымаллар эләбез, төрле шарлар эләбез, тасмалар эләбез. Аппаратураларны чыгарабыз, өстәлләр куябыз, шуннан соң скамейкалар куябыз, зуррак кешеләргә утырырга, ботка пешерәбез. Ботканы инде символически, казанны өч аякка утыртабыз, ә ботканы мәктәптә поварлар зур кастрюльләрдә пешерәләр. Пешерәләр дә, без шуларны апчыгабыз, шуннан соң кешеләргә.

Башта инде:

– Балалар, әйдәгез, учак ягыйк, казан асыйк, – дип казанны асабыз инде, шул арада әйдәгез җырлар җырлап алыйк, нинди җырлар өйрәндегез, нинди шигырьләр өйрәндегез. Яз турында, кошлар турында шигырьләр сөйлиләр.

Шуннан соң уеннар уйнап алабыз. Шуннан соң ботканың пешкәнен карыйсың:

– Пешкән ботка!

– Тәмле булган боткасы!

Ботка ашарга башта инде олы кешеләргә таратабыз. Ботка ашыйлар, утырып чәй эчәләр, аннан балалар өстәл янына шулай җыйнала. Шуннан уеннар китә инде. Алар ашаган вакытта концерт номерлары бара. Балалар төрле уеннар: капчык киеп тә йөгерәләр, күкәйне кашыкка салып та йөгерәләр. Төрле-төрле шулай иттереп уеннар үткәрәбез инде. Балалар көтәләр инде ел саен, кайчан карга боткасы үткәрәбез, дип.

1990 елларда туктап торды ул. Үткәрелмәде. Карга боткасы – апрель урталарына туры килә. Яз иртәрәк килсә – апрель башы, җир кипкәчтен, көн елынгач.

Нигә үткәрелә карга боткасы – балаларга аңлатабыз: бу менә борынгыдан килгән бәйрәм, кешеләр елыны, кояшны, кошлар алып килә дип уйлаганнар, шуңа күрә каргалар килгәчтен куанышып бәйрәм ясаганнар (*көлә*), ботка пешергәннәр, каргаларны сыйлаганнар.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Гобәйдуллина Нәфисә Фатыйх кызыннан (1959 елгы)*
*язып алынды*

Элек туйлар шундый озакка бара торганые. Башта яучы бара. Аларны бер көндә бирми. Икенче көндә бирмиләр әле кызны, килешмиләр. Өченче көндә килешсәләр килешәләр, яучы барганнан соң. Аннан соң инде кызны килешкәч, егет ягы чакыра кызның әти-әниләрен, туган-тумачаларын чакыра да, туйга хәтле, шуннан соң инде кыз ягы чакыра. Шуннан кодалашу башлана. Бу ике як сөйләшкәннән соң. Шул чакырган вакытта, егет ягы, сөйләшәләр бирнә бирүне. Хатын-кызга элек материал инде, яулык, күлмәклек. Ир-ат затына – күлмәк, нәски,

кулъяулык. Бирнәләрне туйда тараталар. Сүзгә остарак халыклар бирнә биргән вакытта инде:

– Кода сак бул, менә хатыныңа бирәбез, ни, японский шолк. Көлдертә-көлдертә бирнәләрне биреп чыгасың. Аннан кыз ягы егет ягына бирә инде шулай иттереп. Ә кызлар инде әзерләнә: тәрәзәсенә фәрдәсен, челтәрен алып бара, караваt өсләренә ябарга юрганын, пар мендәрләрен, бөтенесен дә алып бара инде теге үзенең төшкән йортына. Килен булып хезмәт итә. Килен булып төшкәндә, киленне каршы алалар ашлар пешереп, табыннар тезеп. Егет ягыннан да, туган-тумачалары, яшьләр бергә җиналалар да, шунда күңелле итеп утырып, киленнәрнең кайсын су юлына аббаралар инде. Су юлы күрсәтәләр инде. Кайсыларына яулык бирә, кайсыларына бияләй бирә. Менә шулай иттереп су юлыннан йөреп кайталар инде. Киленне су юлы белән таныштыралар. Элек чишмә булган. Бер кеше чишмә юлына киез куеп туктаткан.

* * *

Сабан туе элегрәк булды. Маевка да булды. Но хәзер, нишләптер, тукталды бит. Әйбер җыйдылар. Атлар белә чыгалар да, зур таяк. Шуннан соң теге таякка әйберләрне бәйләп атның дугаларына бәйләп җыйнап чыга торганнарые да, шуннан соң инде Сабан туенда тарата торганнар ие кемгә нинди. Берәү җиңәме, җиңгәнгә нәрсә бирергә, шулай тарата торганнар ие. Жюрилар кебек халык утыра. Җыйнап йөргәндә үзебез чыгып карап тора торган иек. Менә хәзер карга боткасы ясыйлар болар. Матур иттереп гармуннар белә урамга чыгалар. Укучылар чыгалар. Шуннан соң инде карга боткасы дигәч күкәен чыгарабыз, кем акчасын бирә. Шуннан болар клуб каршында боткалар пешерәләр, шуннан бөтен халык җыйналабыз, барабыз шунда, шуннан безгә савытларга салып ботка пешереп бирәләр, күкәйләр пешереп, кәнфитләр, самавырлар куялар, аннан шунда үзләре вич җырлыйлар, яшьләр дә җырлый, кайсы гармун уйный, үзебез дә төшеп китеп биибез шунда уйныйбыз, бик күңелле була карга боткалары.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Фәтхуллина Миңлегөл Гали кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

**Туй йоласы.** Килен төшә инде. Мин үземнең төшкәнемне сөйлим сезгә. Кияү килә безне алырга инде. Ат белән, пар атта. Баштан кияү генә килә. Кияү алучылары була аның янында. Кызны алырга килгәч, аларны йөртәләр, берничә ергә кертәләр кунакка, сыйлыйлар. Алар кергән ерләрендә – кияү, кыз пока өендә тора, кайсы ердә кунакта йөриләр алар, шуннан нәрсә булса да урлап алып чыгарга тиешләр. Кашык урлыйлар, әтәчләрне чыгып урлыйлар. Менә шушы килен алырга килгәндә инде. Менә шушы әйберләрне урлыйлар да күрсәтмиләр. Хуҗа инде тик йөри урлатмаска. Урлыйлар да, шуннан киләләр кызның йортына. Кыз инде әтиләре-әниләре белән саубуллаша, утырталар анда парлап та, ә тегеләр артта бер 3 чана пар атлар иде инде элек, әле инде атлар бетте. Менә шул вакытта тегеләр урлаган әйберләрен урамнан селкә-селкә, әтәчнең аягыннан тотып, килен төшкән йортка алып баралар инде шуларны. Шуннан инде, мәзәк өчен генә инде, аннан бит инде кирәк әйберләрен кайтаралар, кирәкмәгән әйберләре кызда кала инде.

Ябалар бит инде беренче көнне кияү белә кызны. Аннан аерым өй була инде аларга, кияү егет була, әлеге вакытта свидетель диләр инде, кыз ягыннан да була. Алар кыз белә кияүне калдырып китәләр дә, сәгать 4 тән (иртәнге) мунча әзер. Кияү белән кызны иң беренче мунчага ебәрәләр. Пока аларның йокылары туймаган, аларны илтәләр мунчага. Мунча яга инде кызның җиңгәсе (абыйсының хатыны или якын кешесе). Мунчада алар бу ягучыга ниндидер булса да подарка салып китәргә тиешләр, салып китәләр. Аннан соң килгән кодалар бар да ул мунчаны керәләр. Кияү мунчасы диләр иде. Кияү мунчасына барысы да подарка салалар. Элек шулай иде, хәзер кафе-барларда үткәрәләр. Мунчасы бар инде.

**Кияү коймагы.** Итсез коймак иде ул вакытларда. Аннан кияү пилмәне була иде бездә. Менә шундый гына (кечкенә) ваквак ясыйлар. Безнең заманда кызның чисталыгын күрсәтә иделәр, әле юк. Чыбылдык. Иң беренче кергәчтен кайна белә кайната килә инде. Карый постелен ачып, анда күренә инде.

*Александр районы Султакай авылында*
*Агишева Галия Мөхәммәтҗан кызыннан (1945 елгы)*
*язып алынды*

Туйлар инде нык шәп була иде. Берәр атна. Например ничә кода булса, бара икән синең туеңа анда 5 пар кеше – 5 кода – 5 көн була. Һәрбер кодага 1 көн. 7 кода була икән – 7 көн. Мин үземә бер көн алам, иртән торуга мунча ягам, аш салам. Кияү мунчасы була.

Туй көнне кияү коймагы. Кызны алырга килә егет. Шуннан кыз ягындагы кешеләр коймак чыгаралар. Түгәрәк майланган коймак. Кияү анарга акча сала. Аннан ул ала да, аннан икенчесе килә. Анда бер генә коймак булмый – берничә була. Аның барсына да кияү акча сала.

Кияүгә пилмәнне вак кына ясыйлар иде. Матур була дип. Шундый бәләкәч кенә.

Киленне сорый булганнар инде. Например, лампыны куялар пузырьлы. Пузырьне себермичә генә, әгәр дә килен белекле булса, әйбәт булса, ул пузырьне алып себерергә тиеш. Шуны тикшерәләр.

Кайсыберсе, белеклесе, идән юа. Аннан соң камыр басыралар килennән. Карыйлар, киленнең куллары ничек анда: нык буялганмы камырга? Аннан соң баскан талинкасы шомамы? Камырлы түгелме? А ту бит чип-чиста итеп калдырасың баскан савытыңны. Шундый сынаулар инде.

Тегеләр коймак белән чыгалар. Болары күчтәнәч апкилә. Аларга:

Ничек килдегез сез безгә,
Батмаенча диңгезгә.
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итик сезгә.

Кодага ерлап бирә:

Стаканның төпләрендә
А хәрефе бар әле.
А хәрефе күренер,
Әйләндереп карале.

Әйләндерер өчен эчеп бетерергә кирәк. Ике якта да шундый ерлар була иде.

Стаканың тулы түгел,
Ерлап тутырыйк әле.
Кодаларның күңеле булсын,
Ерлап утырыйк әле.

Атна буена туй ясап күп ерлар ерлана. Иртә таңнан мунча ягасың, мунчага бөтен кодалар килә. Аларга чәй эчерәсең. Аннан арада минем ягымнан берәү ашка чакыра, өйлә вакыты була инде ул. Аннан тагы кичкелеккә мин үземә алам, төне буена утырырга:

Әй, кодалар, сезнең өчен,
Укадан бау үрәмен.
Күкрәгемдә яным ничек,
Сезне шулай күрәмен.

Аннан ул үзе теләгәнен ерлый, капма-каршы:

Эй, кодалар, кодалар,
Кодалар-кодачалар.
Сездә ничек, бездә шулай,
Уйнап күңел ачалар.

Аннан чыгаралар бутка. Анарга калакларны шулай төртеп-төртеп куйганнар. Төртәләр инде китәргә. Аннан соң чыга да, берәрсе стенага кага тыштан. Янәсә (янәсе. – *И.Я.*) дә, бу китү билгесе.

Шак-шок, ә стенаны кага инде, безгә китәргә вакыт етте, диеп инде. Вакытын белеп кага инде, теләсә кайчан түгел. Кодалар кодаларны кызык иттереп, кодалар киткәндә, арбага утыргач, кулларына кишер тоттыралар. Туйдан кайтканда кодалар берберсен сүләшеп кайталар, тикшереп туйны, бусы әйбәт булды, тегесеме начар булды, бу җитешмәде, йә арттырып җибәрдеме – шуларны тикшерергә урын калдырмас өчен кодаларга кишер тоттыра да кулына:

Янәсә, безне чәйнәп кайтканчы, кишер чәйнәп кайтыгыз! – дип.

Кияүне куенга кертү дә бар иде. Кияү килә дә кызның йортына ул була кияүне йортка кертү. Шунда урын карарга да керәләр

агай-эне. Шунда акча салып та чыгалар. Кызның урынын карага керәләр янәсә дә. Беренче көнне кияү белән кызны җиңгәләре саклап тора. Аннан инде бар-югын чыгып сөйлиләр: тегеләй булды, болай дип. Хәлләрен коймак белән кереп беләләр. Шунда кияү коймак ашый.

Ишек бавы тоту да бар иде. Кыз янына керер алдыннан. Ишекне тоталар, кертмиләр кияүне. Әйтәләр:

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын, дип.

Шуннан:

Без килмәдек, буш китәргә,
Килдек алып китәргә, дип, –

инде кияү акча бирә. Акча биргәч кертәләр.

Элек баш кодагый килә торганнар ие. 2–3 мәртәбә. Башта болай гына килә. Монда ыштан балагын чыгарган берсен. Яучы килә, бер балагы чыккан. Янәсе дә яучы булып килгән. Шуннан белгәннәр инде, аның яучы булып торганын.

Килделәр. Безнең үләнергә булгач сәфәр ае булды. Сәфәр аенда янәсе туйлар уйнарга ярамый. Шуннан без 1 ай буена тордык өйләнешмичә, сәфәр ае беткәнне көтеп. Шундый тәртипле, бер-беребезне күрмәдек тә хәттә.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Рәмзә Газиз кызыннан (1925 елгы)*
*язып алынды*

Килешергә килделәр. Элек сөт сатар идек битун белән. Сөт сатып пич янында торам, бер карт кына бабай килеп керде дә ишеккә, менә шулай итеп торды да, мин пич янында елынып торам. Әни, мин әйтәм, бу нинди кеше ул, ул бит түшәмгә карый, ул чыгып киткәч инде. Ярар, белмәсәң дә ярар.

Мунчага чыктылар. Аның туганнары мунчада эшли икән. Әнә шул ике ятимне туры китерергә кирәк, дип сөйләшкәннәр мунчада, өйдә дә түгел, колхоз мунчасы элек бар ие бездә. Шуннан килде, «колак сөенчесе» дип атала. Теге яулык белә акча китерәләр бит. Килә дә керә икән, мин белмим вообще. Мин ул

вакытта өйдә тормадым да. Колак сөенчесе килде, мәһәр килде. Мәһәр килгән дә, чанадан алдылар әхә-хә дип көләләр, мин бернәрсә дә белмим. Мәһәр килгәч: кызым, клубка чыгасыңмы әллә? Миңа элек чыгарга ярамый иде, хәзер ярады. Мин ничек тормышка чыкканны да аңламадым даже.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Назыйрова Мәдинә Габделхак кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

## Бәетләр

### *Наза бәете*

*Фатихның сеңлесе кибеттә сата иде. Аннан Казахстанга киттеләр. Ул анда үлде дә, анда күмделәр үзен.*

Риза булыгыз, халкым, рәнҗетмәдем,
Кибетләрдә сату иткәндә.
Авылыма бер тутырып карадым,
Чит илләргә чыгып киткәндә.

Эшем яхшы иде, авылым – матур,
Ризыклар шулай аерды.
Киткән чакта нидер сизгән кебек,
Күңелләрем бик нык кайгырды.

Бер кыз бала таптым киләчәктә,
Сердәш булыр диеп үземә.
Икәү генә калгач, моңсу итеп,
Тутырып карый иде күземә.

Шулай моңсу итеп караганда,
Уйлый идем авыр көнемне.
Тормыш дулкыннары җил чыгарып,
Сындырдылар бәхет гөлемне.

Мин үлгәч тә, кайгырмагыз,
Язмышларны һичкем узалмый.
Күпме генә елап кайгырсаң да,
Кыска гомер артык озаймый.

Хәзер минем сезгә теләгем шул,
Кызымны бар диеп белегез.
Тормышыгыз кушса, мөмкин булса,
Килеп аның хәлен белегез.

Руза кызым матур булып,
Үземә ошап ул үсәр.
Ятлар читләгән вакытта,
Әнкәсе исенә төшәр.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Сәфәрова Зөмәрә Бәсим кызыннан (1946 елгы)*
*язып алынды*

И, Раушаным, Раушаным,
Колагымда тавышың.
Каберләрең калдырып киттем,
Туган якка агышым.

Бик зур шатлыгым булдың син,
Мәрхүм абыеңнан соң.
Әҗәлләр тартып иткәндер,
Инде нишләтием соң?

Башкаең өзелгән кебек,
Бәгырьләрем өзелде.
Шул чактагы кара кайгы
Мәңгелек дип сизелде.

Китмәс идем сине ташлап,
Ризык бетте, күрәсең.
Үлем-аерылу газаплары
Маңгайдадыр, күрәсең.

Кара-кашым, кара күзем,
Төшермәдем теземнән.
Чит туфракларда калсаң да,
Чыгармамын исемнән.

Пар алмаларым калды шул,
Калды үзбәк җирендә.
Ходаем ярдәмнәрең бир,
Күчеп кайткан җиремдә.

Ах үземнең хәлләремне,
Кешеләргә сөйлим әле.
Эчемдәге моң-зарымны
Бәеттә көйлим әле.

Үстердем бит кочып-сөеп,
Үстердем шәфкать белән.
Ә хәзер яшим дөньяда,
Тик сезнең хәсрәт белән.

Балакаем, тыныч ят, син,
Нур уйнасын гүреңдә.
Тыныч ятып гүрләреңдә,
Бул син оҗмах түрендә.

Бу шул башы өзелгән кызына карата. Урта Азиядән кайткан апаның кызына. Ул инде малае үлгән була, шуның каберенә барырга, кызы да еткән була, шул машина астында кала. Берсенә барам дип, икенчесе дә үлә. Аннан монда эшләделәр, аннан киттеләр күчеп тагын Башкириягә.

Башкортстанда туып (бу апа инде) гаилә тормышын Үзбәкстанда үткәргән, картлыгында Яңа Муса авылында яшәүче күршем Фәндия апаның кызы Раушания истәлегенә (фаҗигале үлгән).

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдершина Раушан Бари кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

### ***Наил бәете***

*(Тормыш иптәшем Наилгә багышлыйм)*

Бисмилла диеп башлана
Изге корбан гаете.
Мин язамын, сез укыгыз,
Наилемнең бәете.

Тарих мең дә тугыз йөздә,
Туксан икенче елда.
Мичкә эчендә вафат булды,
10 нчы ноябрьдә.

Соңгы катлар чыгып китте,
Иртәнге чәйне эчеп.
Мин киттем дип, – шикле әйтте,
Калдым эчләрем сизеп.

Шикләнсәм дә, башыма килмәде,
Күзенә тутырып карарга.
Күбесе озатып кала идем,
Чыгып ишек алларга.

Навозлар[1] ташырга киткәч,
Кире әйләнеп кайтмадың.
Оныгың белән күпме эзләп,
Берничек тә тапмадык.

Икенче көнне Ринат белән
Икәүләшеп эзләдек.
Күпме генә йөресәк тә,
Күренмәде эзләрең.

Луиза, Ринат, Илдус китте
Торак йорттан карарга.
Илдусның башына килгән
Мичкәләрдән карарга.

Ширпылар сызып карагач,
Җизнәкәе күренгән.
Абыем-җизнәм монда, диеп,
Ишекләргә йөгергән.

Илдус әйткәч, балакаем,
Мичкәләргә үрләгән.
Мичкә эчләрендә күргәч,
Күңелләре сүрелгән.

[1] Тирес.

(Шунда төшәләр, шунда төшеп рәтлиләр, ремонтлыйлар эчтә клапан, нәрсәдер мичкәнең, шуны ремонтларга төшкән, шунда ул аммиакка исергән, үзе генә булган, кеше булырга тиеш иде анда, хуҗаларның гаебе булган).

Арканнар белән бәйләп
Мичкәдән чыгарганнар.
Бу нинди хәлләр диеп,
Әдәмнәр караганнар.

Улым әйтә: ничек кенә
Кайтып әйтим әнекәемә.
Дөнья яктылыгы бетте
Газиз әтекәемә.

Алып кайтып өйгә куйгач,
Җаннарына иелдем.
Аның тыннары чыкмагач,
Күңелләрем сүрелде.

Алларың булалмадым,
Гөлләрең булалмадым.
Мичкәләрдә ян биргәндә
Ярдәмче булалмадым.

Маңгай битләреннән үптем,
Риза-бәхил бул диеп.
Изге догаларым кылдым,
Изге җаннан бул, диеп.

Сабырлыклар бир, Ходаем,
Минем йөрәкләремә.
Догаларым пәрдә булсын
Ахирәт көннәренә.

Балаларым белән бергә
Гел дә аны яраттык.
Койрыклар булганда
Кайгыларны бергә тараттык.

Кеше балалары килгәч,
Төрле сүзләр булды инде.
Дөньялары шулай булгач,
Аларны да кичер инде.

Оныкларны бик яраттың,
Изге күңелең белән,
Ходай сине ярлыкасың
Бакый иманың белән.

Туганнарның һәрвакытта
Хәлләрен белеп тордың,
Бервакыт каршы килмичә,
Сине озатып тордым.

Барыбыз да сиңа риза,
Бәхил булып калабыз.
Оҗмахларны насыйп итсен
Бер Ходаебыз – Аллабыз.

Үкенеч булды шунысы –
Эштән өйгә кайтмадың.
Җаннар биреп ятканда
Җылы урыныңда ятмадың.

Инде нишлик, Ходаем,
Кире кайтарып булмый,
Караңгы гүрең якты булсын,
Күңелләр шулай уйлый.

Тормышыбыз булды гөл кебек,
Гомеркәең булды төш кебек.
Ике арабыз булды шундый йомшак,
Татлы искән назлы җил кебек.
(Бик яхшы яшәдек, бик матур)

Исән кайтсын диеп озатып кала идем,
Исән кайттыңмы, диеп каршылап,
Бабакачым-әбекәчем дип гөрләшә идек,
Арыган вакытларда сайрашып.

Язмышлардан инде узмышлар юк,
Шулай булгандыр шул гомерең,
Әти-әни, мин, балалар фатихасын бирде,
Тыныч булсын синең күңелең.

Каткан кулларыңны турайтырга,
Грелкалар куеп җылыттым,
Җансыз гәүдәң, йөзләреңә карап,
Ник болай булды икән, дип шаккаттым.

Ачылмады синең йомган күзләр,
Мәңгелеккә алар йомылган.
Мичкә эчләренә менгән чакта,
Үлем җиле сиңа кагылган.

Бер кат башкаема да килмәде,
Мичкә эчләрендә үләрең.
Тик уйлана идем һәрвакытта,
Атың (К700) калып, дөньядан китәрсең.

Сау бул инде, җаным, риза-бәхилләр бул,
Аз түкмәдең җирдә тозлы тир,
Әхирәткә оҗмах ишекләрен
Үз кулларың белән ачып кер.

Исән чакта Әбҗәт догаларын
Бик аз гына укымадың син.
Машинага һәм дә К-700 ка
Бисмилласыз утырмадың син.
Шуның өчен соңгы юлга киткәч,
Мин дә тыныч, син дә тыныч бул.

Җансыз гәүдәң өйгә алып кергәч,
Сөлгеләр дә яба алмадым.
Тик шулай да, изге дога укып,
Ак пәрдәләр сиңа капладым.

Колхоз эше, дөнья малы дия-дия,
Газраил тия яннарга.
Исәнлекләр, тигезлекләр бирсен,
Бездән калган балакайларга.

Уфалардан кайткач, машинагызны
Гаражларга кертеп куегыз.
Дөньялыкта кабат күрешү юк,
Каберләрем якын куегыз.

Алларың булалмадым,
Гөлләрең булалмадым.
Төннәр буе җир сөргәндә,
Яныңда булалмадым.

Ниләр булды икән, ниләр генә булды,
Синең әрнү йөрәккәеңә?
Нигә ярдәм итәлмәдем икән
Синең сынган беләккәеңә?
(Элек аның аркасы – беләге сынган иде).

Тәрәзәләрдән иртән карап калам,
Абыемның үтеп киткәнен.
Әле дә бәлки кайтып керерсең дип,
Сине өзелеп көтә йөрәгем.

Төймә тишекләре бик күп, бик күп,
Төймә тишекләре бигерәк күп.
Бер гүрләргә киткәч кайтып булмый,
Аның инде ишекләре юк.

Агыйделдән килгән ак пароход,
Томаннарга кереп юл алды.
Исемең телләремдә тибрәнсә дә,
Гәүдәң күз алдымнан югалды.

Алмагачым чәчәк ата,
Майның унбишләрендә.
Мәңге сүнмәс булып калдың,
Минем күңелләремдә.

Гомерләр ике килми шул,
Дөнья тик фани гына.
Аның асылын аңламый
Бары тик сабый гына.

Белдең кадерем, белдем кадерең,
Матур үтте көннәрем.
Кадерләребез белергә
Ярдәм итте диннәрем.

Я, Ходаем, үзең кичер мине,
Шундый моңнар инде язаем.
Сабыр итәм, ләкин өзелеп көтәм,
Күңел бит ул, нишли алаем.

Соңгы сәгать, минут, секундлары ян тәслим итүе үзе белән бер Ходайга гына мәгълүмдер. Күпме генә башлар ватсак та белә алмыйбыз, кире кайтара алмыйбыз, Ходаем аны изге яннарыңнан кыйл, рәхмәт фәрештәләрең кабул итсен. Ярдәмче бул, иман белә ярлыкагыл. Укыган-укыткан Коръән-догаларыбызның савабын аңа насыйп ит. Оҗмах белә ярлыка. Дөньяда булган гаеп-гөнаһларын үзең кичер, әхирәт көннәрдә оҗмахларда күрешүне насыйп ит. Балаларга, миңа, туганнарга исәнлек-сабырлык, ярдәмнәреңне үзең бир. Амин.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдершина Раушан Бари кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

### *Рәсүлулла бәете*

Рәсүлулла ятим үзе,
Ятимнәрдә – ике күзе.
Әгәр күрсә ятимнәрне,
Башын сыйпар иде үзе.

Рәсүлулла ятим булган,
Ятимнәрнең кадерен белгән.
Аларның башларын сыйпап,
Аларның хәлләрен сораган.

Васият кылдый ул безгә,
Ятимнәрне күрсәгез сез дә,
Бәним тик хәлләрен сорап,
Башларын сыйпагыз сез дә.

Ятимнәрнең башын сыйпап,
Сәдака бирсә бер кемсә,
Кыямәт көнне Алланың,
Дидарын күрер ул кемсә.

Гәет көнне Рәсүлулла
Урамнарга чыгып йөрде.
Агач төбендә утырган
Ятим баланы ул күрде.

Агач төбендә утырган
Бу ятимнең хәлен сорады.
Атам да юк, анам да юк,
Диеп ятим җавап бирде.

Рәсүлулла әйтеп аңа
Атаң булаем, бән сиңа.
Ни сүзең бар, сөйлә миңа,
Күзләремнән яшьләр ага.

Шулай дигәч ятим әйтте:
Бәнем тик балалар монда.
Менеп йөриләр дөл-дөлгә,
Шатланып йөриләр анда.

Рәсүлулла дәюп сиңа,
Дөл-дөл булаем бән сиңа.
Ни сүзең бар, сөйлә миңа,
Күзләремнән яшьләр ага.

Шулай итеп, ятим бала
Рәсүл аркасына менде.
Рәсүлулла дөя булып
Анда-монда йөгереп йөрде.

Дөя кебек тамагыңны
Дәеп айга сәлә аф-аф.
Аны күреп сәхабалар
Җыелдылар алар саф-саф.

Рәсүлулла, барыгыз сез,
Ясак алып килегез сез.
Ятим баланы кулымдан
Бәндән сатып алыгыз сез.

### ***Үлем бәете***

Рәсүлулланың чыкмыйк юлыннан,
Кәүсәр шәрәбен эчәрбез кулыннан.
Рәсүлулланың сөннәтен тотаек,
Сөннәтен тотып өммәт булаек.

Үтенәм сездән дога кылуның,
Җәннәт эчендә бергә булуны.
Иманлы кеше бирер җавабын,
Дәфтәрләренә язар савабын.

Газраил килер, җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.
Якын дусларым юа башларлар,
Киемнәремне алып ташларлар.

Зифа буемнан үлчәү алыгыз,
Юып паклагач кәфен салыгыз.
Әлхәм белән башлыйм сүзләрем,
Ядкяр булсын йомсам күзләрем.

Әлхәм соңында янәбе Аллага
Салават әйтик Рәсүлуллага.
Сезгә, дусларым, актык сүзләрем,
Догадин куймагыз, йомсам күзләрем.

Әҗәл шәрәбем бер көн эчәрмен,
Якты дөньядан бер көн китәрмен.
Фани дөньядан югалыр исемем,
Яхшылык белән искә төшермен.

Күңелем үсмәде, кулым бармады,
Хәсрәтле уйлар миннән китмәде.

*Сарыкташ районы Кылчым авылында*
*Аргенбаева Тәскирә Миңгали кызыннан (1955 елгы)*
*язып алынды*

**Мөнәҗәтләр**

И, Ходаем, мин телимен дүрт нәрсә
Берсе – иман, берсе – җәннәт,
Берсе – нигъмәт, берсе – нур.
И, дусларым, телим сезгә
Бергә-бергә булуларны.
Бәдән-җәннәт эчләрендә
Бергә-бергә булуларны.
Йөземнең аллары бетте,
Күземнең нурлары бетте.
Иман белән җаныбызны алсаң,
Безгә шул дәүләтең җитте.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Мангутова Луиза Әүхәди кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Инандым мин Алланың берлегенә,
Бердер Аллаһым бәнем.

Барлыгы үзеннәндер,
Һичкемсәдән түгелдер.
Үзлегендин булган ул,
Бердер Аллаһым бәнем.

Аллаһының барлыгына
Әҗәл, ахыр юк аңа,
Бетмәс дәхи...
Бердер Аллаһым бәнем.

Бар нәрсәне белгән ул,
Күп нәрсәне күргән ул.
Тавышын ишеткән ул,
Бердер Аллаһым бәнем.

Син һәр эшне теләгән,
Һәр теләгәне булган,
Теләмәсә булмаган,
Бердер Аллаһым бәнем.

Аллаһы ул теректер,
Аңа үлмәк һич юктыр,
Кешенең шиге юктыр,
Бердер Аллаһым бәнем.

Юктыр тиңдәшең сәнең,
Бердер Аллаһым бәнем.

* * *

Лә иләһе иллә Аллаһу,
Күп әйтегез фәләкләр.
Лә иләһе иллә Алласыз,
Кабул булмас теләкләр.

Лә иләһе иллә Аллаһу,
Таулар-ташлар басалмас.
Лә иләһе иллә Аллаһны
Ерләр-күкләр кысалмас.

Лә иләһе иллә Аллаһу,
Гәрше кеше баскычы.
Лә иләһе иллә Аллаһу –
Сигез оҗмах баскычы.

Лә иләһе иллә Аллаһның
Карамагыз азына.
Лә иләһе иллә Аллаһу –
Мәңге бетмәс хазина.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдершина Раушан Бари кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Лә иләһе, иллә Аллаһы
Мөхәммәдеррәсүлулаһы.
Хозур Ильяс.
И, Ходаем, бер Ходаем,
Теләгәнем дүрт теләк.
Берсе – иман, берсе – җәннәт,
Берсе – нигъмәт, берсе – нур.

И Ходаем, бер Ходаем,
Дидарыңны күрсәм иде.
Ходайның рәхмәте белән,
Оҗмахка керсәм иде.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Кәбирова Зәрә Заһретдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

Инәй элеккеләрне әйтә торган иде. Инәйнең инәсе бик укымышлы кеше булган. Ул шуннан откан, мин инәйдән оттым, булган хәтлесен инде.

Бисмиллаһи рахмани рахим.
Әлки-әлки әлләли,
Әлхәм белмәс әлләзи.
Ата хакын белмәдең,
Күрше күңелен күрмәдең.
Тәндә яның су булдый,
Тәнең калдый курылып.
Яның чыктый суырылып,
Ак кәфенгә төрделәр,
Илтеп гүргә куйдылар.
Кырык адым җир киткәч,
Килеп җавап алдылар.
Җире каты, кабре тар,
Каты газаплары бар.
Утлы чукмарлары бар,
Гамәлеңне алып бар.
Тезең куйсаң – тезең ут,
Йөзең куйсаң – йөзең ут.
Эшең-тышың бар да ют,
Шунда намаз кыйлгайлар,
Намаз вакыт – 5 вакыт.
Куя күрмә бер вакыт,
Әгәр үлеп китәр булсаң,
Мөэмин уйларым бер сәгать.

И, мөэминнәр, торыгыз,
Мәчет-сарай йөрегез.
Мәчет-сарай йөргәннәр
Оча, калка баралар.
Таму(г) сарай йөргәннәр,
Аяк басар белмәссең.
Лә иләһе иллә Аллаһ,
Мөхәммәдеррәсүлуллаһ.
Байның күзе малдан туймый,
Ачның күзе аштан туймый.
Минем күзем яшьтән туймый,
Биш барулдый бәнем хәлем,
Асларыңнан утлар чәчәр.
Өсләреңнән туфрак басар,
Яланчаяк микән тәтәр,
Ятим-ятим димәгез,
Ятим хак(ы)на тимәгез,
Ятим хакы зур булыр,
Ахирәттә хур булыр.
Лә иләһе иллә Аллаһ,
Мөхәммәдеррәсүлуллаһ.

* * *

Янам инде, көям инде,
Гасыйлардан булам инде.
Сабырсызлык кылам инде,
Сиңа сыгынам, Рәсүл Аллам.

Бу дөньялар үтәр – китәр,
Әхирәтлек килеп җитәр.
Әхер бер көн алып китәр,
Сиңа сыгынам, Рәсүл Аллам.

Бу дөньяның вафасы юк,
Кемебез ач, кемебез тук.
Арабыздан догачы юк,
Сиңа сыгынам, Рәсүл Аллам.

Мөнәҗәтем яза-яза
Каләм тоткан кулым тала.
Күземнән яшьләрем ага –
Синә сыгынам, Рәсүл Аллам.

Мөнәҗәтем сезгә булсын,
Дус-ишем дога кылсын.
Догалары кабул булсын –
Синә сыгынам, Рәсүл Аллам.

Хәсбун Аллаһу вә нигъмәл вәкил,
Нигъмәл мәүлә вә нигъмән нәсыйр.
Гуфранәкә раббнә вә
Иләйкәл мәсыйр.

Ходаем бирде миңа дәүләт,
Мәкәмем әйләди карбәт.
Иманнурый лә гөлҗәннәт,
Көюл кадыйр мәңә рәхмәт.

* * *

Әгүзе билләһи минә шайтани раҗим
Бисмилләһи рахмани рахим.
Әҗәл ширбәтен бер көн эчәрмен
Якты дөньядан бер көн күчәрмен
Әҗәлем җитәр – тыннарым бетәр.
Ясин укырга вакытлар җитәр,
Укый алмамын, бетәр сулышым.
Артымнан калсын дога кылучым.
Газраил килер – җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.
Якты дөньяны ташлап китәрмен,
Караңгы гүрдә нихәл итәрмен.
Караңгы гүрдә калыр бу башым,
Ак фәрештәләр булсын юлдашым.
Кыен хәл икән гүргә керүе,
Авыр хәл икән җанны бирүе.

Зифа буемны үлчәп алырлар,
Караңгы гүргә илтеп салырлар.
Газиз тәнемне каты тотмагыз,
Кире кайталмам, ашыктырмагыз.
Ерак җирдән дуслар килгәннәр,
Карап калсыннар якын күргәннәр.
Йорттан чыкканда ашыгып чыкмагыз,
Елашмагыз, зинһар чыдагыз.
Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфрактан безгә ястыклар.
Бу ят җиргә кемнәр китергән,
Безгә йортларны кемнәр җиткергән.
Иптәш калмаган түшәк җәймәгән,
Кәфен сырылган акбүз җәймәдән.
Каберләремне киңрәк казыгыз,
Ак таш утыртып исмем языгыз.
Каберем өстенә чардак корыгыз,
Агач утыртып нурландырыгыз.
Яфраклар ярсын, кошлар сайрасын,
Рухым шат булсын, догалар барсын.

### *Раббым Аллам, шөкер кылам*

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Исәнлек биргәнеңә.
Аякларым йөргәненә,
Күзләрем күргәненә.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Нигъмәтләр биргәнеңә.
Күктән яңгырлар яудырып,
Иген үстергәнеңә.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Якты көн биргәнеңә.
Аятьләрне укыр өчен
Зиһеннәр биргәнеңә.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Ак карлы кышларыңа.
Җәйнең матур таңнарында
Сайраган кошларыңа.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Ураза биргәнеңә.
Бәндәләрнең гөнаһларын
Ярлыкыйм, дигәнеңә.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Караңгы төннәреңә.
Намазларны укыр өчен
Ярдәмең биргәнеңә.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Иманга кайтканыма.
Намаз укып, Коръән укып
Тынычлык тапканыма.

Раббым Аллам, шөкер кылам,
Сабырлык биргәнеңә.
Сабырлыкның савапларын
Бирермен дигәнеңә.

* * *

Сабыр итим, сабыр итим,
Сабыр итми нихәл итим.
Сабырлыкның морадына
Ничек кенә барып җитим.

Мөнәҗәтләр әйтик әле,
Өйнең эче нур белә(н) тулсын.
Бу мәҗлесне ясаучыга
Сигез оҗмах насыйп булсын.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Саягфарова Сәбилә Гайсә кызыннан (1943 елгы)*
*язып алынды*

Ике аккош, бер тутый кош
Оча кыйбла хутына.
Раббым Аллам, Кадир Мәүләм,
Салдың дөнья утына.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Фәтхуллина Миңлегөл Гали кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Нәнәй өйрәткән догаларым калган. Без 9 бала. Авыр торырга. Нәнәйләрдә тордым. Мине алды ул. Әйбер пешерә нәнәй, үзе мөнәҗәт әйтә:

Әр сәхәр вакытында бар иди эши,
Арпадин эрди, күзен агызды.
Гарәп чүлләрендә айзыл карани,
Гасасы бар иде аның билендә.
Камәре бар иде аның кулында.
Алланың сикрите аның телендә,
Гарәп чүлләрендә сән-сән солтани.

* * *

Лә иләһе иллә Аллага,
Күп әйтегез фәләкләр.
Лә иләһе иллә Алласыз
Кабул булмас теләкләр.

Лә иләһе иллә Алланың
Карамагыз азына.
Лә иләһе иллә Аллаһы
Мәңге бетмәс хазина.

Лә иләһе иллә Аллаһы
Гарше кеше пар кеше.
Лә иләһе иллә Аллаһы
Сигез оҗмах ачкычы.

*Александр районы Султакай авылында*
*Фәтхуллина Венера Әхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Кеше өчен иң әвәле намус дигән,
Намусыңны сатып итмә, табыш дигән.
Байлык өчен илен-көнен саткан кеше –
Ике дөнья өчен дә ул явыз дигән.

Икенче кыйммәтлесе гакыл дигән,
Акылсыз да тәүфикъ ягы такыр дигән.
Акылсыз да намуссыз да иман да юк,
Ялганга ант итеп барып сатыр дигән.

Өченче кыйммәтлесе әдәп дигән,
Әдәп көчле мәхәббәткә сәбәп дигән.
Әдәпсез дә бәхет тә юк, тәүфикъ та юк,
Кеше исеме үзгәрүе гаҗәп дигән.

Дүртенче кыйммәтлесе күңел дигән,
Күңеле бозык кеше кеше түгел дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә җирдә, үлеп күмел дигән.

Бишенче кыйммәтлесе сабыр дигән,
Сабыр кеше зур бәхетләр табыр дигән.
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу –
Бер кайгыдан икенчегә салыр дигән.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Әлфия Альберт кызыннан (1969 елгы)*
*язып алынды*

Лә иләһе иллә Алланы
Сез әйтегез һәрзаман.
Лә иләһе иллә Алладан
Аерылган кол бик яман.

Лә иләһе иллә Алланы
Күп әйтиек халыклар.
Лә иләһе иллә Аллаһы
Барча афәтләрдән саклар.

Лә иләһе иллә Аллаһы
Яннарга рәхәт бирә.
Лә иләһе иллә Аллаһы –
Барча эшне уң кыла.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Монасыйпова Фирдәвес Абделгазиз кызыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

Лә иләһе иллә Алла,
Яңартыгыз иманны.
Лә иләһе иллә Аллаһу –
Куар сездән шайтанны.

Лә иләһе иллә Аллаһу –
Тәһлил җәүһәреннәндер.
Лә иләһе иллә Аллаһу –
Иман кәлимәседер.

Лә иләһе иллә Аллаһу,
Иман бирсен бәндәгә.
Лә иләһе иллә Аллаһу,
Сират күперен кичәргә.

Лә иләһе иллә Аллаһу –
Һич бетмәс хәзинәдән.
Лә иләһе иллә Аллаһу –
Җимешен бирер Аллаһ.

Лә иләһе иллә Аллаһ,
Кайгысы килгәндә дә.
Онытмагыз Аллаһыны
Шатлыгын биргәндә дә.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Назыйрова Мәдинә Габделхак кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Газиз Аллам, Кадир Аллам,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булса булыр,
Атаң-анаң разый булса.

Газиз Аллам, Кадир Аллам,
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булса булыр,
Күршеләрең разый булса.

*Сакмар районы Үрге Чебенле авылында*
*Кунафина Мәгъдәлинә Гайзулла кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Уеннар, аулак өйләр**

Кич утырганда **«Зилем»** уйный идек. Кул эше эшләп утырабыз да. Егетләр килә, гармунчылар килә, «Зилем» көе – бию көйләре уйныйлар да, берәү төшә дә уртага икенче кешене ала, аннан ансы өченчене ала. Төрле ерлар анда:

Алларым диям сезне,
Гөлләрем диям сезне.
Ал гөлләрдән, былбыллардан
Артык күрәм мин сезне.

Аннан **«исем кушышлый»** уены. Утырасың да, рәттән тезелеп, колагына бер сүз атясең дә, дөрес ишетмәсә наказ бирәсең.

«Йөзек салышлый», «Саңгырау телефон» уйный идек.

**«Саңгырау телефон».** Тезеләбез дә мин монарга бер сүз атям. Бу ничек ишетте – икенче кешегә атя. Шуннан, круглап чыккач, беренче кешедән, соңгыданмы сорап, дөрес атся – бер нишләми, хатя атся – эшли.

«Дуадак», «Тамчы там» уйный идек.

**«Дуадак»** – ике рәт тезелә кешеләр. Берсе алга баса, сугалар – йөгереп тоталар. Бу артка баса, теге икенче кешегә баса.

«Ярма ярулы», «Үрдәккәем, чумасың» уйный идек.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдершина Раушан Бари кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Аулак өйләрдә (безнең заманда бит уенчыклар юк) кызлар-егетләр тезелеп утырабыз да, кулдан-кулга «тычкан салышлый» (күмер алабыз да күмер белән) уйный идек. Шуннан, кемдә күмер? – дип сорыйсың. Белмибез бит инде, әллә кемдә. Шуннан ул кеше уртага чыга бит ине. Аны чыгарабыз – тагын шулай уйнап китәбез.

**«Наза»**лы уйный идек. Тотына иек тә, астан бит ине кызлар-егетләр йөри ерлап:

Наза, Наза,
Наза кара пальтолы.
Кеше йәре кешеләргә
Буламени әйт әле, –

дия идек.

Аннан:

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән.
Наза дигән кыз бала
Һич тә чыкмый күңелдән, –

дип тә.

**«Туплы»** уйный иек, качышлы. Аннан качаек та, бер кеше эзләп таба ие. Таяк белә өй мөешенә сугасың: тук-тук, дип. Тук-тук беткәч качабыз, хәзер бер кеше эзли, таба.

Аннан **«Черта»**лы уйный идек. Черта сызаек та урамга шакмаклап мел белә ясыйек та, шунда пыяла ыргытабыз, читкә төшмәсә үзең уйныйсың да уйныйсың. Ыргытасың инде шул пыяланы да шул шакмак эченә, шуннан читкә төшсә ул кешене чыгарабыз да, икенче кеше уйный башлый. Шакмак берничә сызык ине – 5–6.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Кәбирова Зәрә Зәһретдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

Аннан соң бит инде шакмак-шакмак ясар иек та, акбур белә сызарыек та шакмак ясап. 8 була торган ие: 4 кә 4 ике ягыннан. Аннан эченә, шакмакның эченә, бер нәрсә ыргытасың да, шуны сызыкка тимәсен өчен аягың белә эшереп кертәсең.

Безнең заманда бичәкәй[1] дә юк иде. Шырпыны мулина белә урар идек тә, шуңа күлмәк тегеп, шуны бичәкәй итеп уйнар идек. Шырпы кабы белә кирпеч сугам дип. Гел шундый ие.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Саягфәрова Сәбилә Гайсә кызыннан (1943 елгы)*
*язып алынды*

Икешәр-өчәр күкәй алабыз, шуннан тары ярмасы, шуннан он, май, шулай алабыз да кемдә бер апай кешене белешәбез дә, теге апай кеше безгә иртәгә – карга боткасы дигән көнне, безгә иртәнчек коймакларын пешерә, әйберләрен әзерли: тары боткаларын ясый – боткалар ашыйбыз. Кызлар җинаулашып, булган яңа киемнәрне киеп күпергә китә торганыек. Күпергә барабыз да, анда уйныйбыз, көләбез, тыкрыкка чыга торганыек, «тәкәләр» уйный торганыек, уеннар шундый иде, «кристанцылар» итә торганыек. Шуннан соң кайтабыз да, теге өйгә җыйналабыз да хәзер кичкелеккә пилмән, шуннан соң пилмәнгә үзебезнең классташлар, күз күргән егетләребез килә торганыек инде. Шуннан алар гармуннар белә киләләр инде, уйныйбыз инде шунда күпме мөмкинчелегебез бар. Хуҗа безгә сүз әйтми, без уйныйбыз. Шуннан арып-талып өйләргә таралыша торганыек. Гармонис(т) булмаса, гармонис(т)ны эләктерү өчен өенә бара торганыек. Шуннан тегеңә әйтә торганыек:

И, дүдәме, дүдәме,
Гармунчыгыз өйдәме.
Өйдә булса, килсен әле,
Биетеп китсен әле.

Үпкәлибез-үпкәлибез,
Үпкәлибез, килмәсә.
Килмәсен дә, йөрмәсен дә,
Бию көен белмәсә.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Фәтхуллина Миңлегөл Гали кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

[1] Бичәкәй – курчак.

Әтиләр-әниләр каядыр китсә шул җыела идек. Егетләр килә иде шунда. «Йөзек салышлый», **«Күгәрчен ашату»** диләр иде инде – сөйгән яры белән кемгә чыга анда, йөзек салган вакытта, ул сөйгән ярын мунчага алып төнне китә иде. Шул күгәрчен туйдыру.

**«Качыш».** Берәү саналмышлар нитеп тора. Аннан 10 га кадәр саныйлар. Эзләргә чыгам, дисең инде. Тегеләр качалар инде. Урынны билгелиләр инде. Килеп тукылдый шунда тапкан кеше.

**«Ак тирәк, күк тирәк».**

Теге як әйтә: Ак тирәк.

Бу як: Күк тирәк.

Тегеләр: Бездән сезгә кем кирәк?

Бу як: Сездән безгә кара кашлы, кара күзле Галия матур кыз кирәк!

Тотынганбыз. Тегеләрдән берәү килеп өзеп чыгарга тиеш. Өзәлсә, значит ул алып китә үз ягына, өзәлмәсә, шунда кала.

**«Кем суктылый».** Халык тезелгән. Берәү килә дә суга, барсы да во-во! дип басып торалар. Теге әйтергә тиеш. Белсә кем сукканын, кем суккан баса.

*Александр районы Султакай авылында*
*Агишева Галия Мөхәммәтҗан кызыннан (1945 елгы)*
*язып алынды*

Кич утыруга (аулак өйне шулай атаганнар) йөрдек. Абыйлар йөри, без әле бәләкәй. Безнең өй буш булгач, без пич башында, абыйлар менә шулай тезелешеп утыралар да, шуннан соң ни – йөзек салалар. Сала-сала, шуннан: кемгә чыккан икән? Ул чыга. Әһә, теге кешене наказать итәбез – нишләтәбез?

Күгәрчен туйдырырга!

Кызга чыкса: егет белә кыз чыга. Кыз күгәрчен туйдырып кайта янәсе.

Без пич башында утырабыз. Пич башы туп-тулы пайлак – корт.

*Александр районы Султакай авылында*
*Фәтхуллина Венера Әхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

**Кич утыру.** Укыган вакытта бу. Әтиләр җибәрми бит. Бер подружкама барабыз дип чыгып китәбез дә, кич утырырга керәбез. Үзебезнең егетләрне алып кердек, арттан йөрүчеләрне кертмәдек, хәзер шакыйлар-шакыйлар. Без тәрәзәләрне кордык инде чүпрәк белән, үзебезчә уйныйбыз инде. Анда «Зилем», «Тамчы» – шундыйларны уйныйбыз.

**«Тамчы».** Ике кеше басасың да, куллар белән чәбәкләшеп җырлап торасың:

Там, там, тамчы, там,
Тамуыңны яратам.
Тамчы тамган вакытларда
Уйланырга яратам.

Хәзер менә моннан берәү килә дә, чыга тегеннән. Хәзер кемнедер ала: егетнеме, кызнымы.

Хәзер кыз егетне ала да, икесе тора:

Алы сиңа, гөле миңа,
Яфырагын бүләрбез.
Төрлебез төрле илләрдә
Саргаешып үләрбез.

Анда нинди җыр җырласаң да бата.

Аннан **«Зилем»** уйныйбыз:

Зилем-зилем, Зөбәйдә,
Аллар үсә, гөлләр үсә,
Идел буе тугайда.

Биешә-биешә җырлыйбыз:

Ай янында якты йолдыз
Минем йолдызым гына.
Таң алдында ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

Хәзер теге кертмәгән малайлар директорны алып килделәр. Ә без эчтә. Хәзер нишләргә. Ядкәр абый – директор, «ач та, ач» – ди Фәриткә. Теге бичаракаем азбарда тишеге булган, шуннан безне чыгарып, кайтарып җибәрде. Ишекне ачты. Теге

малайлар бит инде белә. Икенче көнне вич тезеп кәнсәләриягә кертте безне. Әтиләрне чакырта. Зинһар әтине генә чакыртма, Ядкәр абый, дибез. Яфалама, Ядкәр абый әтине.

**«Палачлый».** Менә, например, бүреккә язулар саласың да, шуннан аласың. Менә аның кызы миңа чыкты. Хәзер ул сатып алырга тиеш. Ремень белән сугалар. Пример, унны сугарга, диләр. Сугалар, түзә, түзмәсә – кыз теге егеттә кала, ә түзсә – теге аңарга була.

Егет белән кызны «Гөрләтү» бар иде.

*Александр районы Тукай авылында*
*Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

**Кич утыру.** Без нык кич утырдык аулак өйләрдә. Башта инде егетләр килгәләгәнче эш эшләп утыра идек. Анда кем нәрсә илиме, оек бәйлиме, нәрсә булса да инде. Аннан инде егетләр киләләр дә.

– Ярар, етте сезгә, Зилем сугыйк.

«Зилем» әйтә идек элек. Биибез, җырлыйбыз, йөзек салышлы уйныйбыз. Шуларны без «Зилем сугабыз» дип әйтә торган идек.

Элек мәхәббәт ерлары юк иде ул, советский ерлар ерлый идек күбесе.

И, су агулары,
Суның болганулары.
Үзебез чәчкән кырлар буйлап
Күңелле барулары.

Самолеттан карап бардым
Безнең чәчкән кырларны.
Шул кырларда дан казанган
Егетләрне-кызларны.

Колхоз төзелгәннән соң «төзелгән» җыр:

Трактор дигән машина
Килде безнең кырларга.
Эшче белән крестиан
Элемтәсе булганга.

Трактор да килер әле,
Безнең авылларга да.
Безнең башлар өйрәнде инде
Нинди авырларга да.

Зилем сукканда уен ерлары, матуррак кызлар чыкса:

Сипарат әйләндерә,
Круг уртасына чыкса,
Кругны ямьләндерә, – дип.

Аннан «Йөзек салышлый» уйныйбыз. Бер кеше йөзек салып йөри. Аннан инде кемдә йөзек – биергә, йә ерларга – шундый наказ бирә торган идек.

Йә әйтә: мин шул кызны алам. Аңа атялар: суктыр кулыңа. Биш мәртәбәме, алты мәртәбәме. Аннан инде икенчесе суга. Сукканнан соң кызны үзенә ала. Егетләр түзә инде – нишләсен. А то кызны алалмый. Аннан алар утыралар икәү бергә кыз белән. Синнән ала да тегенең белән барып утыра.

«Мунча» дигән дә бар иде, «мунчага» чыгарга. Егет белән кыз икәү чыгып керәләр шунда – ишек алдына. Әз генә, минут кына, кызык өчен: «Мунча да кереп чыктылар».

Кич утыра идек тә, кайтып та китми идек, егетләрдән курка идек. Кемдә утырган кешедә куна торган идек. Егетләр китә иде өйләренә.

Дояркалар юып куя
Сипарат казаннарын.
Булса булсын грамотный,
Сөймибез наданнарын.

Элек шулай ерлый идек.

Каршы ерлар бар иде. Төртмә-төртмә ерлар дип атя идек:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәридә
Син дустымны ошатамын
Мунчадагы пәригә.

**«Тамчы там»** уйный идек:

Там, там, тамчы, там,
Тамуыңны яратам
Тамчы тамган вакытларда
Уйланырга яратам.

Иртән дә киләм диден,
Кичен дә киләм диден.
Одеколон, исле сабын
Алып килермен диден.

Ай иртә кил, иртә кил,
Тәрәзәңне чиртә кил.
Чиртүләреңнән танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Там, там, тамчы, там,
Тамуыңны яратам.
Өз эшләргә, күп йокларга,
Тәмне ашарга яратам.

Яртышар сәгать биергә була бу көйгә.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Рәмзә Газиз кызыннан (1925 елгы)*
*язып алынды*

Бала вакытта кар эреп бетәр-бетмәс борын **«Ашыклы»** уйный торганыек.

Сарыкта, кәҗәдә ул була сөяк. Атта була, ансы зур була. Ашыкларны (шарнирлы җирдәге сөяк) тезеп куясың да, шул сөякләрне сараймы, өйме, коймамы – тезеп куясың да, арасы 10 см чамасы була. Ун-унбиш адыммы – зурлыгына карап, тегене үзеңдә тагы бер «ашык» бар бит инде, шул ашык белән тегеңәргә еллисең. Әгәр дә теге ашыкка тигезсәң – ул минеке – кесәгә. Әле мин аның белән генә туктамыйм. Значит миңа дополнительно тагын бирелә, тагын алсам – тагын мин. Зурлар безне, нарош килеп ала торганнар ие. Шуннан тегеләр күлләвекләр була бит инде эрегән кар суыннан, шунда теге ашыкларны ташыйлар да – шуны кереп аласың ялангач аяк.

Кыш көне булса **«Чүрәкә»** биетү була торгание. Кыш көне ине Сакмар суына төшеп, бозны тазартып, бозны инде тазартасың зеркальный булсын дип. Шуннан чүрәкә дип атала инде, русча веретено була бит ине.

Значит монауң хәтлек кенә биеклектә була (якынча 5–10 см), юанныгы була агачның ние (башы) киселгән була, ул очлана (бер башы), уртада бау нитергә (бәйләргә) канава.

Шунда баудан ясалган чыбыркы була, шул тегене урап нитәсең дә тартып ебәрәсең, бозда теге әйләнә бит ине (баудан ясалган чыбыркыны бау бәйли торган урынга – канауга бәйлисең). Тартасың, тарткач сүтелү ягына китә, шуннан теге әйләнә бит ине. Шуннан теге туктарга тиеш, ә син туктатмаска, тагы чыбыркы белән сугасың (туктаганчы). Шундый осталык кирәк. Теге тагын да биергә башлый, урап тормыйча гына сугасың – чирттерәсең дип әйтелә. Ансы бертөрле була торган ие.

Шуннан, шул чүрәкәнең очына кадак кагасың (очланган очына), чтоб эшләпәсе калганчы, казак[1] кереп киткәнче и теге эшләпә күбрәк әйләнергә файда бирә. Шуннан икенче төрлесе була торган ие. «Атлы казак» дип атала торган ие. Ансы менә шундый чүрәкәнең тагын бу ягы да очлы була, ике ягы да очлана. Уртада тоже бау урыны. Ансы сугып ебәрсәләр, тоже шул ук чүрәкәдәге кебек. Бездән зуррак мастерлар инде тегеләр (олыраклар) чыбыркы белән еббәрә, теге вы-ың-ң-ң итеп тавыш белән очып барып, 5 метрлык тегендә килеп төшә дә, тегендә бии. Тегендә барып чыбыркы белән чиртәсең. Монсы кыш көне бит ине.

**«Чана»** шуышлы вакытта кая ине, самодельный теге ике тактаны ясаган бу башларын азрак түгәрәкләгән, өстенә куйган. Апак кар булып кайта идек бала вакытта бит ине. Сугыш вакыты булса да, ач булса да, бала кешесе белми бит ине.

Шуннан җәй көне **«Түк-түк»**ле уйный торган иек – качышлы. Түк-түк дип атала торган ие. Например 10 бала, ограничение юк, ике команда була да, теге командада бер кеше атаман була. Атаман дип атала. Шул син атаман, мин атаман – бирәләр бер таяк, астан берсе тотып ала, аннан икенчесе – очына кем беренче

[1] Казак – кадак.

чыга. Шуннан теге кем беренче чыга, шул башлап ебәрә уенны. Шуннан син үзеңнең командада, мин үземнең командада. Отылган кеше командасыннан бер баланы ала да атаман, битләрен каплата да, шуннан җиңгән команданың балалары вич төрле якка качалар ине. Шуннан беткәчтен – бетте, дип кычкыра ине атаман. Шуннан теге торып калган кеше (чутлап торган кеше) теге ташкамы, тактамы (билгеләнгән урын) – нәрсә була шуңа түк-түк дип кычкыра, вроде эзләргә киләм дип. Шуннан эзләп йөри. Әгәр дә ул табалмаса, арада теге җиңгәннең командасы бит качты, теге эзләп йөргән кешенең әгәр дә тапмыйча йөри икән, җиңгәннең бер бала барып тоже шул ук тактагамы сугып кычкыра: түк-түк, значит «мин җиңдем» дигәнне аңлата. Тегендә тагы штрафной, наказание була. Җиңелгән команданың балалары эзләүчедән башка, карап торалар уйнаганнарын.

**«Туп»**лы уйный торган иек. Аны бәлки, хәр дә уйный торганнардыр. Пример 5–6 кеше җыйналабыз да, монда врата дип атала – ике таш куелган. Монда бер сакчы. Бу сакчы булган кеше монавың хәтле таяк (хәр городки диләр бит ансын да уйнадык – «Мура» дип атала торган ие) белән теге тупны чөеп ебәрә дә туп очып бара, ә тегендә калган бала-чага тегендә әзер торалар. Тупны кем тота, значит ул җиңгән була ине.

Шуннан **«Ходули»** – озын ике таяк – шул таякка аркылы аяк басарлык кына такта куела. Ул 2 метр примерно биклектә, 3 метрлы да була даже. Басасың да ике таякка таянадыр идек тә – ходулида йөрибез. Анда борыннар канап беткән вакытлар да булды, кул сызырыла[1], егыласың бит ине, сразу ничек басып йөри аласың.

Шуннан ярар, бу уеннар бетте. Без әкренләп зураябыз. Сугыш башланды бит ине. Ашарга такы-токы бит ине. Сыер тоттык постоянно, шул сыер аркасында катыгын оета, нитә дигәндәй, шуннан бәрәңге шәп үсә иде – 20–30 капчыкка кадәр була торгание.

Шуннан аулак өйгә кызлар әзерләнәләр. Бәрәңге пешерәләр дә теге төеп ботка ясыйлар. Шуннан арыш оны табалсалар әгәр,

[1] Сызырыла – сыдырыла.

йә солы оны катыштырып шул яртыга-ярты камыр ясап, җәеп пешереп кыстыбый ясыйлар. Гармун була торган ие.

«Яратасыңмы-яратмыйсыңмы», «Йөзек салу» уеннары уйныйбыз.

**«Яратасыңмы-яратмыйсыңмы»** – бер алып баручы бар, кулында каеш. Шуны икегә букли дә, мин кулны сузып торам. Шуннан бу суга. Яндагы утырган кызга карап әйтә:

– Яратасыңмы аны?

– Яратам.

«Яратам» дигән саен суга. Монда (уч төбе) әчетә башлый. «Яратмыйм» димичә торып туктамый. Слабыйраклар әйтә:

– Юк, мин уйнамыйм, кирәкми, – дип.

Кул авырта башлый бит.

Яратмыйм булала. Ул бит ине аның яраткан кызы түгел. Просто туры килеп утырды теге, бер егет, бер кыз. Безнеңчә әйткәндә шулай итеп егетлеген күрсәтә кызлар алдында.

Шуннан соң **«Күгәрчен ашату»** уены. Шырпыны ала да, тегене сындыра урталайга, сындыра да шуннан авызга каба, очын чыгарып калдыра. Кыз шуны алырга тиеш, теге шырпыны. Килә дә тешнәп алырга тиеш. Мин шул вакытта аны үбәргә тырышырга тиеш.

Шуннан **«пучта куу»** бар ие. Анысында егет белән кыз тышка чыгасың да, урамда нишлисең – өйдәгеләр белми бит ине. Шуннан тегендә кергәчтен ну нишли – пучты кудыгызмы? дип сорыйлар иде халык. Әле кайчан килә пучтыгыз? (көлкеле итеп).

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Даутов Гыйрфан Гыйният улыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

## Җырлар

Бакчаларга гөлләр чәчәсең дә,
Шытып чыгуларын көтәсең.
Дустың әгәр еракларга китсә,
Кайтуларын сагынып көтәсең.

Бакчаларга гөлләр чәчәсең дә,
Чәчәк атуларын көтәсең.
Дустың исеме сиңа якын булса,
Йөрәк уртасында йөртәсең.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Сәфәрова Зөмәрә Бәсим кызыннан (1946 елгы)*
*язып алынды*

Килен белән кияүгә җырлыйлар:

Син дә булдың кодагый,
Мин дә булдым кодагый.
Ике күрше арасында
Андый хәлләр булгалый.

Кушымта:
Әйтмә дә генә инде,
Сөйләмә генә инде.
Бу яшьләргә замананың
Иң матур чагы килде.

Сез дә яхшы күршеләр,
Без дә яхшы күршеләр.
Ике күрше бергә килә,
Әвеш-тәвеш итсеннәр.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдршин Марат Рузит улыннан (1962 елгы),*
*Кадырмаева Гөлзада Павловнадан (50 яшь),*
*Алтынчурина Галимә Фаррах кызыннан (1964 елгы)*
*һәм Абдршина Гөлгенә Наил кызыннан (1963 елгы)*
*язып алынды*

Моны армиягә киткәндә дә җырлыйлар:

Һавалардан очып килә
Күгәрчен көтүләре.
Әле дә булса күз алдымда,
Кул биреп китүләре.

Исеңдәме, киткән чакта
Кулларыңны биргәнең.
Моңсу карап күзләремә
Көт, онытма, дигәнең.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдршин Марат Рузит улыннан (1962 елгы)*
*язып алынды*

Инеш буе – сары чәчкә,
Өзәсең дә аласың.
Сары чәчкәләрне өзеп,
Үзең ялгыз каласың.

Инеш буена төшмәсәң
Күрмәгән булыр идем.
Сары чәчкәләрне өзеп
Бирмәгән булыр идем.

И, дусларым, сезгә әйтәм,
Сары чәчкә өзмәгез.
Яраткан ярларыгызга
Сары чәчкә бирмәгез.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдршин Марат Рузит улыннан (1962 елгы),*
*Кадырмаева Гөлзада Павловнадан (50 яшь),*
*Алтынчурина Галимә Фаррах кызыннан (1964 елгы)*
*һәм Абдршина Гөлгенә Наил кызыннан (1963 елгы)*
*язып алынды*

Таулар биек, таулар биек,
Таулар биек менәргә.
Баскыч кирәк, баскыч кирәк
Шул тауларга менәргә.

Болындагы чәчкәләрне
Таптамам, дигән идем.
Туып үскән авылымны
Ташламам, дигән идем.

Болындагы чәчкәләрне
Таптарга туры килде.
Туып үскән авылымны
Ташларга туры килде.

* * *

Казаннар килгәндә без «Хуш киләсез»не тегеннән ерлап керә идек.

Чәчәкләр белән каршылый
Безне иркен урманнар.
Ерак юлны якын итеп
Хуш киләсез, туганнар.
Хуш киләсез,
хуш киләсез,
Хуш киләсез,
кунаклар.

Эшләр әйбәт бара безнең,
Якларыбыз мул яклар.
Күңелебез дә, түребез дә,
Ачык сезгә, туганнар.

Татар халкы иҗат иткән
Җырлап бетмәс җырлар бар.
Шул ерларны бергәләшеп
Ерлыйк, әйдә, туганнар.

* * *

Тәрәз ачып җимнәр сиптем,
Килде ике күгәрчен.
Күрдем дә ике күгәрчен,
Килде сезне күрәсем.

Эх, дуслар, әйдә бергә
Уйнап ерлашик әле.
Авылыбызның көй-моңнарын
Бергәләп җырлыйк әле.

* * *

Эх, дусларым, сезнең белән
Күтәрелде күңелләр.
Күтәренке күңел белән
Үтсен безнең гомерләр.

Уйсу җирдә дым була,
Дым бар җирдә су була.
Яшь чакларда уйна да көл,
Картайгачтын соң була.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Абдршин Марат Рузит улыннан (1962 елгы)*
*язып алынды*

Кич утырабыз инде. Үзебез кул эшләре эшлибез, шәл бәйлибез, йырлыйбыз:

Гармунчыгыз өйдәме,
Бию көен беләме.
Өйдә булса, килер иде,
Биетеп китер иде.

Ялындыра, ялындыра,
Ялындыра, килми ул,
Килер иде, уйнар иде,
Бию көен белми ул.

Ялынмыйбыз, ялынмыйбыз,
Ялынмыйбыз, килмәсә.
Килмәсен дә, йөрмәсен дә,
Бию көен белмәсә.

* * *

Ак эшләпәм бар минем,
Маңгаема тар минем.
Нигә миңа башка ярлар,
Сөйгән ярым бар минем.

Аклы ситса күлмәгеңнең
Җиң очында хаты бар.
Хатын укып караган идем,
Сөям, дигән сүзе бар.

Аклы ситса күлмәгемнең
Итәге тар, җиңе киң.
Ситсасын тапмадым,
Үземә пар яр бит син.

Әтинең хатта язган җыры:

Безнең госпиталь буенда
Сары төлке куалар.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Хуш булыгыз, туганнар.

*Шарлык районы Яңа Муса авылында*
*Әхмәтова Наилә Хәмзә кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Матур үтсен дисәң яшьлегеңне,
Дуслар булсын тирә яныңда.
Шулар арасыннан яшьлегеңнең
Бер юлдашы булсын тагын да.

Ул юлдаш та булсын, дус та булсын,
Күңлең төшкән чакта күтәрсен.
Сиңа төшкән шатлык-авырлыклар
Үзең белән бергә үткәрсен.

Менә шундый дуска ач сереңне,
Менә шундый дусны сөя бел.
Тормышыңны, гүзәл яшьлегеңне,
Менә шундый дуска гына бир.

Сезнең алсу йөзегездә
Һәрвакытта кояш, нур уйнасын,
Үпкәләү-көнләшү газаплары
Шат тормышның ямен җуймасын.

***Туй җыры.***

Алтын микән, көмеш микән,
Кесәсендә пәкесе.
Кара карлугач микән, сары сандугач микән,
Аны үстергән әнисе, –

дип ерлый идек.

* * *

Безнең авылның капкасы
Ачык торсын, япмагыз.
Безнең газиз балаларны,
Җәтим, диеп какмагыз, –

дип җырладылар әтиләр.

Без китәбез иртәгә
Шинель салып җилкәгә.
Без китмәс идек иртәгә,
Герман тия теңкәгә, –

шулай дип тә ерладылар.

* * *

Киттеләр дә югалдылар,
Кайтырлар микән шулар, –

дип ерлый иде инәй.

Шуннан җырлый иде:

Дустыкаем, син күрмәдең,
Басуның кибәннәрен.
Син кайтмасаң, мин күрмәсәм,
Артык бит үлгәннәрем.

* * *

Ак төтен яулык итеп болгап,
Авылым калды мине озатып ла,
Елгаларым-чишмәләрем калды,
Челтер-челтер көен уйнатып.

Болын тулы чәчәкләрем калды,
Сандугачым калды кагынып.
Камышларым калды башын иеп,
Туганнарым (балаларым) калды сагынып.

Юл читендә басып әнием калды,
Маңгаена куеп кулларын.
Хуш, исән бул, балам, рәхәт яшә,
Изге була күрсен, дип юлларың.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Кәбирова Зәрә Заһретдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

Карлыгандай кара, ай, күзләрең лә,
Бөрлегәндәй йөзләрең.
Шикәрләрдән тәмле, ай, балдан татлы,
Сөям, дигән сүзләрең.

Кашың кара, кашың кара,
Кашларың кара синең.
Кара кашыңа карасам,
Йөрәгем яна минем.

Алма бакчасының юлы
Тәрәзәләргә туры.
Әллә сезгә бирде микән
Бөтен дөньяның нурын.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Булатова Клара Заһретдин кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Төртмә җырлар күп иде алар. Җырлый торганыек. Кристанцылар уйнаган вакытта. Артель-артель кызлар була. Шул олыраклар инде, без кечерәкләр керсәк, безне бик өнәп бетми торганнар ие. Төртмә җырлый торганыек.

Бер аягың озынрак,
Икенчесе кыскарак.
Ике аягың тигез булса,
Басар идең остарак, –

дип биегән кешегә әйтә торганыек.

Күп ул җырлар, истә түгел.

Бие-бие, Гайфулла,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булганчы,
Карт алаша тай була, –

дип, биергә төшкәннәргә шулай әйтә торганыек.

*Шарлык районы Мостафа авылында*
*Фәтхуллина Миңлегөл Гали кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Аклы ситца күлмәк алып
Яшелләрдән яка салдырам.
Исеңә төшкәндә бер укырсың дип,
Шул җырларны язып калдырам.

Ак иделкәй буен, ай, кичкәндә,
Бер ерладым микән ишкәндә.
Бер егласаң, туган, бер ерларсың,
Үткән гомер исеңә төшкәндә.

Матурдан да матур чәчәкләрне
Матурлыклары өчен өзәм мин.
Әле тормышым авыр булса да,
Киләчәкләр өчен түзәм мин.

Уфадан Мәскәүгә хәтле,
Тимер юллар күп микән?
Авыруларга давалар бар,
Кайгыларга юк микән?

Караны киеп туйдык без,
Кисеннәр кимәгәннәр.
Без сөеп ташлаганнарны
Сөйсеннәр сөймәгәннәр.

Күгәрченнәр күккә менә
Гөрләшеп, сүз серләшеп.
Йокыларымнан уянам
Сезнең белән сөйләшеп.

Сандугачның баласын
Тотып торың, дуласын.
Дошманыбызны сөйләгәнче
Элек үзен уйласын.

Җырлар яздым, туган, сиңа гына,
Альбомыңда урын табарсың.
Яшь чакларың исеңә төшсә,
Сагынганда алып карарсың.

* * *

Язгы җилләр исә карлар катып
Салкын бирә кайнар күңелгә.
Иптәш, сиңа язам бу җырларны,
Булыр бәлки гомергә.

Карадан кара күлмәк тегеп,
Кызыллардан яка салдырам.
Яшь йөрәктән чыккан ерларымны
Истәлеккә язып калдырам.

Яланнарда матур чәчәк,
Өзмә дустым үсеп утырсын.
Сакла минем язган истәлекне,
Сагынганда алып укырсың.

Уфадан Мәскәүгә чаклы
Юл буйлары чәчәкме.
Суда балыклар ничаклы
Миндә хәсрәт шул чаклы.

Поезд таугa менә икән,
Төтене кала икән.
Туган илләрдән чыкканда
Йөрәкләр яна икән.

Иртән торгач, битем югач,
Барып карыйм көзгегә
Көзгеләрдә төсем күргәч,
Искә алам сезне дә.

Кепкаларың күтәр-күтәр,
Арасыннан җил үтәр.
Бу дөньялар үтәр-китәр,
Татулыкка ни җитәр.

Беләзекне сынмый диләр,
Кигәч кенә сынмасын.
Яшь йөрәкне янмый диләр,
Нигә инде янмасын.

Кулымдагы пирчаткамның
Китә инде күзләре.
Ышанма ялган сүзләргә,
Бар да дошман сүзләре.

Алмагачлар арасында
Шаулап үсәсең, илем.
Җаннарымнан артык күргән
Якын дустым син минем.

Һаваларда кошлар оча,
Кая баралар икән?
Дошманнар безне ишетеп
Утта яналар микән?

Яз көннәре җитә инде,
Карлар да китә инде.
Безнең бергә көннәребез
Үтеп тә китә инде.

Алмы матур үскәндә,
Гөлме матур үскәндә.
Сагынам туган илемне,
Әллә шунда үскәнгә.

Урманнарда кара елан,
Уралды беләгемә.
Синең кайгы штык булып
Кадалды йөрәгемә.

Карлыгачлар күккә менә
Иртән сәгать унбердә.
Бәгырькәем, гүзәлкәем,
Ник һич чыкмыйсың бер дә.

Базарлардан яулык алдым,
Ал белән яшелләрне.
Нинди сүзләрем булса да,
Мин синнән яшермәмен.

Кара урманның эчендә
Ике аю чылбырда.
Синең кебек булмас инде,
Сахрадагы былбыл да.

Минем чәчләрем сүтелми,
Ефәк белән үрсәм дә.
Сине күргән кебек булам,
Кызыл чәчәк күрсәм дә.

Ак куянның баласын
Җибәр кырга, уйнасын.
Дошман безне сөйләгәнче,
Элек үзен уйласын.

Мин бу ерлар язамын,
Бизәкле каләм белән.
Язуымны тәмам итәм
Ялкынлы сәлам белән.

* * *

Ерлар язам, дустым, сиңа гына,
Сагынганда алып ерларсың.
Шул ерларым сиңа барып җитсә,
Бер утырып мине уйларсың.

Онытмамын, дустым, онытмамын,
Тормыш диңгезенә батсам да.
Тормыш дулкыннары синнән аерып,
Чит илләргә илтеп атса да.

Аклы кофта киям диеп,
Зәңгәр кофталар кимә.
Матур ярлар сөям диеп,
Кеше калдыгын сөймә.

Автомобиль килеп туктый
Магазин алларына.
Мин баралмасам яныңа,
Син килерсең яныма.

Аклы кофта, кара юбка
Килешә кичә кигәннәргә.
Зифа буең әрәм була,
Запаска сөйгәннәргә.

Кара булсын, кара булсын,
Кара булсын кигәнең.
Ут эченнән тартып ала
Торган булсын сөйгәнең.

Түгәрәк шарлар ясадым
Быел яуган карлардан.
Тормыш аермасын икән,
Җаның сөйгән ярлардан.

Киләм, киләм, киләм, киләм,
Ак иделләрне буйлап.
Ак йөзем сары булды,
Син дускаемны уйлап.

Су сип, дустым, гөлләреңә,
Чәчәк атып утырсың.
Сагынып сиңа ерлар язам,
Сагынганда укырсың.

Сандугачлар басып сайрый
Өй түбәсе – тактага.
Син дустымны онытмамын
Җаным чыккан чакта да.

Сандугачлар җыелышып
Су буенда сайрыйлар.
Безнең дуслыкка көнләшеп,
Дошманнар теш кайрыйлар.

Кашларыңны, күзләреңне
Күрәсем килә минем.
Синең эчке серләреңне
Беләсем килә минем.

Аклы күлмәк кимә, дустым,
Аклы күлмәк керләнә.
Матурларны сөймә, дустым,
Матур тәкәбберләнә.

Мин синең белән таныштым,
Шаярып көлү белән.
Әлегә кадәр сөя килдем
Яшерен сөю белән.

Аклы ситца күлмәгемне
Тектереп киям инде.
Үз күңелемә ошаганың
Мәңгегә сөям инде.

Сөймиләр дошманнар,
Хәтерләр калдыралар.
Көнләшәләр, уфтаналар,
Эчләрен яндыралар.

Ак иделнең аръягында
Сарымсак түтәлләре.
Булырбыз икән мәңгегә,
Кирәкми бүтәннәре.

Кашың кара, кашың кара,
Бәләкәйдән карамы.
Минем яшь йөрәгем яна,
Синеке дә янамы.

Пияла ишек, җиз тупса,
Ник ачыла җил юкта.
Син бар чакта, сиңа каршы,
Кемгә каршы, син юкта.

* * *

Карлыгачкай олы, муены кара,
Канат очларыннан кан тама.
Аталардан калган һай яшь бала –
Күкрәк көче белән мал таба.

Кара ефәк яулыгымны
Бәйлимен, юмасам да.
Исләремнән чыгармыймын,
Янымда булмасаң да.

* * *

Биек таудан карап калдым
Кошның очып киткәнен.
Кош артыннан сәлам әйтәм,
Белмим барып җиткәнен.

Әйдә, дустым, барасыңмы,
Лавкага сибирский.
Синең кебек матур булып,
Бакчада гөлләр үсми.

***Көлке җырлар***

Мондый күмер күмер мени,
Яхшы каен күмере.
Кыз саклаган карчыкларның
Кыска булсын гомере.

Безнең артның капкасын
Кәҗә кереп ачмасын.
Авызыңны бик зур ачма,
Телең чыгып качмасын.

Сездә чәчәләрме торма,
Бездә чәчәләр торма.
Тимер тырма теше кебек
Миңа кадалып торма.

Безнең артта ак балчык –
Сикереп чыкма, атлап чык.
Син дә миннән артык түгел,
Син әзрәк мактанчык.

***Җыентык җырлар***

Сездә чәчәләрме кабак,
Бездә чәчәләр кабак.
Туган илдән чыгып киткәч
Кайтып булмыйдыр кабат.

Исә җилләр, исә җилләр,
Исә җилләр файдасыз.
Төнлә төшләремдә күрәм,
Көндез әллә кайда сез.

Алмачылар алма сата,
Алмасы ничә тиен.
Бер башыма ике кайгы,
Мин берсен нишләтием.

Алма чәчәк аткан чакта
Бакчаларга кергәлә.
Ак бәхетләр, рәхәт тормыш,
Телим, дустым, сезләргә.

Агач башларына мендем,
Яфракларын санарга.
Бу ерларны сезгә яздым,
Мәңгелеккә сакларга.

Алма бакчасында үзем,
Гөл бакчасында күзем.
Аерылган чакта онытма,
Сиңа актыккы сүзем.

Кызылмы күлмәккәем,
Зәңгәрме бизәккәе.
Бергә йөргән искә төшсә
Өзелә үзәккәем.

Стенада ике сәгать –
Күтәрегез герләрен.
Үлсәм дә сине алырмын,
Тар булмаса гүрләрем.

Безнең артта ике басма,
Басып су алганым юк.
Таң алдында бер кош сайрый,
Елмаеп көлгәнем юк.

Алтын алма авыр булмый,
Авыр була бакыры.
Нурлы йөзләреңне күрми
Саргаермын ахыры.

Ай белән кояш,
Болыт араларында.
Эх, бер сөйләшергә иде,
Минут араларында.

Агыйделнең аръягында
Казлар килә кагынып.
Кычкырып җырлап җибәрәм,
Сез дусларны сагынып.

Йөгереп чыктым урамга,
Әйтер сүзем булганга.
Әйтер идем сүземне,
Сирәк күрәм үзеңне.

Бигрәк матур үсә икән
Бакчадагы алмабыз.
Эх, иптәшкәй, хәзер инде,
Бергә була алмабыз.

Ап-ак кәгазь өсте чуарлана
Юллар сыза очсыз каләмем.
Еракларга китеп аерылгач,
Шушы булыр соңгы сәләмем.

***Җырлар***

Уфа, дисең дә карыйсың,
Уфа күренә мени.
Аерылышып тору белән
Күңел сүрелә мени.

Кайсы диңгезләргә коя икән
Чылтырап-чылтырап аккан агымсу?
Бергә чакта, дускай, берни түгел,
Аерылышкач була ямансу.

### ***Чит илләрдә***

Туган илләремдә йөрегәндә
Сандугачлар кебек шатландым.
Аерылышып киткәч чит илләргә
Кайгы дәрьясына ташландым.

Алды тәкъдир мине үз илемнән,
Илтеп салды бигрәк еракка.
Күзләремнән ага кан яшьләре,
Сагыну уты кайный йөрәктә.

Сап-сау башым минем авыру була
Туган илкәемне уйласам.
Янган йөрәгемә минем дару була
Туган илемне сагынып җырласам.

Чит илләрдә йөрим утлар йотып,
Ямь табалмый бер дә дөньядан.
Туган илкәемне күрсәт, диеп,
Теләк телим газиз Алладан.

Таң атканда торып теләк телим,
Сәлам сөйлим таңның җиленә.
Сәламемне җилләр илтәр димен
Туган үскән матур илемә.

Авыр тормыш мине адаштырды
Суын эчкән матур җирләрдән.
Туган илгә мине кавыштырсын
Алсын мине ямьсез илләрдән.

***Җырлар***

Сандугачның балалары
Сайрый-сайрый ялт итә.
Чит илләрдә шунсы кыен –
Бер күрергә зар итә.

Агыйделнең аръягында
Ай-һай дигән бер тавыш.
Миннән, дустым, сиңа теләк –
Сөйгәнең белән кавыш.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миңнегөл.
 Көннәреңдә мине сөйлә,
Төшләреңдә мине күр.

Көмеш чалгы алыгыз,
Су буйларын чабыгыз.
Кая безнең бергәләшеп
Уйнап йөргән чагыбыз.

Идел буе тугай микән,
Йөрергә уңай микән?
Аерылышу кыен икән,
Кемгә дә шулай микән?

Базарларга барсаң, дустым,
Ал күгәрчен читлеген.
Хат эченә язып җибәр
Хәлеңнең ничеклеген.

Сандугачлар очкан чакта
Канатын кузгаталмый.
Сезне сагынып елаганда,
Һич кем дә юаталмый.

Безнең артта түгәрәк күл,
Үрдәк йөзәрлек түгел.
Быел кошлар моңлы сайрый,
Бер дә түзәрлек түгел.

Яхшы шлея, яхшы камыт,
Яхшы атларда гына.
Иртән торсам ике күзем
Сезнең якларда гына.

Яхшы шлея, яхшы камыт,
Кайдан алдың бу атны.
Бик сагынып, бик саргаеп,
Сезгә яздым бу хатны.

Кара урман эчләренә
Төшә айның яктысы.
Сезне уйлап үтә инде
Гомеремнең яртысы.

Эх, дусларым, таныйсызмы,
Латинский хатларны.
Сагынганда бер сөйләрсез
Бергә йөргән чакларны.

Өстәлләрдә күп алма –
Барысын да башлама.
Яңа дуслар таптым диеп,
Искеләрен ташлама.

Бакчаларга кереп утырам,
Ал чәчәкләр кадыйм түшемә.
Еракларга китеп аерылгач та,
Син төшәсең минем исемә.

Башларыма кепка киеп,
Чәчләремне таратам.
Исемә алып хатлар язам,
Гадәтеңне яратам.

Күп иттереп җиләк җыйдым,
Бер учым да тулмады.
Ничә ел бергә укысак та,
Бер көн хәтле булмады.

### ***Төртмә җырлар***

Әйдә, дустым, урманнарга,
Кара бөрлегәннәргә.
Бу җырларны без җырлыйбыз
Ярын көннәгәннәргә.

Ана аннан берәү килә,
Аягына чүп кергән.
Аягына чүп кермәгән,
Төртмә җырлар төртелгән.

Каен башында каргалар
Сайраган була микән.
Үзен үзе әллә кемгә
Санаган була микән.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлбикташ.
Юкка гына тавышыңны
Күтәрмә әле, иптәш.

Ак пирчаткы, күк пирчаткы
Бәйләп тә бирәлмадым.
Хәзер теләсәң дә булмас,
Электән теләмәдем.

Җырлыйк, дуслар, җырлыйк, дуслар,
Янсын дошман йөрәге.
Янсын дошманнар йөрәге,
Шул кирәк бигерәге.

Зур тәрәзә төпләренә
Вазамны куйган идем.
Тик торганнан бер эш булсын
Дип кенә сөйгән идем.

*Александр районы Султакай авылы музеенда*
*Альбеков Рәшит Закир улы (1926 елгы)*
*дәфтәреннән язып алынды*

Агыйдел сулары булсам
Болганып агар идем.
Яңгыр тамчылары булсам,
Алдыңа тамар идем.

Җырлыйк әле, гөрлик әле,
Барыбыз бергә чакта.
Бервакыт таралышырбыз
Төрлебез төрле якка.

*Александр районы Тукай авылында*
*Морзакаева Люция Саях кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

### *Уен җыры*

Рәткә тезелеп баса идек тә:

Мин матур, мин матур,
Миннән матур кайсыгыз?
Миннән матур булганыгыз
Чыгып алга басыгыз.

Аннан бусы чыга инде. Аннан без тагы ерлыйбыз:

Безнең персидәтел чаба,
Легковойда – такырдан.
Ә сезнеке җәяү йөри,
Тарантасы ватылган.

* * *

Кодаларга:

Синсез савытларым тулмый
Син-синнәр тутырсам да.
Синсез күңелләрем булмый,
Кайларда утырсам да.

*Александр районы Тукай авылында*
*Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Шаулый урман, шаулый урман
Җилләр искәндә.

Сагындыра тугайлары,
Искә төшкәндә.
Сагындыра тугайлары,
Көмештәй салкын сулары,
Әллә инде шунда үскәнгә.
Сагындыра сызылып аткан
Алсу таңнары.
Әллә шул су буйларында
Яшь йөрәккә тәүге тапкыр
Саф мәхәббәт кабызган ялкын.

*Александр районы Тукай авылында*
*Вахитова Сәрия Самат кызыннан (1970 елгы)*
*язып алынды*

Сугыштан кайткач, әти чирләп ятты, шунда шулай ерлый иде:

Агыйделнең аръягында
Ак кар ятулары бар.
Яшь йөрәгем эчләремдә
Хәсрәт катулары бар.

Агыйделләр күтәрә алмый
Бер мыскал тимерләрне.
Эзләсәң дә табып булмый,
Үткән яшь гомерләрне.

***Озын көй***

Мәдинәкәй дигән калаларга
Кич акшамсыз капкалар ябылмый.
Үткән гомер белән калган хәтер
Сатып алыйм дисәң дә табылмый.

Үтәсең лә, гомерем, ай, үтәсең,
Үтәсең лә, харап итәсең.
Үтүләрең генә берни түгел,
Картайтып ла харап итәсең.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Мөнирә Сибгатулла кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Бадъян гөлләр чәчәк атканда
Сандугачлар канат какканда
Ятлар яхшы тәмле аш капканда
Үзләр кирәк чирләп ятканда

### *Борынгы җырлар*

Иртәдәй генә торып тышка чыксам
Сандугачлар кунган киртәгә.
Әҗәл вакытларын белеп булмый –
Әллә бүген, әллә иртәгә.

* * *

Ак тулалар бигрәк матур була,
Аркау бавы тигез эрләнсә.
Үз дигәннәрең дә ятка әйләнә,
Читкә йөреп күңеле керләнә.

*Александр районы Яфар авылында*
*Яһудина Роза Газиз кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

Алма бакчасына керсәм
Алма тия йелкәмә.
Үземә дә берәү генә,
Сүз әйтмәгез иркәмә.

Алма пешкән, өзелеп төшкән,
Сандугачның башын тишкән.
Матур кызлар сайлый-сайлый
Чәчләремә ак төшкән.

Сандугачым, син бәләкәй,
Гөл арасына күмел.
Уйлап та карамас идем,
Сабый чакларым түгел.

Гармунчының кулларында
Төрле көйләр уйныйбыз.
Сез алырлык, без барырлык
Булсак кына уйныйбыз.

Минем дустым гармун уйный
Ике җиңен сызганып.
Гармун уйный, кулы тала –
Үләм инде кызганып.

Гармуннары, гармуннары,
Гармуннары, моңнары.
Тәрәзәне ишек итеп
Йөргәннәр ич моңары.

Агыйделнең аръягында
Сандал киеп уйнама.
Үзең ничек, мин дә шулай,
Ялыныр дип уйлама.

Балаклары, балаклары,
Балаклары киң түгел.
Бигрәк оста бии инде,
Артистлардан ким түгел.

Агыйделгә төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр җәйгән гөлләр кебек
Китмәдең йөрәгемнән.

Әби мескен яшь чагында
Биегән дә биегән.
Менә хәзер бии алмый
Подшипнигы эрегән.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Кывандыкова Наилә Гыйният кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Элеккеге җыр бу:

Сакмар буенда туып үстек,
Сусаганда эчтек суларын.
Сакмар суы булды якын дуслар,
Аңа чәчтек барлык серләрен.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Сөлимова Әсма Газиз кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Утырдым да кәмә төпләренә,
Карадым да суның төбенә.
Башка язганнарны күрми бер чара юк,
Ходай кушканнарны күрми чара юк, –

әнинең ерлаган еры бабай белән бергә утырып.

* * *

Ерак-ерак җирдән
Сәлам сиңа улыңнан.
Сирәк язасың дип,
Үпкәләмә, әнием.
Үпкәләргә син генә хаклысың.
Әнием, күз нурым,
Көт мине, кайтырмын.

*Сарыкташ районы Кылчым авылында*
*Хәсәнова Гөлара Ногман кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

## Балалар фольклоры

Бакчадагы алмагач
Корый яңгыр яумагач.
Бакчалардан ни файда бар,
Алма пешеп тормагач, –

дип яңгыр телибез үскәндә, шулай урамнарда телибез. Инәйләр өйрәтә ине безгә.

*Шарлык районы Зирекле авылында*
*Кәбирова Зәрә Заһретдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

– Төлке-төлке, Телән би,
Төнне ка-йа бара-сың?
– Әбиемә ба-ра-мын.
– Әбиең сиңа ни би-рә?
– Бер пешерем ит би-рә.
– Аны кая ку-йа-сың?
– Таш башына ку-йа-мын.

– Таш башыннан эт а-лыр,
Нәрсә белән ку-ар-сың?
– Таяк белән ку-ар-мын.
– Таяк каян а-лыр-сың?
– Әрәмәдән а-лыр-мын.
– Таягың сынса ниш-ләр-сең?
– Балта белән ку-ар-мын.
– Балта каян а-лыр-сың?
– Кузничадан а-лыр-мын.
– Кузничада тотарлар,
Сакалыңны өтәрләр,
Елкы мае сөртәрләр,
Яулык белән капларлар,
Яулыгыңны җил ачыр,
Хатының яныңнан качыр.

* * *

Басар ул, басар ул,
Басар өчен туган ул.
Безнең күңелләребезне
Ачар өчен туган ул.

Бас-бас, эзеңә,
Күз тимәсен үзеңә.
Фәрештәләр канат йәйсен,
Синең баскан эзеңә.

* * *

Әт итә, әт итә,
Бармаклары чәрт итә.
Кашы кара, буе зифа –
Коеп куйган кәртинкә.

* * *

Ары басма, бире бас,
Идән ярыгына бас.
Идән ярыгына басма,
Әниең өстенә бас.

* * *

Бас, бас, бас әле,
Тактасы сынмас әле.
Сынса, ялгарлар әле,
Такта табарлар әле.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Рәмзә Газиз кызыннан (1925 елгы)*
*язып алынды*

**Бишек җырлары**

Матур гына кызым син,
Бәләкәчем минем син.
Ай-кояшым, таң йолдызым,
Бәләкәчем минем син.
Минем кызым, минем җырым,
Ай-кояшым, таң йолдызым,
Бәләкәчем минем син.

Кашың кыйгач кара,
Күзең йомылып бара.
Матур төшләр күрә-күрә
Йокла, газиз балам син.
Минем кызым, минем җырым,
Матур төшләр күрә-күрә
Йокла, газиз балам син.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Әлфия Альберт кызыннан (1969 елгы)*
*язып алынды*

Аллаһу валлаһу,
Кәҗәләрне тауга ку.
Кәҗә тауны букласын,
Минем улым йокласын.
Лә иләһе иллә Аллаһу
Мөхәммәдер рәсүлуллаһу.

*Сакмар районы Татар Каргалысы авылында*
*Назыйрова Мәдинә Габделхак кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Һу-һу Аллаһу,
Кәҗәләрне тауга ку.
Кәҗә чәчәк ашасын,
Минем кызым йокласын.

*Сакмар районы Үрге Чебенле авылында*
*Кунафина Мәгъдәлинә Гайзулла кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Халык сүзләре, әйтемнәр**

Кара тояк карында ятмас.

*Александр районы Султакай авылында*
*Фәтхуллина Венера Әхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

Түз, түз балам, түзгән түш ите ашаган.

* * *

Ике бармак арасына ит үсми.

*Александр районы Тукай авылында*
*Гыйниятуллина Гөлнур Абдулла кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

Чүркә үрми шуның күзенә,
Кеше керми кеше гүренә.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяев Ришат Бари улыннан (1961 елгы)*
*язып алынды*

Көл алабыннан он алабына төшкән.

*Александр районы Яфар авылында*
*Асяева Рәмзә Газиз кызыннан (1925 елгы)*
*язып алынды*

## Табышмаклар

Утырышы мулла кебек,
Сызгырышы шайтан кебек.
(самавыр)

* * *

Ти, дисәң тими,
Тимә, дисәң тия.

(ирен)

* * *

Аягы да юк, кулы да юк, ә күлмәк кия.
(мендәр)

*Сарыкташ районы Рәдүт авылында*
*Ибраһимова Диләрә Чулпан кызыннан (1970 елгы)*
*язып алынды*

# ТРАДИЦИОННАЯ МУЗЫКАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА ТАТАР ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ

*Эльмира Галимова*

В настоящее время в обществе и науке активизировался интерес к этническому музыкально-эстетическому наследию, решению проблем исторической преемственности в культуре и возрождению традиционных ценностей. Развитие того или иного народа на уровне этноса, субэтноса, этнографической группы никогда не протекало в изоляции. Следовательно, довольно сложную внутреннюю структуру имеет и татарская этническая общность. Из-за обширности ареала расселения татар комплексное исследование всех этнографических групп, позволяющее судить об их этнокультурной дифференциации, до сих пор ещё не завершено. В исследованиях, проводимых в разных направлениях, главной проблемой является ареальное изучение особенностей разных субэтносов волго-уральских татар: *казанских, касимовских татар, мишарей* и субконфессиональной группы православных татар (*кряшены*). По систематизации этнографа Д. Исхакова *казанские татары* подразделяются на центральных (казанских), чепецких (Кировская область), оренбургских, пермских и тептяро-башкирских. Здесь термин *казанские* используется как объединяющий в широком смысле, то есть как субэтнос, включающий другие этнографические группы, и в узком смысле – как отдельная группа жителей Казани и Заказанья, называемая Д. Исхаковым *центральной*[1].

[1] *Исхаков Д.М.* Татарская этническая общность // Татары. М.: Наука, 2001. С. 11–25.

Безусловно, прежде чем делать какие-либо выводы о традиционной музыкальной культуре в целом и сложившихся национальных традициях татар Оренбургской области, стоит обратиться к страницам истории, в которых изложены очень интересные факты.

В 1730 г. хан Младшего казахского жуза (орды) Абдулхаир обратился к Российской империи с просьбой о принятии в подданство. С целью укрепления российского влияния в Зауралье была направлена экспедиция И.К. Кирилова, которой предписывалось заложить город-крепость. 31 августа 1735 г. у места впадения р. Орь в р. Яик (Урал) был основан город Оренбург. Однако место города было выбрано неудачно – оно постоянно заливалось весенним половодьем. 20 августа 1739 г. Оренбург был заложен вновь ниже по р. Яику в урочище Красная Гора. По проекту И.И. Неплюева, город-крепость надлежало перенести на место слияния Сакмары и Яика. На этом месте 19 апреля 1743 г. Оренбург был основан в третий раз. Оренбургская губерния была учреждена 15 марта 1744 г. В состав губернии входили земли современных Северного и Западного Казахстана, Башкирии, Челябинской области, часть Татарстана, Курганской, Самарской, Пермской, Тюменской, Свердловской областей. В 1758 г. после разгрома Китаем государства джунгар в Центальной Азии к России присоединился казахский жуз. В последующем границы губернии постоянно менялись. К 1917 г. Оренбургская губерния охватывала территорию, протянувшуюся с юго-запада на северо-восток от верховьев р. Самары до среднего течения р. Тобол. В состав губернии входили Оренбургский, Орский, Верхнеуральский, Троицкий и Челябинские уезды. С 1920 по 1925 г. Оренбург являлся столицей Киргизской Автономной Советской Социалистической республики (впоследствии Казахская ССР). Затем Оренбург потерял функции губернского и областного центра и стал центром округа в составе огромного Средне-Волжского края, протянувшегося от Пензы до Орска. В декабре 1934 г. была образована Оренбургская область в современных границах.

В ходе комплексной экспедиционной работы нами была поставлена задача посетить Шарлыкский район (д. Сарманаево,

д. Новомусино, д. Зерикло, д. Мустафино); Александровский район (д. Султакаево, д. Тукаево, д. Яфарово); Сакмарский район (д. Татарская Каргала, д. Верхние Чебеньки); Саракташский район (д. Ново-Кульчумово, д. Шишма, д. Кабанкино, д. Биктимерово, д. Никитино, д. Аблязово) Оренбургской области. В данных поселениях проживают татары, башкиры и казахи. Интересно, что диалектные особенности, которые являются определяющим национальным фактором населения каждой деревни, накладывают отпечаток на этническую самобытность и музыкальный фольклор в целом.

В ходе полевых исследований собран музыкально-фольклорный материал, состоящий из 267 напевов. Музыкальные записи сделаны от 73-х информантов 1925–1977 г. рождения. Необходимо отметить, что нами собраны экспедиционные образцы разных жанров: напевы книжного интонирования *(мөнәҗәт, бәет),* лирические песни *(озын көй, салмак көй),* деревенские напевы *(авыл көе, урам көе),* такмаки и короткие напевы *(такмак һәм кыска көйләр),* песни проводов солдата *(солдат озату җырлары),* колыбельные *(бишек җырлары),* игровые напевы и наигрыши *(уен җырлары һәм көйләре),* а также инструментальные наигрыши *(бию көе, инструменталь көйләр).* Безусловно, песни казанских татар, такие как: *«Су буйлап», «Герман көе», «Ах, җаныем суларда», «Сарман буйларында», «Рәйхан», «Олы юлның тузаны»,* нами были зафиксированы буквально в каждой деревне.

Полевые исследования также показали попытку сохранения некоторых традиций, к примеру *Карга боткасы, Майевка бәйрәме* (праздник труда) аграрного календаря исследуемого региона (д. Новомусино, д. Зерикло Шарлыкского района). Во время обряда *Карга боткасы* (воронья или грачиная каша) жители деревни готовят кашу в большом котле из собранных продуктов. Сопровождая криками *«кар-кар»,* приготовленную кашу разбрасывают вокруг. Далее праздничное действо продолжается угощением друг друга приготовленной кашей. После этого жители в сопровождении гармониста исполняют такмаки, деревенские и плясовые напевы. Весенний обряд *Карга боткасы* предвосхищает главный праздник татар Оренбургской области –

*Майевка бәйрәме.* Это один из самых любимых праздников, все этапы проведения которого приближаются к празднику Сабантуй казанских татар. Подробно нам об особенностях проведения этого обряда аграрного календаря рассказал житель д. Новомусино Шарлыкского района М.Р. Абдршин (1962 г.р.). Большая часть музыкального сопровождения *Майевка бәйрәме* состоит из знаменитых песен казанских татар (*«Үтте дә китте яшьлегем», «Олы юлның тузаны», «Бездә биек таулар бар», «Эрбет көе», «Бишле бию көе»* и т.д.). Марат Рузитович Абдршин, являясь руководителем фольклорного ансамбля и музыкальным работником Дома культуры д. Новомусино, ведёт активную работу по внедрению традиционного музыкального фольклора в массы, участвуя во всех мероприятиях Оренбургской области, а также обучая подрастающее молодое поколение.

По рассказу Кабировой Зары Загретдиновны (1932 г.р.) в д. Зерикло нами зафиксирован обряд *«Яңгыр теләү»* (вызывание дождя), который продолжает бытовать в настоящее время и в других поселениях Оренбургской области. По сведению этнофоров, во время засухи жители деревни ходят на речку и в игровой форме обливают друг друга водой. По утверждению жителей поселений, после проведения этого обряда уже на обратном пути домой начинается дождь.

В ходе каждой экспедиции большое внимание уделяется жанрам книжного интонирования – *мунаджатам* и *баитам*. В Оренбургской области жанр *мунаджата* находится уже на стадии исчезновения из музыкального фольклора. Сохранившиеся жанры книжного интонирования в быту татар Оренбургской области носят в большей степени религиозный характер. Исследователи дают следующее определение жанру: *мөнәҗәт* – обращение к Богу с просьбой, молитва, интимный разговор с Богом. По смыслу этому жанру ближе всего арабо-персидское слово нәҗү (беседа). По-видимому, от этого слова произошёл термин *мөнәҗәт,* что означает «исповедь самому себе», «разговор с Богом» и подчёркивает его интимный, сакральный характер. По собранному экспедиционному материалу в Оренбургской области мы можем систематизировать жанр *мөнәҗәт* по их содержанию

и выделить 3 группы. К первой группе относятся *мунаджаты,* в которых утверждается монотеистическая идея восхваления Аллаха, в них присутствует обращение к Аллаху с просьбой о помощи, милосердии, и они близки, по мнению М. Бакирова, к такому жанру восточной литературы, как *тәүхид* (араб. объединение; вера в единого Аллаха). Ко второй группе мы можем отнести ритуальные *мунаджаты,* исполняемые во время религиозных обрядов, праздников. Третью группу составляют *мунаджаты* – завещания и наставления, обращённые к детям. Во время экспедиции нам удалось зафиксировать такие мунаджаты, как: в д. Новомусино *«Инандым мин Аллага»*[1]; в д. Зерикло *«И, Ходаем», «Салават әйтү»*[2]; д. Мустафино *«Әлпи мөнәҗәте»*[3]; с. Верхние Чебеньки мунаджат *«Газиз Аллам», «Салават әйтү», «Җомга салаваты», «Алла ярдәм бирсен», «Ана сүзе», «Таравих Тәсбихе», «Салават әйтү»*[4]; с. Никитино *«Биш балам», «Илаһым, диде Муса»*[5].

### ***Инандым мин Аллага***

Записано от Абдершиной Рушан Бариевны, 1940 г.р.,
д. Новомусино, Шарлыкский район.




---

[1] Записано от Абдершиной Рушан Бариевны, 1940 г.р. (д. Новомусино, Александровский район).

[2] Записано от Кабировой Зары Загретдиновны, 1932 г.р. (д. Зерикло, Александровский район).

[3] Записано от Саягфаровой Сябили Гайсаяновны, 1943 г.р. (д. Мустафино, Шарлыкский района).

[4] Записано от Кунафиной Магдалины Гайзулловны, 1938 г.р. (д. Верхние Чебеньки, Сакмарский район).

[5] Записано от Макаевой Факии Галяувны, 1933 г.р. (с.Никитино, Саракташский район).

## *И, Ходаем*

Записано от Кабировой Зары Загрстдиновны, 1932 г.р.
д. Зирекле, Шарлыкский район.




## *Газиз Аллам*

Записано от Кунафиной Магдалины Гайзулловны, 1938 г.р.
д. Верхние Чебеньки, Сакмарский район.




Значительно уменьшился удельный вес в быту жанра *бәет (баит),* который являлся в свое время самобытным национальным достоянием музыкально-поэтического творчества татар-мусульман. Этот жанр еще с середины XIX в. неоднократно привлекал внимание многих учёных. В связи с этим татарская фольклористика насчитывает большое количество работ в области собирания, публикации и изучения этого жанра.

Исходя из собранного музыкального материала определяется следующая жанрово-тематическая классификация баитов:

1) исторические (сохранились только в текстовой форме) и 2) семейно-бытовые. Это наиболее многочисленная группа данного жанра. Основа их содержания – это трагическая гибель отдельных людей. Именно эта группа баитов на данную тематику актуальна в Оренбургской области. Из старинных образцов этого жанра нам удалось зафиксировать очень много интерпретаций популярного в свое время баита *Сак-Сок*. В настоящее время традиция интонирования произведений в этом жанре, к сожалению, угасла. Очень часто этнофоры интонируют баит на напев мунаджатов. На сегодняшний день бытование этого жанра наблюдается лишь в письменной традиции. Баитам свойственна строфическая форма стихосложения с чёткой организацией стиха: как правило, строфа состоит из двух или четырёх строк. В ходе полевых исследований в д. Новомусино нами записаны: *«Раушания бәете», «Өзелгән гомер»*[1]; д. Зерикло *«Айрат туганыбыз бәете»*[2]; с. Ново-Кульчумово *«Рәсулулла бәете»*[3], д. Кабанкино *«Солдат бәете»*[4].

### *Раушания бәете*

Записано от Абдершиной Рушан Бариевны, 1940 г.р.
д. Новомусино, Шарлыкский район.




---

[1] Записано от Абдершиной Рушан Бариевны, 1940 г.р. (д. Новомусино, Шарлыкский район).

[2] Записано от Кабировой Зары Загретдиновны, 1932 г.р. (д. Зерикло, Шарлыкский район).

[3] Записано от Арченбаевой Таскиры Мингалиевны, 1955 г.р. (с. Ново-Кульчумово, Саракташский район).

[4] Записано от Мусиной Халиды Гыйльметдиновны, 1938 г.р. (д. Кабанкино, Саракташский район).

## *Сак-Сок бәете*

Записано от Кабировой Зары Загрстдиновны, 1932 г.р.
д. Зирекле, Шарлыкский район.




## *Рәсүлулла бәете*

Записано от Аргснбасвой Таскиры Мингалисвны, 1955 г.р.
с. Кульчумово, Саракташский район.




Рекрутские песни *(солдат озату жырлары)* всегда вызывают научный интерес у исследователей. В Оренбургской области данный жанр не является особо популярным. Но всё же в некоторых деревнях жители с тематикой песен проводов в армию связывают дальнейшую судьбу человека. По сведению М.Р. Абдршина, 1962 г.р. (д. Новомусино, Шарлыкский район) существует поверье, что от смыслового контекста песни зависит дальнейшая судьба рекрута. Солдат, которого провожают в армию с песнями шуточного характера, всегда возвращается домой. Если солдат грустит и его провожают, исполняя песни лирического

плана, то это не к добру. С целью обеспечения безопасности новобранца на службе и его возвращения оренбургские татары выполняли ряд ритуалов. Например, традиция надкусывания рекрутом хлебного каравая перед отъездом на службу. Этот каравай мать хранила до его возвращения. Нам удалось зафиксировать очень интересные образцы песен: в д. Новомусино *«Армияга озату җыры»*[1]; д. Зерикло *«Солдат җыры»*[2]; д. Тукаево *«Солдатта булган дилəр»*[3]; д. Яфарово *«Карпат отряд»*[4], *«Сез көтегез»*[5]; д. Татарская Каргала *«Шахтёр көе»*[6].

## *Солдат җыры*

Записано от Кабировой Зары Загретдиновны, 1932 г.р.,
д. Зирекле, Шарлыкский район.




---

[1] Записано от Абдршина Марата Рузитовича, 1962 г.р. (д. Новомусино, Шарлыкский район).

[2] Записано от Кабировой Зары Загретдиновны, 1932 г.р. (д. Зерикло, Шарлыкский район).

[3] Записано от Гиниятуллиной Гульнур Абдулловны, 1940 г.р. (д. Тукаево, Александровский район).

[4] Записано от Асяевой Муниры Сибгатулловны, 1936 г.р. (д. Яфарово, Александровский район).

[5] Записано от Асяевой Гульсум Динатовны, 1959 г.р. (д. Яфарово, Александровский район).

[6] Записано от Латыпова Хамзи Хасановича, 1952 г.р. (д. Татарская Каргала, Сакмарский район).

## Солдат озату җыры

Записано от Дибаевой Альфинур Хабибзяновны, 1958 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




## Сез көтегез

Записано от Асяевой Гульсум Динатовны, 1959 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.



В описании свадебного обряда мы исходили из последовательного изложения наших этнофоров[1]. По их сведению, обряд растягивался на продолжительный срок и состоял из нескольких этапов: *никах, зур туй* (проводился в доме невесты), *кода туй,* который проводился в доме жениха. Раньше распространенной формой считался брак по сватовству – *kиңәшеп итү, ярәшеп йөрү.* Сейчас уже этого нет и свадебный комплекс начинается с обряда *кыз сорау.* Далее уже родители невесты и жениха договариваются о проведении религиозного обряда *никах,* который совершает мулла, как правило, в доме невесты. На его проведение приглашаются только самые близкие родственники. По правилам проведения *никаха,* мулла три раза задаёт жениху и невесте вопрос о согласии на заключение их брака. Получив от молодых положительный ответ, он читает молитвы (суры из Корана) для данного случая. Заканчивается этот ритуал обменом подарками. Жених после проведения обряда *никах* остаётся ночевать в доме жены. С раннего утра золовка жены *(җиңги)* готовит баню для молодых *(кияү мунчасы).* В пять – шесть утра молодые идут в баню, после которой в доме тёща молодого зятя ждёт с угощениями *(кияү коймагы, кияү пилмәне).* Свадебный обряд в плане музыкального сопровождения не отличается какой-либо оригинальностью. Во время свадьбы обычно исполняют песни *«Кодалар җыры»* в жанре: *кыска көй* и *такмак.*

В Оренбургской области в ходе полевых исследований отмечено бытование части свадебного обряда *Су юлы күрсәтү йоласы.* Об этом нам подробно поведала и исполнила песню *«Су юлы»* Асяева Альфия Альбертовна (1969 г.р.) из д. Яфарово Александровского района. Этот напев является визитной карточкой данного обряда. Нас удивило трепетное отношение татар Оренбургской области к данному обряду. Фольклорно-этнографические ансамбли показывают этот обряд в сценической интерпретации для всех приезжих гостей с исполнением главного напева этого обряда *«Су юлы»* чаще всего в многоголосии.

[1] Записано от Агишевой Галии Мухаметзяновны, 1945 г.р. (д. Султакаево, Александровский район); Асяевой Ракыи Бариевны, 1954 г.р., Асяевой Альфии Альбертовны, 1969 г.р. (д. Яфарово, Александровский район).

### ***Кодачалар җыры***

Записано от Абдершина Марата Рузитовича, 1962 г.р.
д. Новомусино, Шарлыкский район.




Обряд заключается в следующем: молодая невестка после свадьбы ранним утром берёт в руки коромысло с вёдрами и идёт за водой. В карман кладёт много конфет, для того, чтобы угощать встречающихся детей по пути к роднику или колодцу. Существует и такое поверье в д. Яфарово: сколько детей встретит невеста и угостит их конфетами по пути к колодцу, столько детей она и родит.

В Оренбургской области, на наше удивление, нам удалось зафиксировать много лирических песен в жанрах: *озын көй* и *салмак көй*. Безусловно, этнофоры с трепетом исполняют лирические песни казанских татар: *«Олы юлның тузаны», «Сарман буйларында», «Шахта көе», «Су буйлап», «Мәдинә-гөлкәем», «Янбикәм»* и т.д. Особого внимания заслуживают очень редко исполняемые песни в жанре *озын көй* и *салмак көй,* которые нам удалось зафиксировать в д. Тукаево *«Тәрәзә төбендә»*[1]*, «Кул*

[1] Записано от Рахматуллиной Дины Фазлыевны, 1933 г.р. (д. Тукаево, Александровский район).

## Су юлы

Записано от Асяевой Альфии Альбертовны, 1969 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




*буена килсәң»*[1], *«Ашказар җыры», «Асылъяр», «Булмый яшәп»*[2]*;* д. Яфарово *«Пар юкә», «Төшемдә күреп», «Аккош кайтты»*[3]*;* с. Ново-Кульчумово *«Ага сулар», «Нинди матур безнең тын бакчалар», «Тамчылар тамар чаклар», «Хатлар язам», «Яннарыңа барам», «Киек казлар», «Вәгъдә», «Ак пароход», «Бик сагындым Ык буйларын»*[4]*; д. Кабанкино «Энҗекәй»*[5], с. Никитино *«Утырып ла тышка чыксам», «Су буйлары»*[6]*;* д. Аблязово *«Иртә торам»*[7], *«Вакыт»*[8].

---

[1] Записано от Гиниятуллиной Гульнур Абдулловны, 1940 г.р. (д. Тукаево, Александровский район).

[2] Записано от Мурзакаевой Наили Гыйлемзяновны, 1929 г.р. (д. Тукаево, Александровский район).

[3] Записано от Асяевой Гульсум Динатовны, 1959 г.р. (д. Яфарово, Александровский район).

[4] Записано от Амировой Каусарии Галиевны, 1950 г.р. (с. Ново-Кульчумово, Саракташский район).

[5] Записано от Мусиной Анузы Хуснулловны, 1935 г.р. (д. Кабанкино, Саракташский район).

[6] Записано от Макаевой Факии Галяувны, 1933 г.р. (с. Никитино, Саракташский район).

[7] Записано от Ураевой Фариды Абдулловны, 1948 г.р. (д. Аблязово, Саракташский район).

[8] Записано от Апакаевой Альфии Абдулловны, 1953 г.р. (д. Аблязово, Саракташский район).

## *Вакыт*

Записано от Апакаевой Альфии Абдулловны, 1953 г.р.
д. Аблязово, Саракташский район.




## *Ак пароход*

Записано от Амировой Каусарии Галиевны, 1950 г.р.
с. Кульчумово, Саракташский район.



## *Булмый яшәп*

Записано от Мурзакаевой Наили Гыйлемзяновны, 1929 г.р.
д. Тукай, Александровский район.




В записанных нами лирических песнях во многих образцах в интонационном плане заметно влияние традиционной музыкальной культуры башкир. Есть версия, что это связано с историей этнического формирования татар Оренбургской области. По сведениям жителей, многие деревни в Саракташском районе основывали башкиры, и именно там их влияние особо заметно в жанрах песенной и инструментальной культуры.

Довольно редкие образцы колыбельных песен *(бишек җырлары)* нами записаны в д. Тукаево; д. Яфарово *«Әлли-бәллибәү», «Төлке-төлке»;* д. Татарская Каргала; с. Верхние Чебеньки; д. Кабанкино *«Төлке-төләйман»;* д. Биктимерово *«Аллаһуаллаһу».* Например, в колыбельной песне *«Матур кызым»* мы можем отметить факт влияния казахских интонаций, что придаёт некое мелодическое своеобразие данному жанру.

Также нам удалось зафиксировать две колыбельные песни *«Аллаһу-Аллаһу»* и *«Төлке-төлке»* с разными вариантами текстового и смыслового содержания, которые широко бытуют среди татар Оренбургской области. Несколько примеров данных колыбельных в исполнении этнофоров (Хасановой Бадимы Жаккановны, 1951 г.р. из д. Биктимерово; Мусиной Анузы

Хуснулловны, 1935 г.р. из д. Кабанкино Саракташского района и т.д.) зафиксировали на мотив речитативного плана в узком диапазоне. По мнению этнофоров, данный метод исполнения эмоционально воздействует быстрому засыпанию малыша.

### *Матур кызым*

Записано от Асяевой Альфии Альбертовны, 1969 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




### *Әлли-бәлли-бәү*

Записано от Дибаєвой Альфинур Хабибзяновны, 1958 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




На сегодняшний день в исследуемых районах Оренбургской области актуальны игровые напевы *(уен көйләре),* которые исполняют в зависимости от формы игры в среде молодёжного

общения. Как правило, молодёжные игры и увеселения начинались ранней весной с праздника ледохода. Затем приурочивались к праздникам *Сабантуй (Майевка бәйрәме)* и *Җыен*. В праздничные дни игры проводились на открытом воздухе с участием большого количества приезжих гостей. Более скромно игровое общение проходило в будни. Юноши и девушки собирались на вечерние посиделки *кич утыру.* Летом это, как правило, происходило на лугу, на берегу речки. А осенью и зимой, когда родители уходили в гости, молодёжь собиралась в одном из свободных домов на *аулак өй.* Сюда приходили только с разрешения старших и для проведения времени с пользой девушки брали с собой ручную работу (*пряли, вязали, вышивали*). Именно во время вечерних посиделок (*кич утыру* и *аулак өй*) юноши и девушки проводили разные игры и исполняли игровые напевы. Необходимо отметить, что в Оренбургской области игровые обряды и напевы сохранились в довольно большом количестве. На сегодняшний день игровые напевы уже популярнее, чем *озын көй* или *авыл көе.* Во время застолья, похода друг к другу в гости проводятся разные игры с исполнением игровых напевов. Это своего рода традиция гостевого общения татар Оренбургской области. Например, нами зафиксированы в д. Новомусино такие игровые обряды, как: *«Зилем уены», «Йөзек салышлы», «Исем кушышлы», «Саңгырау телефон», «Дуадак уены», «Ярма яралы», «Үрдәккәем, чумасың»*[1] и т.д. В д. Зерикло зафиксирован игровой обряд *«Күмер салышлы», «Наза уены», «Тук-тук уены», «Чирта уены»*[2]. В д. Мустафино нами записаны игровой обряд *«Кристанце», «Чүрәкәй уены»*[3]; д. Султакаево (Александровский район) – *«Күгәрчен ашату», «Кагыш-кагыш уены»,*

[1] Записано от Абдершиной Рушан Бариевны, 1940 г.р. (д. Новомусино, Шарлыкский район).

[2] Записано от Кабировой Зары Загретдиновны, 1932 г.р. (д. Зерикло, Шарлыкский район).

[3] Записано от Саягфаровой Сябили Гайсаяновны, 1943 г.р. (д. Мустаϵ фино, Шарлыкский район).

*«Ак тирәк уены»*[1]; д. Яфарово – *«Зилем уены»*[2]. В д. Верхние Чебеньки (Сакмарского района) зафиксировали игровые обряды: *«Ак тирәк – күк тирәк уены», «Боланлы»*[3].

### *Зилем көе*

Записано от Асяевой Гульсум Динатовны, 1959 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




### *Тамчы там*

Записано от Асяевой Гульсум Динатовны, 1959 г.р.
д. Яфарово, Александровский район.




---

[1] Записано от Агишевой Галии Мухаматзяновны, 1945 г.р. (д. Султакан ево, Александровский район).

[2] Записано от Асяевой Альфии Альбертовны, 1969 г.р. (д. Яфарово, Александровский район).

[3] Записано от Кунафиной Магдалины Гайзулловны, 1938 г.р. (д. Верхние Чебеньки, Сакмарский район).

Интересен тот факт, что любой напев, бытующий в деревне, мог бы называться авыл көе. Тем не менее статус *авыл көе* получают лишь избранные напевы, которые называются именем того населённого пункта, где они бытуют. Именно таких закреплённых к определенному поселению песен в жанре *авыл көе* нами не зафиксировано. Этнофоры отмечают, что исполняют *авыл көе* во время застолья, когда происходит всплеск коллективных эмоций и песня становится средством духовного единения. Таким образом, в этом жанре заложена изначальная многофункциональность «деревенских напевов» в рамках конкретной локальной традиции, необходимость их звучания в различных ситуациях. Довольно небольшое количество деревенских напевов *(авыл көйләре)* мы зафиксировали как в вокальной, так и инструментальной трактовке в поселениях: д. Новомусино, д. Мустафино, д. Тукаево, д. Яфарово, д. Шишма.

### *Авыл көе*

Записано от Кутлукаева Марселя Гыйзатшаевича, 1946 г.р.
д. Чишма, Саракташский район.




В музыкальной культуре оренбургских татар наряду с песенным фольклором представлена также инструментальная музыка. Во время полевых исследований нам удалось зафиксировать наигрыши, исполненные на саратовской, тульской гармони, баяне и хромке. Саратовскую гармошку достаточно услышать один раз, чтобы потом ее звучание не спутать ни с

– Әти, ник ул кадәр борчыласың, ни булды, – ди.

– Менә шулай-шулай эшләп китерергә кушты, – ди.

– Бер дә курыкма, эти, – ди. – Менә син анарга шушы агачны илтеп бир дә, – ди, – шул агачтан миңа киндер суга торган станок ясап бирсен, – ди, – бүтән төрле агач кертмәсен, бер төрле генә булсын дип әйт, – ди кызы.

Патша кыз җибәргән агачны алып карый да: «Ай-һай, кызың күп белә икән, – ди, – Алай булгач мин анарга алты кәҗә тәкәсе җибәрәм, – ди, – таң атканчы шуларны бәтиләтсен, ди, бәтиләре оргач (ана) булсын», – ди.

Карт тагын җылый-җылый тәкәләрне алып кайтып китә. Кыз кәҗә бәтиләрен күрүгә шатлана башлый.

– Безгә бик яхшы булды әле бу, без аларны берәм-берәм суеп ашарбыз, – ди.

– Әй, сиңа көлке, патша шул тәкәләрне бәбиләтергә кушты бит, – ди.

– Бер дә кайгырма, эти, – ди, – рәте табылыр әле, – ди кызы.

Патша бер көн көтә боларны, ике көн көтә. Көтеп-көтеп килмәгәч, үзе китә. Кыз патшаның килгәнен күрә дә этисенә әйтә: «Хәзер үк мунчага бар, патшага үзем җавап бирермен», – ди. Карт «патша мине алырга килә икән» дип йөгерә генә мунчага.

Патша килеп кергәндә кыз килегә тары салган да тары төеп тора.

– Үзең тары төясең, – ди, – килеңдә ничә бөртек тарың барлыгын беләсеңме, – ди патша.

– Әй, падишаһым-солтаным, – ди, – хәзер генә килеп кердең, сездән безгә хәтле ничә адым булды, шуны санадыңмы, – ди кыз.

– Санап атламадым шул, – ди патша.

– Мин дә тарыны санап салмадым шул, – ди кыз.

– Атаң кайда? – ди.

– Мунчага бәбәйләргә китте, – ди кыз.

– Әй ахмак, ир кеше бәбәйлиме инде, – ди. – Кәҗә тәкәләре кая соң, – ди.

– Бәй, карт кешегә синең йомышка йөргән өчен аяк җалы кирәкмимени, – ди кыз, – суеп ашадык, – ди.

Патша уйлый: «Тукта, – ди, – мин бу кызны яучы җибәреп үземә ала алмам микән», – ди.

Бердәнбер көнне патша яучы җибәрә кызга. Кыз риза була. Ә карт: «Бара күрмә, кызым, икебезне дә астырып үтерер», – ди. «Юк, – ди кыз, – мин барам, – ди. – Бармасам, икебезгә дә начар булыр», – ди.

Ярар, патша кызны алып китә.

Азмы-күпме бергә торгач, патша яланнарны карап кайтыйм дип чыгып китә. Чыкканда әйтә: «Миннән башка беркемгә дә хөкем итмә» дип. Патша чыгып китүгә кыз чардакка менә дә карап тора. Эшчеләр эшли: кайсы кибән куя, кайсы җыя, кайсы нишли шунда. Шунда ике кеше килделәр дә атларын тугарып җибәрделәр, үзләре печән чаба киттеләр. Ашарга кайтсалар, тегеләрнең атлары колынлаган, колын ике тәртә арасында ята, ә ат печән ашап йөри. Болар икесе дә колын янына килгәннәр дә аптырап карап тик торалар. Берсе әйтә: «Бәй, бия колынлаган бит», – ди. Икенчесе: «Бияме соң, колын тәртә арасында ята бит, минем арба колынлаган», – ди. Шулай спорлаша-спорлаша сугыша башлыйлар болар. Сугышып кара канга баталар болар. Аннан «болай булмый, әйдә хөкемгә патшага барыйк», – диләр. Китәләр болар патшага.

– Патша өйдәме? – ди берсе.

– Юк, – ди хатын.

– Кая китте соң?

– Тау башына тары чәчкән идек, шул тарыны көн дә күлдән чуртан чыгып чүпли, шуны куарга китте, – ди.

– Бәй, – дигән берсе, – тау башына чуртан чыгып ничек чүпли ул тарыны, – ди.

– Чүпли шул, – дигән хатын, – әле сез дә килдегез бит бия колынламаган, арба колынлаган дип. Кайчаннан бирле шуның өчен сугышасыз. Ничек инде арба колынласын, – ди. – Барыгыз кайтып китегез, – ди хатын.

– Әй, без ялгышканбыз икән, – дип кайтып китәләр болар.

Ярар, кайтып керә патша. Сорый:

– Хөкемгә килгән кеше булдымы, – ди.

– Килделәр, – ди, – печән чабучыларның биясе колынлаган, – ди. – Шуны белмичә арба колынлаганмы, бия колынлаганмы икәнне белергә хөкемгә килгәннәр, – ди. – Безгә килгәндә сугышып канга батып беткәннәр, ничек хөкем итмисең инде, – ди.

– Син нәрсә дип әйттең соң, – ди.

– Менә тау башына тары чәчкән идек, шул тарыны күлдән чуртан чыгып чүпли, шуны куарга китте, дип әйттем, – ди хатыны.

– Әй, ди патша, – син миннән узып хөкем иткәнсең, – ди, – мин кайткач килерләр иде әле, – ди.

– Эш кешесен ничек көттереп торыйм инде, хөкем иттем дә җибәрдем, – ди.

– Юк, – ди, – безнең сөйләшкән сүз бар иде бит, миннән башка хөкем итмәскә дип, мин монарга риза түгел, бүгеннән аерылабыз, үзең теләгән әйбереңне ал да кит, – ди патша.

– Ярар, – ди хатыны, – бер атна вакыт бир, аннан китәрмен, – ди.

Хатын яхшы иттереп бал куя да бер көнне шулай әйтә: «Инде миңа китәр вакыт җитте, әйдә китәр алдыннан икәү бергә утырып чәй эчик», – ди.

Хатын эчерә патшаны, теге исереп тә китә. Хатын әйтә хезмәтчеләргә: «Ат җигегез дә патшаны чыгарып салыгыз», – ди. Ат җигелгәч патшаны трантаска чыгарып салалар. Хатын үзе трантас алдына менеп утыра да алып китә патшаны. Әй ат белән йөриләр болар урам әйләнеп, әй йөриләр, чокырлы җирләрдән дә, чаптыралар гына, патшаны бөтенләй оныта бу. Шулай йөри торгач айнып патша сикереп тора да:

– Бәй, нишләп йөрибез без бу яланнарда, – ди.

– Сине үземә алып кайтып барам. Син бит, үзең теләгән әйберне ал да кит, дидең. Менә минем теләгән әйберем син, – ди, – сине алып китеп барам, – ди хатын.

– Их, – ди, – минем хатын үземнән акыллырак икән, миңа шундый хатын кирәк тә, әйдә, бор атыңны, өйгә кайтабыз, – ди.

Өйгә кайталар да болар яңадан яхшы гына тора башлыйлар. Килгән кешегә икесе дә хөкем итәләр, киңәш бирәләр. Хатын иренә караганда да тугры хөкем итә икән, ди.

*Октябрь районы Биккол авылында*
*Минҗамал Гапсаттаровадан*
*Х. Гатина язып алган. 1960 ел*

### *Иренчәк*

Бер Иренчәк булган, ди. Ул бернәрсәгә дә кыймылдамаган, «иренәм» дигән дә утырган.

Моның бөтен эше шул икән, көн дә бер балык тота икән дә, шуның белән туклана, бүтән бернәрсә дә эшләми икән, ди.

Патша кызы көн дә моның балыкка киткәнен күреп гел көлә икән «иренчәк китте балыкка» дип.

Патша кызының көлгәнен белеп, Иренчәкнең бик ачуы килә икән. «Әй, – ди, – бер Алланың боерыгы берлән, алтын чабак коерыгы белән патшаның кызы корсаклы булсын иде. Ул миннән көлә, мин аннан көлсәм иде», – ди икән Иренчәк.

Бер заманны патшаның кызы корсакка уза да бер ир бала таба.

Патша бик хурлана инде, кызы бала тапты бит. «Ничек булса да баланың атасын табарга кирәк», – ди. Эзлиләр-эзлиләр баланың атасын, һич таба алмыйлар. Теге бала йөри дә башлый бит инде.

Хәзер баланың атасын белү өчен бөтен халыкны мәйданга җыялар. Халык түгәрәкләнеп тора.

– Авылда килмәгән кеше калмадымы, – ди патша.

– Иренчәк кенә калды, – диләр.

Патша кызы:

– Кирәкми, йөртмәгез шуны, – ди.

– Юк, – ди патша, – алып килегез, – ди. – Бәлки шул булыр баланың атасы, – ди.

Баланың кулына алма тоттыралар да мәйданга җибәрәләр. Бала алманы кемгә бәрсә, атасы шул була инде. Менә түгәрәк эчендә йөри бала, берәүгә дә бәрми бит. Патша әйтә: «Алып килегез иренчәкне», – ди. Иренчәкне алырга баралар, «юк, мин бармыйм, иренәм», – ди. Патшага кайтып әйтәләр. «Барыгыз, – ди патша, – ат җигеп, мендәрләр салып барыгыз», – ди. Теге һаман: «юк, мин болай гына бармыйм, иренәм, – ди. – Патша йортыннан минем йортка хәтле көмештән күпер салдырсын. Селкенчәкле арбага алтын башлы, көмеш тояклы ат җигеп, патша үзе килсен алырга, – ди. – Шуннан соң мин барырмын», – ди.

Моның бит өстенә кияргә рәтле күлмәге дә юк инде, шундый алама киенгән була.

Хәзер патша мәйданга җыелган халыкны күпер эшләргә куша инде. Күперне эшләп бетергәч ат җигеп, патша үзе китә иренчәкне алырга. Көмеш күпер дә салынгач, селкенчәкле арба белән дә килгәч, риза була бу барырга. Алып китәләр Иренчәкне селкенчәкле арбага утыртып. Бара Иренчәк селкенчәкле арбада селкенә-селкенә.

Иренчәкне алып килеп бер алмагачы төбенә яткыралар, утырып торырга «иренәм» ди бит инде. Моның тамагы да ач бит әле. «Алма аша», – диләр. «Өзеп ашарга иренәм лә», – ди Иренчәк. Ул алмагачы төбенә килеп ятуга теге бала алма белән китереп тә бәрә монарга. Шуннан ары «менә безнең кияү» дип күтәреп алалар моны. Алып менәләр Иренчәкне патша кызы янына. Кыз: «Яныма китерә күрмәгез, дөньяда бар көлгәнем Иренчәк иде», – ди.

Ярар, яхшы иттереп киендерәләр моны, хәзер танырлык та түгел инде. Кыз янына алып керәләр. Кыз моны күрүгә гашыйк була, шул хәтле чибәр була егет.

Шулай итеп, ашарга иренгән егет, йөгереп кенә йөри башлый патша кызына өйләнгәч.

Моннан соң кызы да кешедән көлми башлаган, ди.

*Октябрь районы Биккол авылында*
*Минҗамал Гапсаттаровадан*
*Х. Гатина язып алган. 1960 ел*

## Бәетләр

### *Беренче Герман сугышында чыгарылган бәет*
*(1914–1916 еллар)*

Әнекәем, без йөрибез ят җирләрдә
Ризыгыбыз чәчелгәндер күп илләргә;
Бәлки шәфкать булса булыр хактан безгә,
Хак тәгалә шаһларга сабырлык бирсен инде.

Вафат булсак, кая безне кәфенләмәк
Зират казып, кая безне хөрмәтләмәк;
Җиназа укып кая безне дәфенләмәк
Ничәбезне бер чокырга салдылар инде.

Ах дәрига ниләр күрми башларыбыз,
Гөнаһдан хали түгел эшләребез;
Кан аралаш агадыр яшьләребез,
Елга булып ага безнең каннарыбыз.

Урман сазлык безнең йөргән җиребездә,
Авыр мылтык, кылыч, патрон билебездә;
Кайчан кайтып кавышабыз илебезгә,
Хак тәгалә үзе кавыштырсын инде.

Кич яткanda карыймын күк йөзенә,
Ни күрермен, диямен үз-үземә.
Йокласам сез күренәсез күземә,
Кавышуны арзу күреп ятам инде.

Без йөрибез солдатларны саф-саф саклап,
Өстебездә шрапнельләр тора шартлап.
Шул сәгатьтә атларыбыз китә яклап,
Кыямәт көн булды мәллә, диям инде.

Бисмилла дип ияр салдык атыбызга,
Бер-беребезне язып салдык хатыбызга.
Кайчан кайтып хезмәт итәм каршыгызда,
Уйлап торсам, гакылымнан шашам инде.

*1960 елда З. Әхмәров тапшырган*
*дәфтәрдән алынды*

### *Солдат бәете*

Бисмилла дип башладым
Мөнәҗәтем башларын.
Иртә торып, битем юып,
Ашим солдат ашларын.

Алдым сәлам, яздым сәлам,
Туганнарым сезләргә.
Атна кичен, җомга көнне
Дога кылың безләргә.

Кайгы-хәсрәт белән чыктым
Туган үскән илемдин.
Картус иләп шинель киеп,
Каеш будым билемдин.

Йортымыздин чыккан чакта
Бер карадым каерылып,
Бәхил булыгыз, туганнарым,
Киттем сездән аерылып.

Приемдин кайткачтин
Кердем әнкәй янына;
Хезмәт дигән авыр хәсрәт
Авыр газиз башыма.

***Бәет***

Почтовойда кәгазь читләре күп,
Сәлам язар идем, каләм юк.
Каләм булса, ай, кара юк,
Хак тәгалә язгач, чара юк.

Бу якларның җире түбән икән,
Һәрбер җирдә яман балоты.
Безнең йөрәкләрне бик көйдерде,
Бу герман сугышының уты.

Висла сулары бик зур судыр,
Биек лә булып үсә камышы.
Безнең йөрәкләрне чайкалдырды
Герман тупларының тавышы.

Кара саганларда пешерелә
Безнең ашый торган ашыбыз.
Кошлар да очып җитмәс җиргә
Ахры китте безнең башыбыз.

Безгә дә икмәкне салалар
Әчемәгән чүпрә башы берлән.
Иртәдәй торып атка менсәк,
Бит юабыз канлы яшь берлән.

Безнең дәй кылычлар бик үткер,
Кыеп бара камыш кыягын.
Бу якларның юлы таш юл икән,
Бик бетерде атның тоягын.

Бу сугышка килеп ике ат мендем,
Икесе дә атның аксады.
Алдин да, арттин туп аткачдин,
Сөяк буынларым каушады.

Безнең дә ашаган кашыклар
Бал кашык кебек шул очлыдыр.
Сезни лә, туганнар, сагындым,
Сезнең яктан карга да очмыйдыр.

Ай җактылары җактый була,
Айның унбишләре җиткәндә.
Безнең дә җаный җылап калды,
Без сугышка чыгып киткәндә.

Висла тауларының ай башында
Тәгәрәп үк ятадыр ташлар.
Бу сугышка килеп йөрмәс идек,
Азрак бәхетле булса башлар.

Донесение язган кәгазьләрне
Ташыйдыр бит түрә атлары.
Безнең дә ләй өсне явып алды
Бу палянның кара бетләре.

Агачлар яфрак койды
Октябрьнең унбише җиткәч,
Безнең әнкәй җылап калды,
Без сугышка җыенып чыккач.

Висла суларыннан чыгар идем,
Висла суы акмый туктаса,
Туган илләргәләй бер кайтырбыз,
Бер Ходаем үзе сакласа.

Аягыма кигән итегемнең,
Ахры таррак булды кунычы.
Бу сугышка дип атап чыккач,
Китте безнең җаныбыз тынычы.

Минди илә калган балаларга,
Җаныкаем, берүк тимәгез,
Исән булсак – бер кайтырбыз,
Җаный безнең өчен көймәгез.

...дигән сары майны,
Әнкәй, бән кайтмыйча башлама.
Исән дә генә йөреп сау кайтсын дип,
Хәер фатихаңдин ташлама.

Миннәнләй калган казакины
Сандыклардин алып элегез.
Исән дә ләй йөреп кайталмасам,
Әнкәй, бәхил була күрегез.

Карагай ла дигән агачларның
Яфрагы ла өчле буладыр.
Монда йөргән җирдә вафат булсак,
Яшь балалар жалкы каладыр.

Ботка да лай кигән чалбарымның
Ике тези сусарып тузды.
Безнең ләй, дуслар, яшь гомерләр,
Урыс хезмәтләрендә узды.

Астыма менгән туры атның
Ялы килми өчтин үрергә.
Хак тәгалә безгә язды микән,
Туган илне кайтып күрергә.

Безгә дәй төнләр сирәк килә,
Кичтин тыныч ук ятырга.
Безгә Ходай язды микән
Куанышып өйгә кайтырга.

Һаваларда очкан тилгәндер,
Канат очкайлары көйгәндер.
Бүгендин өйгәләй кайтыр идем,
Хак тәгалә ниләр дигәндер.

Сахраларга чыгып ятар идем,
Яшел үләннәргә буялам.
Син дә ләй, җаныем, исемә төшсәң,
Йокылардин елап уянам.

Миндин калган бүркемне,
Җаныем, чөйгә алтын элегез.
Миндин калган балаларны,
Җаныем, үзем кебек күрегез.

Җыен китапларның арасында
Сөеп укый идем Бакырган.
Сез туганнарны уйлый-уйлый
Аерыла яздым акылдан.

Висла суларын без үткәчтен
Күп гаскәрләрнең башын җуйдылар.
Кырылып та яткан солдатларны
Барын бергә җыеп куйдылар.

Висла суларындин без чыккачтын.
Күп гаскәрне шунда салдылар.
Бәд германларны кудырам дип,
Күп сабыйлар җәтим калдылар.

Висла суларындин үткән чакта,
Пантонный мостлардин үттеләр.
Вислалардан чыгып йөгергәч
Күп гаскәрнең канын түктеләр.

Висла өстендәге күперләрне
Германнар туплардин ваттылар.
Күпер өстендә килгән солдатның
Бик күбесе суга баттылар.

Минем дә Әхмәрем елады,
Әткәй син кая барасың? дип.
Бәнем дә йөрәгем ут янды,
Ахры мәхрүм каласыз дип.

*1960 елда З. Әхмәров тапшырган кулъязмалар арасыннан алынды. Бәет 1914–1915 елларда империалистик сугышта катнашучы Әхмәт Кашлубаев дәфтәреннән (8/X–53 ел) күчереп алынган булган*

### Бәет

Бу бәетне язган чакта
Бик күп уйлап утырдым.
Каләм алып язган чакта,
Күземә яшьне тутырдым.

Кызыл флагны күтәргәч,
Эшләрне ташлап киттек.
Күз яшьләрен елга иттереп,
Илләрдин чыгып киттек.

Инде китәсеңмени, дип
Барда миннән сорыйлар.
Өйгә күрешим диеп керсәм,
Бар да кычкырып елыйлар.

Исән йөреп сау кайтар, дип
Күп Алладин теләдем.
Яшь балалар кала диеп
Бән борылып еладым.

Әнкәем бәгырькәем лә,
Китеп бара балагыз.
Агай-эне, туганнарым,
Сезләр бәхил булыгыз.

Балаларның яшен күргәч,
Бән бик артка каерылдым.
Бигрәк кыен булып калды –
Туганлардин аерылдым.

Нәрсә – караны җыйнадым,
Ике кулым сызганып,
Эчем пошып ут тик янды,
Балаларны кызганып.

Бу җирләргә килдим мин,
Ризыгым булганга.
Бәхил бул, дип әйтәлмәдем,
Күңелләрем тулганга.

Без сугышка җыйналганда,
Дошманнар куандылар.
Әти, китәсең бит диеп,
Балалар еладылар.

Без илләрдән чыккан чакта,
Азан әйтеп калдылар:
Хак тәгалә шулай язгач,
Сугышка дип алдылар.

Без сугышка китәбез бит,
Әнкәй, бәхил бул сана.
Әнкәй, без фәкыйрьләреңә
Хәер-дога кыйлсана.

Безләр чыккан көнләрдә бит
Каты булды җил-давыл.
Без җыйналып чыккан чакта
Елады бөтен авыл.

*Тоз-Түбә районы Линевка авылы*
*укытучысы З. Әхмәров тапшырган*
*кулъязмадан күчереп алынды. 1960 ел*

## Мөнәҗәтләр

### *Мөнәҗәт*

Газиз балам, сине искә алып
Яза башлыйм мөнәҗәт башларын.
Чыгып киткәч ерак юлларга,
Әйләнеп кайтмады башларың.

Газиз бәбкәм, исемә төшкән чакта
Һичбер ала алмыйм сулыш та,
Яп-яшь кенә көйгә әрәм булып,
Югалып калдың инде сугышта.

Безгә мәгълүм түгел әй, бәпкәем,
Синең анда ничек булганың;
Әллә ятасыңдыр җир астында
Балчык, туфракларга болганып.

Тәкъдиреңдә язган язмыш булгач,
Әҗәлләр бит килми күренеп.
Синең зифа, газиз гәүдәләрең
Җир астында калды күмелеп.

Ничек кенә итеп түзә идек
Туплар тетрәп аткан чагында,
Белсәм иде, кемнәр булды икән,
Газиз жаның биргән чагында.

Күреп торгандыр дошман тупларының
Һаваларда очып килгәнен,
Без белмибез, җан бәгырем, синең
Кай җиреңә өзеп тигәнен.

Без белмәдек, бәбкәм, син анда
Әллә яткансыңдыр кансырап,
Хәлең белгән кешеләр булмады,
Яткансыңдыр тилмереп су сорап.

Әҗәл уклары кадалгандыр,
Күрә алмадык синең йөзеңне,
Дошманнарны куып йөргән чакта
Харап иткәннәр бит үзеңне.

Күреп торгансыңдыр, җан бәгырем,
Ярылып киткән дошман тупларын,
Мөмкин булса, барып тоткан булыр идем
Сиңа тия торган укларын.

Мөмкин булмагач, ата-аналар
Чакырсаң да яныңа килмиләр,
Ачынып торган ата-ана
Ни булганын сиңа белмиләр.

Дошман уклары килеп тигәч
Тырышкандыр торып йөрергә.
Сугыш сафларында син югалдың
Калдык тилмереп сине күрергә.

Йөргәнсеңдер сугыш сафларында
Аяк-кулларыңны талдырып,
Ихтыярсыз кердең җир астына
Әткәй-әнкәеңне калдырып.

Минут саен көтеп тора идек
Бетә диеп герман сугышын,
Сугыш бетүләрен көткән икән
Синең инде актык сулышың.

Өзеп тисен диеп явыз дошман
Туры итеп тупны аталар.
Әҗәл җитми, гомере бетми,
Буталышып җирдә яталар.

Улым армиягә китте
Кырык икенче ел июньдә,
Чыгып киткәч кайта алмады
Туган-үскән иленә дә.

Уйлый идек сине солдат булгач
Өсләренә шинель кияр дип.
Хатларыңны тилмереп яза идең
Сезне бик күрәсем килә дип.

Дошман кулларында үләрсең дип
Уйламадык сабый чагында.
Сугыш сафларына китеп югалдың
Яшең егермедә чагында.

Сине уйлап сулышым эчемә сыймагач
Тәрәзәләремне ачамын,
Карточкаларыңны кулга тотып
Әрнүле йөрәгемне басамын.

Кай җиреңә өзеп кадалды икән
Әй, бәләкәем, шушы явыз ук,
Синең өчен йөрәгем әрнүенә
Бер минут та түзәр хәлем юк.

Синең үлем хәбәреңне алдык
Бер мең дә кырык бишенче елда,
Әче хәсрәт, каты кайгы
Калды инде мәңге күңелдә.

Күптән инде, бәбкәм, синең хатың
Почтальоннар безгә китерми,
Никадәрле сагынып җыласам да
Җылауларым сиңа ишетелми.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары җиргә кадала,
Сугыш сафларында үлеп калгач
Газиз гәүдәләрең югала.

Көндезендә уйлап йөримен дә,
Төнлә төшләремә керәсең,
Төшләремдә боек күрә идем,
Кайта алмаска булган күрәсең.

Минут саен уйлап йөргәнгәдер,
Һәр төн төшләремә керәсең,
Гәүдәләрең килә күз алдыма,
Әнекәем, дип кулың бирәсең.

Туп актарган туфрак асларында
Калгансыңдыр, бәбкәм, күмелеп,
Ярдәм сорап куллар сузгансыңдыр
Үләм, дуслар, су бирегез дип...

*Шарлык районы Муса авылында*
*кульязмадан (бәетнең актыгы ертылган булган)*
*Х. Гатина күчереп алган. 1960 ел*

### ***Солдат зары***

Әнкәй, иртә торырсың,
Самаварың куярсың,
Газиз балам кайтсын диеп,
Хәер-дога кылырсың.

Казарманың эчендә
Урын җәйдем ятарга.
Ходай безгә кушар микән
Туган илгә кайтырга.

Казарманың буена
Бик күп үскән алмагач.
Алмагачы утка янсын,
Туган илең булмагач.

Таш казарма алларына
Бәйләп куйдым бер сары ат.
Ике кулым булса канат,
Тормас идем бер сәгать.

Сабый чакта бер төш күрдем,
Әрәмәлек эчендә.
Ул төшләрем килеп етте,
Егерме бер яшемдә.

Агач башы аеры,
Сандугачы сайрый.
Җан тик күргән дусларымдин
Бер Ходаем аерды.

Машиналар барадыр,
Эчендә ут янадыр.
Артыма әйләнеп карасам,
Туган илем каладыр.

Ике дә аккош очып бара,
Агыйделдә аларның кышлавы.
Җан бирүдән яман икән
Туган илне ташлавы.

Бакчада гөлләр бетәрме,
Арасыннан елләр үтәрме.
Үзегезне күреп сүзләшмәгәч,
Хатка язар сүзләр бетәрме.

Карагайдай кара урманны
Үтәр көннәр булырмы?
Бу кайгылар башым дип
Китәр көннәр булырмы?

Күк күгәрчен гөрләсә,
Җимнәр алып сибегез.
Безнең әнкәйләр җыласа,
Күреп үгет бирегез.

Без барасы юлларда
Агач башы теш кебек.
Үз илемдә йөргәннәрем
Йокымдагы төш кебек.

Биек-биек бураларны
Без булмагач кем бурар.
Язгы сабан туйларында
Без булмагач кем уйнар.

Өстемдәге шинелемне
Ничек киеп туздырыйм.
Җыен кафер арасында
Ничек гомер уздырыйм.

Алмагачы ак була,
Яфрагы вак була.
Җыл тәүлеге уникe ай,
Бик сагынган чак була.

### *Мулла хакында*

Бу дөньяга хәйран калып
Бән язамын мөнәҗәт.
Ахырзаман муллаларын
Бәян итмәгә хаҗәт.

Мулла ашка җыяр булса,
Җыя тышлы туннарны.
Әллә нигә хөрмәт итми
Фәкыйрь, мескен колларны.

Муллаларның түрендә
Тышлы туннар кигәннәр
Хәзер алар хөрмәтле –
Чуклы бүрек кигәннәр.

Көз ... да гошер булса,
Егет бирә атларын.
Әллә нигә уйга алмай
Фәкыйрь, мескен хәлләрен.

Мәсчетләрдә вәгазь әйтә
Агым су тик шаулатып;
Халык гошер бирмәсә,
Ала бирә даулатып.

Корбан гаете ае җитсә
Корбанны куй чалдыра.
Фәкыйрьләрне, ятимнәрне
Ашатмыйчы калдыра.

Үзенә якын туганнарын
Фәкыйрьлек тә хур тота.
Кирәк сүзне әйтер хәл юк,
Каргармын, дип куркыта.

Явыз дога кылган адәм
Булмас микән монафыйк.
Хәер илә дога кыйлса
Булыр иде муафыйк.

Бу хәлләрне күреп йөреп
Мин каламын хәйранга.
Хак тәгалә рәхмәте
Иман биргән биһрамга.

Муллаларга ник тиеш
Фәхерләнеп йөрергә;
Иблисләгыйн кыссасы бар
Үзләре укый белергә.

Муллаларга ник тиеш
Гамәл илә мактану.
Бу дөньяга кемгә килгән
Оҗмахлы дип хаклану.

### *Туган илем*

Ки бисмилла дип башлаймын
Мин мөнәҗәт.
Теләюбән үзең дип
Барча хаҗәт.
Күрмәенчә түзеп булмый
Һичбер сәгать.
Хак тәгалә үзе ярдәм
Бирсен имди.

Туган илем искә төшсә
Мин уйлаймын;

Әткәй, әнкәй төшемә керсә
Мин елаймын.
Әй, Ходаем, кавыштыр, дип
Мин теләймен;
Хак тәгалә үзе ярдәм
Бирсен имди.

Туган илем кайда икән, белсәм иде,
Туганнарым илә бергә йөрсәм иде.
Үз илемдә газиз җаным бирсәм иде,
Хак тәгалә үзе ярдәм бирсен имди.

Кайтып күрсәм иде бән илемне,
Һичкем белми минем мондагы хәлем.
Васыл итәм сезгә, әнкәй, сәламемне,
Хак тәгалә үзе ярдәм бирсен имди.

Әгәр вафат булсам бән ышбу ердә,
Һич кардәшем юктыр бит ышбу.
И Ходаем кавыштырсын ахыр көн,
Хак тәгалә үзе ярдәм бирсен имди.

Язлы, көзле кошлар очар
Энҗе кебек тезелеп.
Сандугачлар сайраганда
Әнкәй еглар өзелеп.

Уральский диңгезенең
Буй буйлары бик озак.
Насыйп булса, без кайтырбыз,
Булсын гомерләр озын.

Солдат поход чыкканда
Энчү кебек тезелә;
Туганнарым исемә төшсә,
Йөрәкләрем өзелә.

Иртә торып тышка чыксам,
Диңгез суы ялтырый.

Поход чыгып киткән чакта
Тәннәремез калтырый.

Безләр киттек, сез калдыгыз
Без йөрегән җирләрдә
Гомер булса, без кайтырбыз,
Туган-үскән илләргә.

Безнең йөргән җирләрдә
Кошлар сайрый тирәктә.
Бу башта авыр хәлләр,
Торыгыз, дуслар, теләктә.

Безнең йөргән җирләрдә
Комдин тузаннар туза.
Хезмәт итү бигерәк авыр
Гомерләр заегъ үтә.

Хәсрәт утына төшкән
Ирләр күптер дөньяда.
Җиһанда күп михнәт чиккән
Минем кебек дөньяда.

*Шарлык районы Сарманай авылында*
*иске кульязмадан күчереп алынган. 1960 ел*

## Җырлар

### *«Йөрәк»*

*(Элегия)*

Ни булды соң сиңа, йөрәккәем,
Нигә ашкынасың, шашасың,
Һәр көн шулай ашкынасы булсаң
Минем башкаемны ашарсың.

Һич кайда да килми утырасым
Һич кайда да килми йөрисем,
Әллә бер-бер хәлләр булыр микән
Нигә, йөрәккәем, әрнисең.

Йөрәгемне ташлар идем,
Ташлап булмый, өзеп алалмыйм,
Башкайларым тыныч урын эзли,
Ләкин илтеп суга салалмыйм.

Салкын сулар алып эчеп карыйм,
Ләкин йөрәккәем басылмый,
Кеше уйный көлә, күңел ачып,
Минем күңелләрем ачылмый.

*Абдуллин районы Абдрахман авылында*
*Мәрьям Фәтхуллина дәфтәреннән*
*И. Надиров язып алган. 1960 ел*

### ***Озын көйләргә берничә җыр***

Ай казанкай кала сәхрә дала
Күккә тиеп тора манара.
Хуш-исән бул, дускай, аерылабыз,
Бәлки күршә алмабыз тиз ара.

Ак иделкәй алкын, суы салкын,
Гизеп кенә булмый салларны.
Беребез анда хәзер, беребез монда,
Белеп кенә булмый хәлләрне.

Ак иделкәйләрнең ар ягында,
Ап ак чәчәк ята кар кебек.
Сәхрәләргә чыгып тыңлап торам,
Син дустымның тавышы бар кебек.

Ак иделкәй суы дулкынлана
Төньягыннан җилләр искәндә.
Йөрәгемә ялкын ут кабына,
Син дускаем искә төшкәндә.

*Абдуллин районы Абдрахман авылында*
*Сания Гафуровадан*
*И. Надиров язып алган. 1960 ел*

***Борынгы озын җырлар***

Алмалы да гөлләр алмалы,
Бик зур шәһәр диләр Каргалы.
Син җаныкаемны уйлый-уйлый,
Йөзләремдә нурлар калмады.

Көмештә генә чылбыр билдәндер,
Көмешчеләр коеп биргәндер.
Бер битләрең кояш, бер битең ай,
Бер Ходаем сөеп биргәндер.

Кистемдә генә йогач (агач), булды койгач,
Эчләреннән чыкты ла сандугач.
Оҗмахлардан чыккан хур кирәкми,
Күз алкайларымда син булгач.

Тәрәзәкәйләрдән караган,
Якасына чылбыр кадаган.
Кеше сүзләренә һич карамыйм,
Үз күңелләремә яраган.

Бадиян да белән кәләмфернең
Күрсәң иде чәчәксийнанын
Сәрби агачларның төпләрендә
Сәрхүш булып яттым бән җиде ай.
Гилми талип[1] белән гилми дөхтәр[2]
Кавыштырсын иде бер Ходай.

Ай яктыкайлары су кебек,
Ай янында олы юл кебек.
Мин сөямен сине җаным кебек,
Җандин якын иманым кебек.

Ай яктылары бигрәк якты,
Шәмсидәләр кебек ник түгел.

---

[1] Егет.
[2] Кыз.

Вәссиярдә кәсир күп җиһанда
Синең кебек зиһенле түгел.

Тәрәзә төбем сигез гөл,
Сигезесе дә аның кызыл гөл.
Мине дә генә ташлап ятны сөйсәң,
Саргаерсың siксән сигез ел.

Биек чардакларда торасың,
Нечкә билләреңне йазасың,
Нечкә билләреңне бора-бора
Кемне генә кызыктырасың.

Түгәрәккәй бакча эчендә
Туксан җирдә тургай уйныйдыр,
Тәкъдир-каминәре шулай язгач,
Без теләүләр белән булмыйдыр.

Шәмсекамәр им Ләйләбәдәр
Һаваларда ... шул кадәр,
Йосыф Зәләйханы ничек сөяр,
Бән сәне сәвәмен шул кадәр.

Әлкариларның (авылларның) мәрфугасында
Балкыйдыр ла Шәмси нурлары.
Синең дә кебек булса булыр,
Сигезенче оҗмах хурлары.

Кояшлар да чыгар ерактан,
Алмагач ла дигән тирәктән,
Кысма да, җаныем, ай, беләктән,
Син китмисең минем йөрәктән.

*Абдрахман авылында Җәннәт Исаевадан*
*И. Надиров язып алган. 1960 ел*

## Мәзәк

– Эй, энем, теге үзәндә бүре күрмәдеңме?
– Юк.
– Аннан арырак теге тауда дамы?
– Юк.
– Әнә теге урманда да юкмы?
– Юк. Нишләп бүрене бик сорыйсың, әллә син бүрече?
– Юк. Бүредән куркучы.

## Мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар

1. Алганга алты да аз,
   Биргәнгә биш тә күп.

2. Эт өрер, кәрван йөрер.
3. Язга чыксам, сөяктән сарай салырмын дигән.
   Җәйгә чыккач, оныткан.

4. Выж-выж курай тартасың,
   Тал төбендә ятасың;
   Бер осьмуха чәй белән
   Форсить итеп ятасың.

5. Ачу алдан, акыл арттан.

6. Кулыннан эшен алсаң,
   Авызыннан ашын аласың.

7. Ат бирсәң – узар,
   Тун бирсәң – тузар.
   Бер яхшылык бирсәң –
   Барысыннан да узар.

8. Ике табан таймас.

9. Бер дидем берлек,
   Ике дидем икмәк,
   Өч дидем очмак,
   Дүрт дидем дүртмәк,

Биш дидем бишмәт,
Алты дидем атмак,
Җиде дидем җитмәк,
Сигез дидем сикермәк,
Тугыз дидем тукмак,
Ун дидем уймак,
Кытыр-кытыр каймак.

10. Бәләкәй генә бөкре
Бөтен кырны бетерде. (Урак)

11. Бәләкәй генә ак тана,
Мөгезем бар, дип мактана. (Чәйгүн)

12. Бөтри башлы, мең күзле. (Уймак)

13. Өй түбәсеннән кайрак төште
Бөтен кешене кыра төште. (Ыкой)

14. Өйдә өйләймән, кырда курайман,
Суда сөләйман. (Себерке, курай, сөлек)

15. Чын кара таш ярчылыр,
Ярчыгы диңгез аркылы. (Таң ату)

16. Апан-апан, иске чапан, дүрт тәрәвеч, бер болгавыч, кәкре кубыз, якты йолдыз. (Дөя, ябуы, аяклары, койрыгы, өркәче, ике күзе).

**Әйтемнәр**

1. Һаваны җил боза, адәмне сүз боза.
2. Куян бала тапкан, куяр җирен тапмаган.
3. Үз кайгыңны үзең йот.
4. Кулдан кулга, аннан олы юлга.
5. Алла ташламаса, бүре ашамас.
6. Барына шөкер ит, югына сабыр ит.
7. Чыда, казак, атаман булырсың.

8. Капмасаң да май яхшы, бирмәсә дә бай яхшы.
9. Ярлының улы булганчы, байның колы бул.
10. Байның мәчесе дә куян тота.
11. Бай белән даулашма, түрә белән талашма.
12. Хатын алсаң – сайлап ал, аяк-кулын бәйләп ал.
13. Ир хакы – Тәңре хакы.
14. Атны сыйлап, хатынны кыйнап өйрәтәләр.
15. Кемгә война, кемгә файда.
16. Аманәт җан саклый.
17. Кешене өмет (яки мәхәббәт) яшәтә.
18. Егетнең сүзе үлгәнче, үзе үлсен.
19. Кеше булган кешедә һәр кешенең эше бар.
   Кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар?
20. Кунак китәм-китәм дип сыйлата,
   Хәстә үләм-үләм дип елата.
21. Көндез әкият сөйләгәнне ак аю ашый, диләр.

*Александр районы Тукай авылында*
*Х. Гатина язып алган. 1960 ел*



Татар халык җырлары

Институт языка, лите
Казанского фили
Рукописнь
сектора народно-пе
Коллекция 50
Папка 1
№ ед. хр. 6

1. Осталарем буй-буй такта,
Гөлләрем урам якта.
Тыныч булыр җир өстендә,
Совет иле бар чакта.

2. Аккош уйный, аккош уйный
Аргы ог күлләрендә.
Канал казып сулы итәбез,
Кара ком чүлләрен дә.

3. Алмагачлы, гөл бакчалы
Үтәчәк юлларыбыз.
Тынычлыкны яратканга,
Эш сөя кулларыбыз.

4. Минем иркәм хатлар яза,
Җавапсыз калмыйм мин дә,
Минем иркәм диңгез белән
Диңгез тоташкан җирдә.

5. Исле чәчәк өзеп алдым,
Үзебезнең болыннан.
Коммунизмга барабыз
Компартия юлыннан.

6. Тыяла ишек, җиз тупса,
Ачыладыр җил узса.
Кирәген бирә белербез,
Дошманнар борынын сузса.

Фольклор экспедициясе вакытында язып алынган материаллар (1960) һәм Зәкәрия Әхмәров туплаган халык иҗаты әсәрләре (1953–1954) Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклананалар (50 кол., 68 кол.)


Татар халык җырлары.

1. Бар эшне дә булдырабыз,
Бар эш тә килә кулдан.
Коммунизм нуры балкый,
Сталин сызган юлда.

2. Унбиш авыл якты ала,
Безнең авыл суыннан.
Ант ичәбез юлбашчыга,
Тайпылмаска юлыңнан.

Язып алучы: Зәкәрия Әхмәров

15/III-53 ел.

Чкаловская обл.
Буранный район
село Линевка
Ахмерову Закарии.

1953 елда Зәкәрия Әхмәров язып алып кайткан дәфтәрдән (50 кол., 1 сакл. бер.)


Чкалов өлкәсенә фольклор
материаллары җыю экспедициясе
җибәрергә уйламыйсызмы?
Җавап һәм киңәшләр
көтеп,
кайнар сәлам белән,
Зәкәрия Әхмәров
1/IV-53 ел.

Адрес: Чкаловская область
Бугурусланский р-н, село Микеевка.
Ахмеров З. Я.

Рукописный фонд
сектора народно-поэтического т-ва
Коллекция 50
Папка 1
№ ед. хр. 1

Табышмаклар

1. Үлчәнмәгән далада, саналмаган сарыклар. (Күк, йолдызлар).
2. Ишек какмый, тәрәзә чиертми, белми каласың, өйгә кереп утыра (Якты
3. Канаты бар – оча алмый, Аягы юк – тота алмыйм. (Балык).
4. Яңа кәне киенә, Калын тунга төренә; Күзен чишенә башлый, Кышын тунын да ташлый. (Агач).
5. Ямшел бабайның сакалы, су өстендә җилфердәде. (Камыш).
6. Ашарга сорамый – туктаусыз су эчә. Мин кайда – ул шунда, дөньяны тик гизә. (Автомобиль).
7. Гәүдәсе бер карышлы, Лом булыр башы. (Чүкеч).


8. Дүрт башлы, ике билле. (Мендәр).
9. Ике агай – тездән, калышмыйлар бездән. (Итекләр).
10. Ямаеп юк – тишек-тишек, Чыгып булмый – юк ишек. (Балык сөзгече).
11. Нечкә билле ак тана, Тонык күлдән су ала. (Каләм, перо).
12. Теле юк – сөйли, ялкауга көн бирми. (Смена газетасы).
13. Авызы юк, теше бар, ашаганын йотмый, кулы белән тотмый. (Пычкы).
14. Бергә йөриләр, бергә җыелалар, гомер буе берсен берсе күрмиләр. (Колаклар).
15. Алтын йорт, кәрәлгәнда аның тәрәзә. Керәсе җенә, Чыгып булмый тыз генә. (Мурда).
16. Ямел-ямел тәриләр, тәрәзәдән карыйлар. (Гөлләр).
17. Аркылы – торкылы – җома агайның күпере. (Тәрәзә рамасы).
18. Илзәйле-милзәйле, җен тагарга җуайлы. Илзәсез-милзәсез, җепь тагарга җуайсыз. (Бәрәңге, йомырка).
19. Ал тегермән ташы, гөл тегермән ташы, моны белгән – 120 ел яши. (Салават күпере).
20. Кабарый-кабарый кабарый көбек, кабарый пешкән икмәк көбек, җасаный-җасаный җасаный көбек, җасаный (ясаный) килгән кияү көбек. (Күркә).

Зәкәрия Әхмәров
1/IV-53 ел.

1953 елда Зәкәрия Әхмәров язып алып кайткан дәфтәрдән (50 кол., 1 сакл. бер.)


6
13. Яшь чагыңда — ямел чук,
картайгачтын — канкан бук.
14. Бай артыннан иярәм дип,
бака ботын аерган.
15. Эчеңдәге серене — дусыңа да сөйләмә,
дусныңның дусы табылыр, серле җиң
ярылыр.
16. Язлы-көзле ярты акыл,
кар суында балыклы.
17. Агна кургән койкакны[1],
тук булсаң да онытма.
18. Яшь — әлгәре, карт — кире.
19. Ун көн тавык булып яшәгәнче,
бер көн әтәч булып кал.
20. Эт азгыны буранда.
21. Карга кар ашый.
22. Кар башына кар яуса.
23. Ойдә утырып, шәһәр алып
булмый.

24. Җырның ертыгы юк. 4
25. Җырга ямау салмыйлар.

Зәкәрия Әхмәров

1/IV-53 ел.

с. Линевка,
Буранного района,
Чкаловской обл. Ахмерову З.

1) Койка — (къойкъа), кесәл, яисә „шурпа шурпасының шурпасы" мәгънәсендә.


Хөрмәтле Ярми ага!

29/III 54

Сезнең хатыгызны алдым. Рәхмәт. Бер иптәшнең үзе язып биргән әкиятен җибәрәм.

Халык авыз иҗатын җыю эшен дәвам итәм.

Сәлам белән — А. Әхмәров

28/III-54 ел

с. Линевка, Буранного района,
Чкаловской области. З. Ахмеров

Институт языка, литературы и истории
Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
Колл. 50
Папка 1
№ ед. хр. 8

Сөйләүче һәм язып бирүче 12/II.
Асанов Гыйлметдин Шә-
дин улы (47 яшь) — Чкалов өлкәсе
Буранный районы „Искра" миллионер
колхозының баш бухгалтеры.



Әкиятләр дәфтәре № 1.

1. Әкият.
2. Бабайның кече улы һәм бай.
3. Юлбарс, бүре һәм төлке.
4. Песнәк белән куке.
5. Ушган килен.
6. Байлык белән — үлгән, уку белән — терелгән.

Дәфтәрдә 28 бит.

СШЫТАК

па ....................... вуч .........

......... класа ....................... школы

Җыючы: Зәкәрия Әхмеров

Институт языка, литературы и истории
Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
Коллекция 50
Папка 1
№ ед. хр. 7 (14 бит)



бу дию терелә." Егет мондаминаны алып уйнап
җибәрә, дию сикереп торып, биергә тотына.
„Ай егет, уйнавыңа риза мын", — ди дию.
„Дөньяда ни теләсәң, шуны бирермен."
Егет әйтә: „Мине якты дөньяга чыгар,
минем бар теләгем шул", — ди. Дию бу
малайга әйтә: „Әгәр дә 12 елда бер бу мон-
даминаны уйнамасалар, мин үләм", — ди.
Дию бу егеткә өч тармаклы чыбыркы бирә
дә әйтә: „Бер сугарсың, минем көч керер,
икенче сукканда өскә күтәрербез, өченче
сукканда — һавага күтәрелербез", — ди.
Егет бер суга, дию үкереп җибәрә, икен-
че сукканда җирне ярып чыга, өченче
сукканда — икесе дә һавага күтәреләләр.
Шулай итеп, өскә китәләр болар. Өскә
баргандa байларның арбалары күренә.
Болар җиргә төшәләр, төшкәч, дию-
нең җиленә, бу бай сәүдәгәрнең өч доп-
ләре үлә, ике арбалары ватыла.

15 1-бит.

Дию малайны илтеп бирә дә, үзе кире өскә
китә. Бу байлар инде ни эшләргә дә бел-
миләр. Берсе әйтә: „Минем өйгә хат язый к…
анда бу егетне үтерерләр", — ди. Шуннан
болар өйләренә хат язалар, хатта бола…
диләр: „Без кайтуга, бу егетне үтереп, ан…
тиресен капкага кадаклагыз." Егетне атка
атландырып, теге хатны биреп аны алда
кайтарып җибәрәләр. Бу егет, кайтып җи…
рәк, хатны укып карарга була. Баягы сү…
ләрне укый ул бу хаттан: „Без кайту-
га, бу баланы үтереп, аның тиресен кап-
кага кадаклагыз." Егет бу хатны ерты…
ташлый да, кибеттән кәгазь-каләм
алып, болай дип башка хат яза:
„Без кайтуга, бу егеткә кызны биреп, өй-
ләндереп куегыз." Хатны алып барып
тапшыра, хатны укыгач, өйдәгеләр к…
кәшәләр дә, егетне өйләндерергә була…
лар. Төн уртасында егет белән кыз…

1953 елда Зәкәрия Әхмәров күчереп алып кайткан әкиятләр дәфтәреннән



Атын җиккән дә, тәртәгә улын бәйләгән. Аннан соң урам буйлап киткән. Беренче тыкрыкта берничә кыз очрап:
— Ой, мескен! Нигә бәйләдегез? — дип сораганнар.
— Кушканны тыңламый, ялкау — дип җавап биргән бу кеше. Кызлар: „Әй тиле карт"! дигәннәр дә, киткәннәр.
Икенче тыкрыкта да шул хәл кабатланган. Авылның башына җиткәннәр, инде борылып кайтырга дип дилбегәне тарткан чакта бер кыз очрап:
— Бабай нигә җәзалыйсың аны? — дип сораган.
— Эшләми, ялкау! — дип җавап биргән бу кеше.
— Ә... алай булса, чыбыркың белән атка сукканда, аңа да сук. Эш кадерен белер, ныграк. — дигән кыз, шатланып.

Икенче көнне шушы кызга бу кеше яучы җибәргән, кызга ни өчен болай булганны сөйләп биргәннәр. Кыз риза булган. Бик яхшы туй ясап, ике эшчән бәхетле тормыш төзи башлаганнар. Алар әле дә бар ди, ире орден алган, хатыны күргәзмәгә катнашып алтын медаль алган, ди.
Кичә генә шуларда булдым, радио тыңладым, кино карарга бардык. Самолёт белән улы кунакка кайткан иде.



Байлык белән үлгән, уку белән терелгән.

Борын-борын заманда булган ди бер бай. Аның хатыны да үлгән булган, бик күп маллары, өч кибете, бер тегермәне булган. Баласы үсеп җиткән, шулай да укый яза белмәгән. Бер вакыт бу бай улына 12 мең сум акча биреп, аны шәһәргә товарлар алырга җибәргән. Баласы 12 мең сум акчаны кесәгә салып ала да, шәһәргә китә. Шәһәргә барып җитә. Шәһәр читендә туктый. Караса, йорт капкасында бер алтын язу күрә. Язуга карап тора-тора бу егет арып бетә, теге язуны укый белми. Бу егет уйлый: шәһәрдән бер укый белгән кешене чакырып китереп укытыйм да, белим ди. Бу уй белән ул урам буйлап бара башлый, озак та үтми, бер укый белгән кешене алып килеп язуны укыта. Анда болай дип язылган була: „Кем дә кем укырга, язарга өйрәнергә










1960 елгы экспедиция материаллары (68 кол., 57 сакл. бер.)



Илек суы.

Илек суы үзе киң булса да,
Аның аша кошлар сайраша.
Чит илләргә киткән, онытма туган илне,
Сәлам хәбәрләр яз хат аша.

Илек суы, исең китәрлек киң
Колач җитми аша йөзәргә.
Ярсый йөрәгем, ярсый урын таба алмый,
Сабырлыклар бирсен түзәргә.

Бу җырны маг. пленкасына яздым.
Апа Сәйфиева Фәнис җырлады. (1934)
Орен. өлкәсе, Тоз-түбә районы, Линевка авылы. 11/VI-60.
Язып алучы Х. Гарданов.

Урам көе.

7

Сагынам дуслар, сагынам дуслар,
Кичен дә көндезен дә;
Караплар узып чайкалам
сагыну диңгезендә.

Суга баргач кына белдем
Суларның салкынлыгын;
Аерылышкач кына белдем
Дусларның якынлыгын.

Шул ук Фәнис Сәйфиевадан
Язып алынды. 11/VI-60.



Көзге салкын җилләрдә

Биек тауга менеп карыйм
Авылыбызның чишмәсен;
Ялгыз калган кантарендә
Илләренә төшәсең.
Йөгерек чагардай булсам да
кайтып китәрдәй булсам.
Көзге салкын җилләр белән
Туып үскән илләргә.
Җир җимеше җәе була,
Җыймагыз казармыйча;
Һәр вакытта сүзне үтәсәм,
Исемен чыгармыйча.

Бу җырны Камәр Нәҗмитдинов (36) һәм Кәшифә Шакировна (34) язып алынды.
Орен. өл. Тоз-түбә рай. Линевка авылы. 11/VI-60.
Язып алучы Х. Гарданов.
Пленкага язылды.

Солдат җыры

9

Җәекны йөздем,
Вәлҗем тамса да;
Илләрдән киттем,
Йөрәгем янса да.
Их, йөрәгем янса да.
Диңгез өстендә
Ак ак пароход;
Мине озаталар
Владивосток
Их, Владивосток.
Минем башымда
Яшел фуражка;
Тилмереп карыйм,
Баткан кояшка.
Их, баткан кояшка.

Бу җырны Камәр Нәҗметдин
язып алынды. Линевка авылы.
11/VI-60 ел.
Язып алучы Х. Гарданов

Х. Гарданов язып алып кайткан материаллар. 1960 ел (68 кол., 64–66 сакл. бер.)









Х. Гарданов язып алып кайткан материаллар. 1960 ел (68 кол., 64–66 сакл. бер.)




Х. Гатина язып алган фольклор материаллары. 1960 ел (68 кол., 45 сакл. бер.)



Шаян җырлар

клубка килгән чакта чүлләремне ташыймын,
үсган ~~булса гына~~ егетләрне бер күрүдә таныймын.
авыл егетләре киндер күлмәк киеләр,
ар булса үсган булсын ялкауларны сөймиләр...
лар юып куя сипарар казаннарын,
булсын грамотный сөймимен наданнарын.
кырларыннан тыңлыйм комбайн тавышларын,
н үзең дә җырчы булмасаң танышмамын.
ивларга барам, бер тәгәк сипса алам,
арда иң алдынгы син булсаң гына барам.
ында урак урдык, фонарь яндырып суктык,
авыл белән ярышта алдынгы булып чыктык.

Оренбург өлкәсе, Александров
р-ны, Тукай авылында
5/VII-60 Мордякаева Зөһрәдән язып
алынды, колхозчы, 1906 елгы
туган, грамоталы.
Язып алучы Х. Гатина

Х. Гатина язып алган фольклор материаллары. 1960 ел (68 кол., 45 сакл. бер.)







Х. Гатина күчереп алган фольклор әсәрләре. 1960 ел (68 кол., 34 сакл. бер.)





И. Надиров язып алып кайткан материаллар. 1960 ел
(68 кол., 46 сакл. бер.)



30-август 1960 г

2

Оренбург өлкәсе,
Абдулино районы.
Абдрахман авылы.

Авыл тарихына
караган истәлекләр.

Бу авыл 1831 елда Пенза
өлкәсе ягыннан күчеп килгән.
Абдрахман халкын шунда
күрә Пенза мишәрләре
диеп йөртәләр. Абдрахман
халкы күчеп килгән авыл-
ның исеме Богдан булып,
ул хәзер Мордовия өлкә-
сенең Атюрьево районы-
на керә. 1957 елда без
Р. Кадимов белән ул авыл-
ны күреп үттек. Үзенең
кем авыллар тараткан
бу мәдәниятне мишәр авыл
хәзер Ярылганы, Ябыгы,
кечүзен калган. Анда

Абдуллин районы Абдрахман авылында язып алынган материаллар. 1960 ел





Абдуллин районы Абдрахман авылында язып алынган материаллар. 1960 ел

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Әхмәтова Айгөл Илфак кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Галимова Эльмира Мөнир кызы* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире.

*Дәүләтшина Лилия Шамил кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни нәшрият бүлеге мөдире.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

*Мельникова Галина Владимировна** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге аспиранты.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Усманов Венер Мөдәррис улы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

*Шкляева Людмила Михайловна* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

**ЭЧТӘЛЕК**

КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6

ТАТАРЫ ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ:
ИЗ ИСТОРИИ ФОРМИРОВАНИЯ
*Лилия Давлетшина*
28

СӨЙЛИ ИКӘН ТАШЛАР ДА
*Марсель Әхмәтҗанов*
44

РӘДҮТ АВЫЛЫНЫҢ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ
*Венер Усманов*
61

ТЕЛЕН БЕЛГӘН – ТАРИХЫН ДА БЕЛЕР
*Дария Рамазанова*
75

ТАТАРСКИЕ ГОВОРЫ ОРЕНБУРЖЬЯ
*Галина Мельникова*
95

ЕЛЛАР ҮТКӘН ХАЛЫК ЙОЛАСЫ
*Флера Баязитова*
104

ӘДИП ИШНИЯЗ БИНЕ ШИРНИЯЗНЫҢ
ЯҢА ТАБЫЛГАН БИЛГЕСЕЗ ӘСӘРЛӘРЕ
*Марсель Әхмәтҗанов*
139

ОРЕНБУРГ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ФОЛЬКЛОРЫ
*Ильмир Ямалтдинов*
177

ТРАДИЦИОННАЯ МУЗЫКАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА
ТАТАР ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ
*Эльмира Галимова*
257

ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО,
ПРОМЫСЛЫ И РЕМЕСЛА
ТАТАР ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ
*Людмила Шкляева*
279

ШАЛЬЮ ВЕКОВ ОКУТАННЫЙ КРАЙ
*Айгуль Ахметова*
300

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
322

Авторлар турында кыскача белешмә
372

Научно-популярное издание

*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ**

2-е издание

Фәнни-популяр басма

*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән»* сериясе

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**ОРЕНБУРГ ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

2 нче басма

Редакторлар *Я.М. Абдулкадыйрова, Л.Ш. Дәүләтшина*
Корректор *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Китапта *Л.М. Шкляева, Э.М. Галимова, И.И. Ямалтдинов, А.И. Әхмәтова* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 21,8. Шартлы басма табагы 23,5.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20